Илдар Юзеев

*Истәлекләр, әңгәмәләр, шигырьләр*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2008

УДК 821.512.145.0
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Ю25

Төзүчеләре: *Роберт Миңнуллин, Тәфтилә Юзеева*

Рәссамы *Ринат Хәсәншин*

Илдар Юзеев: истәлекләр, әңгәмәләр, шигырьләр / төз.: Р.Миңнуллин, Т.Юзеева. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. — 199 б. — 3000 д. — ISBN 978-5-298-01661-2

Китапка Татарстан Республикасының халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты И.Юзеев турында замандашларының истәлекләре, фоторәсемнәр, шигырьләр туплап бирелде.

УДК 821.512.145.0
ББК 84(2Рос=Тат)-4

ISBN 978-5-298-01661-2
© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Миңнуллин Р.М., Юзеева Т.З., төзү, 2008

## *Чын мәгънәсендә халык шагыйре*

*Шигърият — кешенең рухи халәтеннән, акылыннан һәм җаныннан туа торган бер могҗиза ул. Шагыйрь яшәешнең без тоймаган, без игътибар итмәгән серләрен ачып бирә. «Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән», — дип юкка гына әйтелмәгән. Илдар Юзеевның сокландыргыч иҗаты әлеге фикерне тулысынча дәлилләп тора дип саныйм. Аның әсәрләре — шигырьме ул, лирик поэмамы, драма әсәреме яисә аның сүзләренә язылган җырмы — һәрчак күңел түренә үтеп керә, дөньяга яңача карарга, аны тирәнрәк аңларга мәҗбүр итә. Юморы мәгънәле, фикерләре зирәк, иҗаты эчкерсез аның. Укучыны көлдерә дә, елата да, җырлата да һәм, иң мөһиме, уйлата. Халык аны шуның өчен ярата һәм хөрмәт итә. Иң күп укылучы китапларның Илдар Юзеевныкы булуы барыбызга да мәгълүм.*

*Татар әдәбиятында бөек Тукай традицияләрен лаеклы дәвам итүче шагыйрь буларак, Илдар Юзеев яшь иҗатчыларның тәҗрибәле остазы да иде. Телгә, сүзгә сакчыл мөнәсәбәте белән татар теленең бар матурлыгын, байлыгын, моңын киләчәк буыннарга җиткерү миссиясен дә үтәде ул.*

*Илдар Юзеев иҗатының минем күңелемдә үз урыны бар дияр идем. Авылдан Казанга килеп укый башлаган елларда аның «Таныш моңнар»ы килеп чыкты. Без, авыл егетләре, аны кат-кат укып, радиодан тыңлап, авылны сагына идек, һәрберебез үз «Резидәкәен» исенә төшерә иде. Шул чаклардан алып Илдар Юзеевның һәр яңа әсәре күңелнең әнә шундый хиссиятле агымына кушыла барды. Заманында Сибгат Хәкимнең Илдар Юзеев турында әйткән сүзе дә хәтердә. «Туфан китә, ярый әле Илдар кала», дигән иде ул. Бу бик зур бәһа!*

*Илдар Юзеев — тормыштагы һәр күренешкә, һәр вакыйгага үз карашы, үз бәясе булган, язмыш авырлыкларына бирешмичә, иҗади кыйбласына тугры калган тыйнак шәхес — чын мәгънәсендә халык шагыйре.*

*Татарстан Республикасы Президенты*

*Минтимер Шәймиев*

**ШӘКҮРӘ ЮЗЕЕВА**

# Илдарның балачагы

1941 елны сугыш башлану белән әткәсе фронтка китте. Шул елны Илдар беренче класска укырга керде. Мин үзем һөнәрем буенча укытучы, ләкин, Илдар тугач, озак еллар авырып эшли алмадым. Шулай да әни кеше бала тәрбияләүдән туктамый инде ул. Укытучы буларак балаларның бигрәк тә инша язганда сүз табалмый интегүләрен белә идем. Шуның өчен мин аларга кечкенәдән үк төрле әкиятләр сөйли һәм шигырьләр укый торган булдым. Үзләреннән дә кыска-кыска шигырьләр ятлатам. Бу эш белән Нил да, Илдар да мавыгып киттеләр. Экскурсияләрдән, урманнардан, җиләктән кайткач, үзләреннән сөйләтеп, күргәннәре турында язарга куша идем. Шулай итеп балалар матур иншалар язарга өйрәнеп киттеләр, шигырьләр яза башладылар. Илдар өченче класста укыганда, Яңавыл район газетасында икесенең берьюлы шигырьләре басылып чыкты. Илдарның 1944 елны чыккан «Минем әти капитан» дигән бер шигыре истә калган. Өйгә пионер журналлары һәм «Пионерская правда» газетасын алдыра идек, анда оештырылган уеннарга балалар җаваплар язалар, газета-журнал, радиотапшырулар редакцияләренә шигырьләр һәм хәбәрләр җибәрәләр, аларга һәрвакыт җавап хатлары килеп торды.

Илдар сугыш вакытында балалар өчен кечкенә пьесалар да язгалый иде. Аны Ямады авылы клубында һәм Максим авылында куйдылар да әле. Ул, әлбәттә, бик балаларча язылган, чөнки үзе дә әле пионер яшендәге бала иде бит.

Сугыш туктаган елны «Ямады егетләре» дигән озын шигырь язды. Ун классны бетереп сугышка киткән һәм батырларча һәлак булган авылдашларыбыз турында иде ул шигырь. Аны концерт вакытында үзе укыды, ата-аналар бик еладылар. Бу инде хәзерге поэмаларының башлангычыдыр дип уйлыйм. Әдәби китапларны да бик күп укыйлар иде. Артык бирелеп, укуларына зыян килереннән курка идем. Шуның өчен шагыйрь яки язучы булу өчен бик күп фәннәрне тырышып укырга кирәклекне һәрвакыт аңлатып кына тордым.

Балачакта Илдар Тукайны яратып сөйли иде, үскәчрәк күбрәк Такташка тартылуы хәтердә калган.

Пионер яшендә вакытта иптәшләре белән Гәрә елгасы буйлап походка чыктылар. Берничә көн йөзеп, кояшта янып-пешеп кайтып төштеләр. «Өчәү чыктык ерак юлга» дигән поэмасы шуны хәтерләтә торгандыр.

Ун классны бетергәч, улым Илдар Казан педагогия институтының филология факультетына укырга керде һәм беренче көннәрне үк яшьләр газетасында «Саумы, институт!» дигән шигыре басылып чыкты.

*16 февраль, 1966*

**ФОАТ ДИНОВ**

# Сабакташ

Илдар белән без Ямады мәктәбенең беренче классына 1941 елда укырга кердек. Безнең белән бергә Зәйтүнә Әхмәдиева, Фәнүдә Фаюршина, Венер Зарипов, Инзель Талипов, Фидат Миңнуллин һ.б. уку башладылар. Беренче укытучыбыз Сафин Тимергази абый булды. Башлангыч мәктәптә без «Гали шкулы»нда, детсадта һәм башка биналарда укыдык, чөнки Ямады урта мәктәбе янган иде.

Күпме генә еллар үтсә дә, башлангыч мәктәптә безне укыткан укытучыларны: Сафин Тимергази, Сафиуллина (Казыйханова) Нәкыя апаны, Зарипова Нәзирә һәм Сафиуллина (Әхмәрова) Әсма апаларны зур ихтирам белән искә алабыз. Ике катлы яңа мәктәп салынгач (Даутов Малик агай җитәкчелегендә), Илдар белән без укуны шунда дәвам иттек һәм 10 нчы классны шунда тәмамладык. Безне укыткан укытучыларга Мухов Баян, Юзеев Гафур, Зарипов Якуб, Әхмәтов Локман, Казыйханов Нурихан, Шәйбуллина Маһира, Мерзлякова Софья һ.б. безне тәрбияләп, белем биреп, зур тормыш юлына чыгарганнары өчен барсына да зур рәхмәт, без аларны беркайчан да онытмабыз!

Мәктәптә укыганда, Илдар белән мин бик шук идек, үзебез гел дүрт һәм бишкә укый идек, шуңа әзрәк «скидка» да бирәләр иде. Әле дә хәтеремдә, физкультура дәресендә класс бүлмәсендә Илдар белән шаярып, бер-беребезне куалап уйный идек. Физкультура укытучысы Садыйков Шакир абый, безне тыя алмагач: «Икегезгә дә өчле куям», — диде.

Бер елны җәйге каникулда көймә белән Гәрә елгасы буйлап походка чыгып киттек. Мәсәгүт Варәш авыллары арасында тау итәгендә җирне чокып землянка ясадык. Төнлә безнең землянка тирәсендә бүреләр улый башлагач, бик курыктык. Безнең максат Танып елгасына барып җитәргә иде. Максатка ирешалмадык, ашарга беткәч, кире борылдык.

10 нчы классны бетергәч, аттестат алу өчен Яңавылга 30 чакрым җәяү барып экзаменнар бирдек, чөнки безнең мәктәптә чыгарылыш имтиханнарын алу өчен югары белемле укытучыларның саны җитми иде.

Аттестат алгач, Илдар Казанга китте, ә мин мәктәптә эшкә калдым, башта — китапханәче, ә соңыннан бухгалтер булып эшләдем. Кыен да, моңсу да булды Илдар киткәч. Ике елдан соң инде мин дә Казанга киттем, финанс-экономика институтына укырга кердем. Казанда студент елларында Илдар белән еш очраша идек, кич белән Чехов базары янында Илдар гармунда уйнап, мин җырлап йөргән чаклар истә калган.

Каникул вакытларында бергә Ямадыга кайткач, Илдар белән, гармун уйнап, җырлап, төнлә урам буйлап йөри идек. Чытырман очыннан башлап бөтен авылны урап чыга идек. Вузны тәмамлагач, безнең юллар аерылды, шулай да без бер-беребезне югалтмадык. Мәскәүгә килгәч, Илдар безгә ике мәртәбә керде (1983 һәм 1987 елларда), бик матур итеп төне буе истәлекләргә бирелеп утырдык. Илдар безгә шигырьләр язып калдырды. Арада Зәйтүнә белән икебезгә багышланган шигырь дә бар. Без аларны чын дуслык билгесе итеп саклыйбыз.

*Гыйнвар, 2007*
*Мәскәү*

**НАЗИР ЗЫЯЗОВ**

# Туган җирнең гүзәл җырчысы

Туган ягыбыз үз туфрагыннан чыккан талантлы улларын һәм кызларын һәрвакыт ихтирам итә, алар белән горурлана. Районыбызда туып үскән әдипләрнең һәм сәнгать осталарының тормыш һәм иҗат юлын зур кызыксыну белән өйрәнәбез. Шулар арасында Илдар Юзеев татар әдәбиятын үстерүгә үзеннән лаеклы өлеш кертүчеләр биеклегенә күтәрелгән талантлы шәхес булып балкыды.

Илдар Юзеев уртача буйлы, салмаграк хәрәкәтле, тыйнак, мөлаем, гади кеше иде. Ул — «моңлы шагыйрь», «яшьлек шагыйре», «тормыш шагыйре». Шигырьләре туган җиребезне, газиз әти-әниләребезне ярату турында, дуслыкка тугрылык, батырлыкка, матурлыкка соклану турында.

Илдар Юзеев, татар әдәбиятында сугыштан соңгы елларда тын гына агып яткан шигъриятне сискәндереп, көтмәгәндә генә үзенең «Таныш моңнар» поэмасы белән килеп керде. 20 яше яңа гына тулган шагыйрь тиз арада яшьләрнең яраткан шагыйренә әйләнде. Шигъри күңелле И.Юзеевка безнең якларның кабатланмас шигъри табигате тел ачкычы биргәндер, аның халык арасында популярлык яулаган җырларга әверелеп киткән шигырьләре дә нәкъ шул чорда иҗат ителгән. Әдипнең шигърият дөньясы үзенчәлекле.

Ул үз әсәрләрендә туган халкының тырыш хезмәтен данлый һәм туган ягыннан рухи азык ала, хезмәттән тәм таба. Бәрәкәтле Яңавыл җире яңа шәхес, соклангыч яңа шагыйрь бирде. Ул туган төбәге Яңавылны иң изге хәзинә итеп саклый. Башкортстанда туып үскән шагыйрь беренче чиратта үзебезнең республикабыз, аның үткән тарихы һәм бүгенгесе турында уйлана. Башкортстанга ул берничә шигырен багышлый, анда татарлар һәм башкортларның җыр-моң алмашып, тату яшәвенә куана, әнә шул татулыкны-бердәмлекне тагын да ныгыту, һәрбер халыкның иҗади мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен бертигез шартлар тудыру кирәклеге турында фикер йөртә.

Уфада яшәүче шагыйрьләр Мостай Кәрим, Наҗар Нәҗми, Әнгам Атнабай, Марат Кәримовлар янына ашкынып кайта иде ул. Дуслар белән бер күрешү үзе бер гомер икәнлеген аңлап яшәде. Чөнки монда аны беләләр, үз итәләр, китапларын чыгаралар, җырларын җырлыйлар, үз шагыйрьләре итеп саныйлар.

Башкортстан туфрагында туган Илдар Юзеевтан башка татар әдәбиятын күз алдына да китереп булмый. Аның иҗаты әллә каян аерылып тора. Татар әдәбиятының горурлыгы ул. Башкортстан да аның белән хаклы рәвештә горурлана. Ике халыкның да шагыйре ул. Ике тугандаш халыкның үзара бүлешер әйбере юк, алар бер тамырдан үсеп чыкканнар. Дуслык, туганлык хисләрен тормышның ыгы-зыгылары каплап китәргә тиеш түгел. Әгәр шуның киресен эшлибез икән, ике милләт тә үзаллы үсешен югалтачак.

Казаны да, Уфасы да —
Безнең туган як бит ул, —

дигән шигырь юллары да бар бит аның.

И.Юзеев — җырчы шагыйрь. Ул үзенең туган ягын, туып үскән Гәрә елгасы буйларын сагынып кайта иде, аларга багышлап шигырьләр язды, шул шигырьләрен композиторлар көйгә салды. «Җыр картаймый, җыр яши, җыр дәвам итә», — дигән иде И.Юзеев. Җырга, моңга мәхәббәт — табигый матурлыкка, туган җиргә мәхәббәтнең бер чагылышы ул:

Әйтәләр якташлар: син — җырчы,
Туган як турында җыр чыгар.
Белмиләр: үзләре җырчылар
Каеннар, усаклар, чыршылар.

Туган ягының сихри матурлыгы, чылтырап аккан чишмә тавышлары үсмер чагыннан ук шагыйрьнең күңеленә юылмаслык моң булып сеңеп калган. Менә шуның өчен аның шигырьләреннән мәтрүшкәләр исе килә.

Үзенең туган җиренә — Яңавыл җиренә, аның халкына, аерым кешеләренә шагыйрьнең туганнарча мөнәсәбәте күпсанлы әсәрләрендә ачык күренә. Аларның барысына да тукталып тормыйча, тик «Минем Яңавылым» исемле шигырен генә алыйк. Ул яңавыллыларның уңышына горурланып кына калмый, шушы уңышларны яклап, алга, яктыга да чакыра.

Ул якташларның һәр уңышына куанып, кимчелекләре өчен борчылып, туган ягының киләчәге өчен җан атып яшәде.

Әйе, сагынып сөйләрлек хатирәләрне, хәл-вакыйгаларны Илдар Юзеев белән аз кичермәдек. Олы әдип белән сәгатьләр буе сөйләшеп утырганым булды. Илдар абыйның үз авызыннан өр-яңа

шигырьләрен ишеткәнем бар. Үзәкләргә үтеп керерлек итеп өздереп гармунда уйнаганын тыңлаганым бар. Күңелемә дә, рухыма да якын зат иде. Үсмер чакларымда йотлыгып укыган «Таныш моңнар» поэмасы, дистәләгән еллар үтеп, чәчләремә чал төшкәч тә һаман да исемнән чыкмый. Олы шагыйрьнең шигъриятенә гашыйк булу аркасында минем күңелемдә шигърият аерылгысыз моңдашым, рухи юлдашым булды. Авыр минутларда мин кулыма аның китапларын алам. Аларны укып җаныма шифалы дәва тапкан кебек булам.

Илдар Юзеевның тормышы һәм иҗаты районыбыз язмышы белән аерылгысыз булып үрелгән. Ничә еллар буенча якташларына олы шатлык бүләк итеп, рухи дөньяларын баетып, көч-куәт, дәрт-дәрман биреп яшәде ул.

Без аның һәрвакыт акыллы фикерләрен, җылы мөнәсәбәтен тойдык. Гомере буе ул үзенең изге тойгыларын, күңел энҗеләрен халык талантлары белән бүлеште. Шагыйрә Кәүсәрия Шәфыйкова язмышында да сизелерлек якты эз калдырган игелекле остазларның берсе ул. Якташларына олы терәк булган, яшь каләмдәшләренә ихлас ярдәм кулы сузган көчле ихтыярлы, туры сүзле кеше, милли әдәбиятыбызның киләчәген кайгырткан фикерле, искиткеч талантлы халык шагыйре иде.

Туган якларына кайткач, Илдар Юзеев янып-ялкынланып чыгыш ясаганда, Яңавыл тамашачылары аны йотлыгып тыңлады, тамашачыларның кайнар алкышларыннан якты заллар зыңлап торды. Инде күп кенә еллар узса да, әнә шул көннәрнең якты хатирәләре йөрәк түрендә саклана. Әйе, һич тә онытылмаслык минутлар кичердем мин шул чакта. Аның соклангыч әсәрләре минем йөрәк түрендә, ул кабызган шигърият учагының ялкыннарында әле дә җылынам. Ул учак минем күңелемдә сүнми дә, сүрелми дә.

Илдар Юзеев районның һәр авылында, хезмәт коллективларында булды, аның китаплары гаилә китапханәләрендә иң укылышлы, кадерле басмага әйләнде. Гади савучы, игенчедән башлап мәктәп укытучысына, пенсионерга кадәр аның шигырьләрен яттан беләләр. Очрашулар вакытында шагыйрьгә кушылып залдан аның шигырьләрен укыйлар иде.

Яңавыл халкы мәхәббәте, Илдар Юзеев күңелендә чәчкә атып, аның иҗатын аеруча җимешле иткән дисәк тә хаталанмабыз, чөнки аның күпме гүзәл әсәрләренә Яңавыл җире илһам биргән.

Халык арасында киң танылу алган «Гашыйклар тавы» Яңавыл җирендә туган, һәм без моның белән чиксез горурланабыз.

Язгы кыр эшләре, урып-җыю чорларында игенчеләрнең хезмәтен данлап оештырылган әдәби-музыкаль тапшыруларыбызның берәрсе Илдар Юзеевның шигырьләреннән башка үтте микән?!

Бездә һәр бәйрәм саен клубта, мәдәният йортларында үзешчәннәр тарафыннан пьеса кую гадәткә кергән. Аның пьесалары һәр елны авыл мәдәният йортларында бер кабат күрсәтелеп чыга диярлек. Драма әсәрләре язылган китаплары вакытыннан алда тузып, өзгәләнеп бетә.

Районда Илдар Юзеевның 70 яшьлек юбилеена багышланган кичәләр уздырылды. Шушы уңай белән олы әдипнең тормыш һәм иҗат юлына багышланган мәкаләләр, истәлекләр, хатирәләр дөнья күрде. Зәңгәр экран аша шагыйрьгә багышланган хәтердә калырлык тапшырулар оештырылды.

Илдар Юзеевның йөрәк түреннән ургылып чыккан моңлы җырлары бүген дә яңгырап тора.

Район халкы аның иҗат җимешләре аша рухи ләззәт, үзенә тормыш сабагы ала. Мәктәпләрдә, клуб һәм китапханәләрдә аның шигырьләрен сәнгатьле уку буенча конкурслар, Ямады авылында «Авылдашыбыз — безнең горурлыгыбыз» дигән темаларга ачык дәресләр үткәрелә. Дәресләрдә кулланылган һәр өзек, һәр җөмлә балалар күңеленә изгелек орлыклары чәчә. Шул тәэсирдә алар иншалар, шигырьләр язалар.

Илдар Юзеевның китапларын яше-карты кызыксынып укый. Бу аяусыз, болгавыр заманда да эзләп алып укырлык яхшы шигырь язу бәхете сирәк шагыйрьләр өлешенә генә төшәдер. Әнә шундый сирәк шагыйрьләрнең берсе ул Илдар Юзеев.

1991 елның 17 августында Татарстан һәм Башкортстан Республикалары арасында дуслык һәм тугандашлык килешүе төзелде.

Ә инде 1992 елда Казан шәһәрендә «Яңавыл» якташлык җәмгыяте төзелеп, аның беренче президенты итеп якташыбыз Илдар Юзеев сайланды. Һәм китапханәләр белән тыгыз бәйләнеш урнаштырылган 2001 елда ул «Уйлый күңелем төрлесен», «Калдыр, аккош, каурыеңны» дигән 20 дән артык китабын бүләк итте.

Яңавыл үзәкләштерелгән китапханә системасында ел да Илдар Юзеевның иҗатына багышланган сәнгатьле уку конкурсы игълан ителә. Чараның максаты — шагыйрь иҗатына укучыларны күбрәк җәлеп итү. Конкурста 15 яшьтән алып 65 кә кадәрге шигырь сөючеләр катнаша ала, әсәрләр татар һәм рус телләрендә укыла. Сәнгатьле уку конкурсы сентябрь аеннан алып гыйнвар аена хәтле ике этапта үткәрелә. Аның беренче этабы (ул халыкта зур кызыксыну уяткан) авыл китапханәләрендә үтә, ә икенчесе — Яңавыл үзәк район китапханәсендә.

Икенче этапта Яңавыл үзәк район китапханәсендә призлы урын яулаучыга «Илдар Юзеев шигырьләрен иң оста сөйләүче» призы бирелә.

Барлык китапханәләрдә дә Илдар Юзеевның иҗатына багышланган, вакытлы матбугатта һәм журналларда басылган материалларны «Яңавыл җирендә туган» дигән аерым папкаларга туплыйлар.

Яңавыл тарихи-туган якны өйрәнү музее, Ямады авыл китапханәсе, мәктәбе аңа багышланган экспонатларны саклый. Ямады авылының бер урамына Илдар Юзеев исеме бирелгән.

Ел да уздырылган «Җиңү салюты» концертларында Яңавылның барлык хезмәт коллективлары чыгыш ясый, һәвәскәрләр Илдар Юзеевның шигырьләрен яттан сөйли, аның шигырьләренә язылган җырларны башкара.

Яхшы итеп төзекләндерелгән Татар Урадасы авылы чишмәсенә төшкән юлда да шагыйрь Илдар Юзеев сүзләре күзгә чалынмый калмас:

Сусыз калсак әгәр, корыячак
Табигатьтән иркә гөлебез.
Җилләр иссен, назлы гөлләр үссен, —
Чишмәләрнең кадерен белегез!

Моны һәр су чыганагы алдына куярга мөмкин.

Сандугач авылы янындагы чишмә янында да Илдар Юзеев шигыреннән өзек язылып элеп куелган:

Яшик, дуслар, озак, мәңге...
Матур үтсен һәрбер көнебез.
Кемдер зарыгып бер йотым су сорый —
Чишмәләрнең кадерен белегез! —

дигән юллар барлык кешеләр күңелендә юылмаслык булып калырлык.

Олы юл буйларында да аның туган якка багышланган әсәрләреннән өзекләр белән очрашасың.

Илдар Юзеев танылган шагыйрь булудан тыш бик күпләрнең якын дусты, ышанычлы сердәше, фикердәше дә, шулай ук сәнгать юлына аяк баскан яшь шагыйрьләрнең һәм җырчыларның тәҗрибәле остазы, ярдәмчесе дә иде. Үзенең шушы асыл кешелек сыйфатлары белән әдәбиятка, сәнгатькә рухи байлык биреп яшәде. Бөтен гомерен ул яшәү өчен көрәшеп үткәрде. Гомере буе төшенкелеккә бирелмичә яшәде һәм туктаусыз иҗат итте.

Илдар Юзеев — матурлык җырчысы. Ул җирдә мәгънәле итеп яшәүнең батырлык та, матурлык та икәнен үзенең тормышы, үлемсез әсәрләре белән раслады. Аның рух ныклыгы, күңел байлыгы тормышка, кешеләргә ямь бирә, яхшылыкны, яктылыкны арттыра. Аңардан таралган нур күңелләрне сафландыра, җылыта. Аның иҗат җимешләре әллә ничә буын китап укучыларына, киләчәк буынга рухи азык булыр, чөнки ул иҗат үлемсез, һәм шушы үлемсез әсәрләре белән шагыйрь үзенә мәңгелек һәйкәл коеп куйды.

*Яңавыл, 2007*

**ФИРАЗ ХАРИСОВ**

# Моңнар җырчысы

Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеевның исеме милли әдәбиятыбыз-сәнгатебез тарихына алтын хәрефләр белән язылды. Яңавыл районында туып үскән бик билгеле һәм күркәм якташларыбыз арасында ул — аерым урын алып торган шәхес, берсеннән-берсе матур, нечкә лиризм, тирән моң, хис-фикерләр бердәмлегенә ия булган әсәрләр авторы. Ул тудырган лиро-эпик әсәрләр күп еллар дәвамында радио һәм телевидение репертуарында үзенең лаеклы урынын алып тора. Алар тупланган җыентыкларның затлы күңел ризыгы буларак халкыбыз тарафыннан яратып кабул ителүе үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли түгелме?!

Моңнар җырчысы Илдар абый — халкыбыз күңеленә үтеп кергән, аның иң нечкә кылларын тибрәткән, драматик жанрда язылган ике дистәдән артык әсәр авторы да. Аларның исемнәре дә шигырь һәм поэмаларындагы кебек җырлап тора: «Сандугачлар килгән безгә», «Янар чәчәк», «Кыр казлары артыннан», «Ак калфакны төшердем кулдан», «Гашыйклар тавы» һ.б. Шагыйрь иҗат иткән һәрбер әсәр, дүртьюллыкмы ул, шигырьме, поэмамы йә, булмаса, драматик әсәрме, бервакытта да укучыны, тыңлаучыны, тамашачыны битараф калдырмый: уйландыра, кичерешләр дулкынында йөздерә, кешегә оптимистик рух өсти. Илдар абый иҗатына мөкиббән китүчеләр арасында төрле яшьтәге һөнәр ияләре бар. Безнең уебызча, алар барысы да шагыйрь алдында һәм аның иҗат җимешләре булган әсәрләре алдында баш ияләр. Без тагын бер нәрсәгә шаһит: аңарда бөек талант белән бергә кешелеклелек, гаҗәеп дәрәҗәдәге тыйнаклык, игътибарлылык, кешеләргә карата самими эчкерсез мөнәсәбәт кебек сыйфатлар янәшә бергә яши. Инде шактый еллар Илдар абыйның иҗат җимешләре елның иң күп укыла торган әсәрләре исемлегендә алдынгы урыннарның берсен алып килә. Төрле яшьтәге укучыларның, бигрәк тә балаларның, шагыйрь иҗатына биргән бәясе бик зур әһәмияткә ия, чөнки алар — безнең тормышыбызның һәм яшәү рәвешенең көзгесе бит!

Узган гасырның соңгы унъеллыгындагы иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр Илдар абыйны да читләтеп узмады. Иҗатында яңа темалар, халкыбыз-милләтебез язмышы турында фәлсәфи уйланулар үз урынын тапты. Заман агышын тоеп, әкрен генә атлап, үз юлыннан читкә каерылмыйча, кая юнәлсә дә, юлының ачык булуын һәм җырының да һич бетәрлек түгеллеген ассызыклап яши бирде хөрмәтле якташыбыз!

Шагыйрьнең әсәрләре төрле жанрда язылган булса да, алар бер-берсе белән гаҗәеп дәрәҗәдә дустанә яши. Лира белән Драмадан тыш әле тагын шактый нәфис һәм тәҗрибәле Проза ханым да «көтәм...» дип әйткән, ди. Һәм, чынлап та, соңгы елларда төрле әдәби журналларда басылган истәлекләр, парча һәм нәсерләр — шуның ачык мисалы. Аларны да укучылар көтеп алалар һәм яратып укыйлар.

Илдар абый иҗатының тагын бер үзенчәлекле ягы бар: аның бик күп шигырьләре халкыбыз күңеленә җыр булып кереп калды һәм бу хәзер дә шулай. Классик композиторларыбыз Җ.Фәйзи, С.Садыйкова, замандашларыбыздан М.Имашев, М.Яруллин, С.Ибраһимов һ.б. язган җырлар инде күптән халкыбыз күңелен яулап алды. Ул бит хәтта үзенә карата бик үк дустанә мөнәсәбәттә булмаган кешеләргә багышлап та бик матур, тирән мәгънәле әсәрләр язды, аларга «озын гомер һәм тыныч төн, яхшы күрше һәм якты йөз, әйбәт кәеф һәм көләч көн» теләп, шигырьләренең тәрбияләү чарасы булганлыгын күп тапкырлар раслады.

**ЭРОТ ЗАРИПОВ**

# Хәтердә калган мизгелләр

Үткән гасырның 50 нче елларында Башкортстанның төньягында урнашкан Яңавыл районының Ямады авылы әле цивилизация кагылып бозылмаган экологик чиста зонада утыра иде. Ярты авылны урап кечкенә Гәрә елгасы ага. Чиста сулы, балыкка бай, җәй буе су коенырга мөмкинлек бар. Кәшти тугай, Тирән тугай, Бур тау тугае җикән камышлар белән тулган, чишмә чыга торган текә ярлары безгә серле табигать почмаклары булып тоела иде. Ямады авылын чорнап алган калкулыклар: Япон җире, Югәмәш тавы, Урта көек, Зәйнәш көек, Мүксаз, Буртау һәм башка матур урыннарда авыл балалары, җәй буена җиләк-җимеш җыеп, вакытларын табигать кочагында уздыралар.

Ямады урта мәктәбе зур мәктәп диеп саналганга, тирә-яктагы күп авыллардан килеп укыдылар. Мәктәпне тәмамлаучыларның күбесе укуларын төрле шәһәрләрдә институтларда дәвам иттеләр. Аларның күбесе Ямады авылы балалары. Җәй саен студентлар Ямадыга җәйге каникулларга кайталар. Алар арасында Казан дәүләт педагогия институтында укучы Илдар Юзеев та бар.

Ул ничек истә калган? Беренчедән, аның иң яраткан кумир-шагыйре — Һади Такташ. Ул һәрвакыт аның шигырьләрен яттан укырга әзер. Хәтта аның тышкы кыяфәте — чәчләрен тарап йөрүләре, моңлы күз карашлары — Такташны хәтерләтә. Икенчедән, мин Илдар абыйны ул вакытларда кулында гармунсыз күргәнем булмады. Ул һәрвакыт гармун уйнап йөргән кебек истә калган.

Кайткан студентлар ул заманда бик актив рәвештә авыл тормышында катнашалар. Үзләренчә шаяртып «ЯСОС» (Ямадинский Союз Отдыхающих Студентов) исемле группа оештырып төрле эшләр башкардылар. Ямадыда һәм күрше авылларда төрле концертлар оештырдылар, колхозга зур булышлык күрсәттеләр. Авыл җирләрендә билгеле булмаган спорт төрләре — волейбол, футбол кебек уен ярышларын оештырдылар. Еш кына табигать кочагына ял итәргә чыгалар. Алар булган җирдә һәрвакыт уен-көлке, тапкыр сүзләр! Әлбәттә, бу компаниядә Илдар абый өздереп гармун уйный. Аның авызыннан әледән-әле авылда булган төрле вакыйгалар турында импровизация рәвешендә әллә нинди көлке сүзләр, шигырьләр, эпиграммалар ишетелеп тора. Ә без, бала-чагалар, читтән генә тыңлап, алар сөйләгән бер сүзне дә, бер фикерне дә югалтмыйча истә калдырырга тырышабыз.

Минем фикеремчә, бу 50 нче елларда яшәгән студентларның киләчәктә күренекле шәхесләр булуына менә шушы авыл табигате кочагында үткән мәгънәле яшьлекләре зур роль уйнагандыр. Бу фикер Илдар Юзеевның соңгы елларда язылган «Ямады» исемле шигырендәге бер өзектә бик төгәл һәм ышандырырлык дөрес итеп чагылдырылган:

...Оялмадык, горурландык кына
Борынгылар биргән исемнән,
Ямадыны эзләп табалабыз
Болындагы чәчәк исеннән.
Йөрәк ертыкларын сиздермичә,
Без шаярдык, көлдек, уйнадык,
Ямауларны бездән соңгыларга
Калдырмаска диеп уйладык, —
Тик җыр калдырырга уйладык.
Ямаулыклар берчак онытылыр,
Мәзәк булып кына калырлар,
Ямадыны ямаулардан түгел,
Без калдырган җырдан танырлар!

*20 декабрь, 2006*

**САЛАВАТ ЮЗЕЕВ**

# Слово об отце

Говорят, поэзия — дело молодое. Один современный поэт сказал, что даже на семнадцатилетних поэтов смотрит с подозрением. Конечно, он слегка сгустил краски, но по сути своей он прав. Писать стихи легче, когда душа еще не отягчена грузом лет. С годами поэты переходят на прозу или еще осваивают какой-нибудь литературный жанр. Не пишется. Но всегда есть исключения из правил. Есть люди, не изменяющие поэзии до последних своих дней. Гёте, Ахматова, Пастернак... Этот ряд можно продолжить. Но я хочу сказать, что к этим счастливчикам, от которых не уходит Слово, принадлежал и мой отец, Ильдар Юзеев. Почему я так говорю? Потому что, знаю.

Я помню отца в нашей маленькой квартирке на улице Волгоградской. Ему было, наверно, немногим больше тридцати. Он писал тогда одну из самых известных своих поэм, пытаясь уединиться за письменным столом. Мы же — кроме меня, в этом действии присутствовали все соседские дети — носились вокруг него как чертенята, создавая атмосферу конца света. Но он, как ни странно, нисколько не был этим отягчен, его перо носилось по бумаге без остановки, я скажу больше — не поэт в таких условиях ничего не напишет.

Еще я помню отца уже в период, близкий к дням последним. Летнее утро на даче. Он говорит нам — встающим с постели: «Пока вы спите, я уже два стихотворения написал». Сам он вставал очень рано, с птицами, наверно, в эти часы душа открыта природе, свету и Слову (видимо Всевышний для своих избранников устанавливает свой режим).

Я помню отца в Доме творчества писателей в Коктебеле, когда он вытаскивает письменный стол на открытую веранду и садится работать. В это время остальные писатели загорают и нежатся в теплых морских волнах, а, собственно, чего скрывать — из-за этого сюда в Крым и едут. Он же — с пером в руке — смотрится здесь как-то несуразно, не к месту, и даже я испытываю за него неловкость.

Я помню отца в самые разные дни. Его лицо всегда было освещено приходящим Словом. Он знал о своем Даре. Знал и то, что этот Дар надо отработать, он несет за него ответственность. Перед собственной совестью, перед народом. Он любил свой народ, и эта любовь была и остается взаимной.

Так получилось, что я тоже имею отношение к творчеству. Я писал когда-то и стихи, но вынужден признать, что это было делом молодости, и тот ряд счастливых исключений оказался для меня недосягаем. Как-то одна журналистка спросила — помогал ли мне отец? Я не совсем понял, что имелось в виду, но, думаю, она подразумевала, что в творчестве можно помогать так же, как помогают, скажем, разбирать автомобильный двигатель или вспахивать поле. Нет, ответил я, не помогал и не учил. Поскольку он прекрасно знал, что творчеству научить нельзя. Он сделал для меня нечто гораздо более важное. Он научил меня любить собственный народ, его культуру. Он привил мне любовь к книге, к печатному слову.

У меня за плечами была уже пара книг прозы, и меня потянуло в сторону кино, которое, хочешь не хочешь, отнимает огромное количество энергии. Отец, видя мои метания, порой напоминал мне: «Главное — литература. Все остальное должно быть на втором плане». Сейчас я полностью с ним согласен. Слово — прежде всего. Все остальное — вторично.

«Человек по-настоящему умирает тогда, когда его забывают», — не знаю, кто это сказал, потому что, есть фразы настолько естественные, что не задумываешься об их авторстве.

Ильдара Юзеева не забудут.

Люди помнят ушедшего, так повелось издавна, в христианстве в память о нем ставят свечку, в мусульманстве — читают светлую молитву. Душа ушедшего слышит нас и всегда ждет нашего к ней обращения. Придет время, и, как это ни горько, многих из нас уже никто не вспомнит.

Иное дело, когда речь идет о творцах. Мы читаем книгу писателя, который оставил этот мир много лет назад, мы вступаем с ним в контакт, мы обращаемся к его душе, и она слышит это обращение.

Мы исполняем стихи ушедшего поэта, и он, из своих запредельных территорий, с благодарностью внимает нам.

Люди поют песни на слова Ильдара Юзеева, слова, которые стали народными, и, думаю, его душа, отзываясь, пребывает в блаженстве.

Это и есть настоящее бессмертие.

**САМАТ ЮЗЕЕВ**

# Минем дәү әтием

Минем дәү әтием йөрәгемдә мәңге калыр. Аның табигатен, үзенчәлеген, күз карашын, йомшак күңелен беркайчан да оныта алмамын.

Әтием белән әнием көне буе эштә була иде, шуңа күрә мин күбрәк дәү әтием һәм дәү әнием белән кала идем. Һәм, гомумән, дәү әтием минем иң беренче тәрбиячем иде! Ул мине балачакта бик күп нәрсәгә өйрәтте, шуның өчен мин аңа бик рәхмәтле. Ул мине шахмат уйнарга, өстәл янында үземне дөрес тотарга, мәчене сыйпарга өйрәтте. Ләкин иң зур рәхмәтем татар телендә укырга өйрәткән өчен.

Хәтерлим, ничек ул мине көн саен бишәр бит татар китабын укырга мәҗбүр итә иде. Шул вакытта (миңа биш-алты яшь иде) мин аңа ачулана идем, ләкин хәзер аңлыйм — юкка! Дәү әти укыткан китаплар бик кызыклы иделәр. Хуҗа Насретдин, батырлар, төрле аждаһалар турында. «Борын-борын заманда...», «Яшәгән, ди, булган, ди...» — әйе шул, бу сүзләр һәрвакыт дәү әтием белән ассоциацияләнә.

Татар китаплары укудан башка да без бик күп кызыклы уеннар тапкан идек. Минем иң яраткан уеным телефоннан сөйләшү иде. Кайвакыт без дәү әтием белән ярты көн буе шул уенны уйный идек.

**АЙДАР ЮЗИЕВ**

# Штрихи к портрету Ильдара абый

Уже давно нет в живых моего отца Нила Юзиева (1931–1996) — старшего брата Ильдара абый, ушедшего из жизни относительно недавно. А кажется, канула в Лету вечность. Если и существует жизнь в горнем мире, то души братьев, несомненно, там встретятся и опять будут вестись диалоги о жизни, творчестве. Два родных брата — Нил и Ильдар — всегда по жизни шли вместе: испытали все тяжести деревенской жизни в трудные военные и послевоенные годы; учились в Казани в разных гуманитарных вузах; занялись литературным творчеством — Нил учил методике написания стиха, Ильдар стал поэтом. На этом тернистом литературном пути они достигли блистательных успехов: оба стали лауреатами Государственной премии имени Г.Тукая — для татарской культуры случай уникальный.

Ильдар абый стал для меня — особенно после смерти отца — аксакалом рода Юзеевых, вобравший в себя мудрость целого поколения. Он постиг философскую суть бытия и пытался передать смысл жизни и в своем творчестве. Его поэмы отличались глубиной анализа характера героев, философским осмыслением действительности, драматургические же произведения имели философский подтекст, требовали от читателя (режиссера) определенных усилий для постижения сути замысла автора. В этом и заключалась цель творца — добиться того, чтобы читатель сопереживал героям, «включился» в контекст отображаемой действительности и только тогда у него может возникнуть чувство сопричастности с происходящим. Одна из задач искусства как раз и состоит в том, чтобы читатель увидел себя в контексте произведения. Эта задача по силам только талантливым поэтам, драматургам, одним из которых и был Ильдар Юзеев.

Казалось, Ильдар абый будет еще долго рядом с нами, думал: успею еще поговорить по душам, расспросить о некоторых фактах его биографии. Но не все происходит в жизни так, как мы хотим… Многое так и осталось недосказанным, невыясненным. И все же я прекрасно помню моего родного дядю.

Ильдар абый, будучи человеком публичным, почитаемым, известным, никогда не кичился своими многочисленными регалиями, был прост в общении, любил пошутить. Его шутки часто становились афоризмами и быстро распространялись в писательской среде, поскольку Ильдар абый обладал талантом быстро, емко и точно — порой одним четверостишием — охарактеризовать того или иного человека. Причем говорил он медленно, не повышая голоса, облекая мысль в стихотворную форму и только в конце фразы, где был заключен основной смысл, его лицо озаряла загадочная улыбка. Окружающие доброжелательно реагировали на его эпиграммы, потому что и его шутки были доброжелательными и необидными. Афоризмы от Ильдара абый передавались из уст в уста, печатались в газетах и журналах.

Ильдар абый, как и большинство творческих людей, любил творить в тиши кабинета. Об этом говорила и его супруга — Тафтиля апа, которая была единственной женщиной, с которой он преодолел все тяжести и перипетии нашей трудной жизни. Не всегда у поэта были благоприятные условия для творчества, но в новой квартире, которую он получил незадолго до кончины, просторной и благоустроенной, была та самая любимая им тишина. Меня поразили слова Ильдара абый, сказанные в ответ на мои лестные отзывы о его новой среде обитания: «Айдар, самое ценное в этой квартире — тишина, а значит, и идеальная возможность для работы. Мне выпало счастье хотя бы на старости лет поработать в тиши кабинета».

К сожалению, судьба распорядилась иначе. В конце концов болезнь, которая все чаще напоминала о себе, оказалась сильней творца. Последняя песня поэта осталась недопетой. Но нам, его потомкам, осталась в наследство его поэзия, прекрасные песни, исполняемые народом, драматургические произведения. Многое по-новому предстоит оценить в наследии Ильдара Юзеева. Некоторые его драматургические произведения, незаслуженно обойденные вниманием режиссеров, еще ждут театральных постановок. Видимо, должно пройти некоторое время.

Свет лучезарной поэзии Ильдара Юзеева будет всегда озарять души многочисленных почитателей его поэтического таланта! Ильдар абый и сейчас незримо присутствует вместе с нами. Дело отца продолжает его сын Салават — писатель, сценарист, режиссер.

**ИЛДАР ЮЗЕЕВ**

* * *

Гадәт-холкым белән — кыр казы мин:
очам,
йөзәм,
китәм
һәм кайтам...
Гадәт-холкым белән — кыр казы мин:
сагынам,
түзәм,
әрним,
югалтам...
Гадәт-холкым белән — кыр казы мин:
очмаучылар
сәер, ят алар...
Бәлки,
мине
аңлый алмаучылар
беркөн йөрәгемә атарлар...
Гадәт-холкым белән — кыр казы мин:
егылып
төшәрмен дә
сызланып,
җан бирермен
соңгы сулышымда,
очалмаганнарны кызганып...
*1982*

# Ямады

«Сез каян?» диеп сорасалар әгәр,
Без оялып башны имибез,
«Әйтүе дә бик уңайсыз инде,
Ямадыдан гына...» димибез.
Безне әрәм итми, адәм иткән
Серле бер авыл ул — Ямады.
Чит-ятларга бер дә сиздермибез,
Булса да ул кырык ямаулы.
Безнекеләр бөтен тирә-якта
Ямаучылар белән дан алган.
Әткәйләрдән калган гимнастерка
Әнкәй кулы белән ямалган.
Якын күреп, каян килсәләр дә,
Иң кадерле кунак саныйбыз,
Казан төбе әгәр тишек икән,
Сер бирмибез, бик тиз ямыйбыз!
Үз җиребез үзебезгә якын.
Булмасак та яный торганнар,
Явыз ният белән килгәннәрнең
Колак төбен ямый торганнар!
Киленнәр дә бездән зарланмыйлар,
Килә алмый безгә андыйлар.
Казанда да бер дә боекмыйлар, —
Тишек оекларны ямыйлар.
Хәерчеләр түгел, үзебезне
Иң бай кеше итеп санарлык,
Ямаулыклар һич бетәрлек түгел,
Җирнең бар ертыгын ямарлык!
Оялмадык, горурландык кына
Борынгылар биргән исемнән,
Ямадыны эзләп табалабыз
Болындагы чәчәк исеннән.
Йөрәк ертыкларын сиздермичә,
Без шаярдык, көлдек, уйнадык,
Ямауларны бездән соңгыларга
Калдырмаска диеп уйладык, —
Тик җыр калдырырга уйладык.
Ямаулыклар берчак онтылырлар,
Мәзәк булып кына калырлар,
Ямадыны ямаулардан түгел,
Без калдырган җырдан таныралар!

*1996*

* * *

Мәхәббәт, нишләттең син мине?..
Хисләрне яңарттың,
Йолдызга караттың,
Күңелне бай иттең,
Телемне бал иттең,
Зиһенне чуалттың,
Биеттең, елаттың,
Өемне гөл иттең,
Кем идем, кем иттең,
Төнемне көн иттең,
Көнемне төн иттең,
Яндырдың — көл иттең...
Нишләттең син мине, мәхәббәт?
Тилерттең, шаштырдың,
Күкләргә аштырдың,
Сагышлар уяттың,
Наз гына оялттың,
Кабыздың, сүндердең,
Тыңлаттың, күндердең.
Чәчәкләр өздердең,
Сагынгач, түздердең,
Ялгызым калдырдың,
Татлы яшь тамдырдың,
Күңелне нечкәрттең...
Мәхәббәт, син мине нишләттең?..

*1971*

# Шагыйрьләр нигә картаймый?

Шагыйрьләр нигә картаймый?
Дөнья уе — башында.
Асыл кошлар затыннан ул,
Сандугачлар яшендә.

Болай да кыска гомерне
Мәгънәле итәсе бар.
Юлчы булып дөнья буйлап
Сәфәрләр китәсе бар.

Тормыш дигән әкиятнең
Йомгагын сүтәсе бар.
Фатир сорап күңелләргә
Тәрәзә чиртәсе бар.

Картаеп сүнгән йөрәкнең
Бозларын эртәсе бар.
Үксезләрнең күзләреннән
Яшьләрен сөртәсе бар.

Гашыйкларны кавыштырып,
Туенда биисе бар.
Сабыйларның бишекләрен
Тирбәтеп йөрисе бар.

Сандугач киткән күңелгә
Оялап сайрыйсы бар.
Дошман йөрәген тишәрлек

Хәнҗәр-сүз сайлыйсы бар.

Юлда адашып калганга
Маяклар тезәсе бар.
Үзеңне адаштырсалар,
Бирешми түзәсе бар.

Халык кайгырганда — елый,
Көлгәндә — көләсе бар.
Ил булып утка керәсе,
Ир булып үләсе бар.

Оясы юк, мөлкәте юк,
Каләме, биштәре бар.
Күңелләрне тетрәтерлек
Җырлары-хисләре бар.
*1973*

## Болытлар артында Кояш бар!

Усаллар, әрсезләр заманы...
Нәселдә һәммәбез юашлар.
Бабабыз әйтергә яраткан:
«Болытлар артында Кояш бар!»
Өметне югалту бик ансат,
Ни генә күрмәде бу башлар...
Башларны калкытты тик бер нур:
Болытлар артында Кояш бар!
Караңгы, болытлы күзләрдән
Сибелер шатлыклы күз яшьләр...
Көн килер, дөньялар яктырыр:
Болытлар артында Кояш бар!

*1991*

## Кошлар юлы

Былбыл булалмадым дип тормадым,
Кошлар юлын сайладым, —
Таң алдыннан өзелеп бер җырладым —
Күңелем тулып сайрадым.
Мин дә сезнең кебек газапланам,
Кошлар, гаеп итмәссез,
Яз таңында мин дә канатланам,
Бәлки, ташлап китмәссез?..
Күрешербезме, юкмы бу дөньяда?
Анысы — язмыш кулында...
Очрашасы иде Мәңгелектә —
Ерак кошлар юлында...
*1991*

## Ян, күңел!

Беренче дә булмый, бишенче дә...
Мәхәббәт ул салкын сан түгел,
Кайнар яшьлектә дә, картлыкта да
Сүнмә, дөрлә, мәңге ян, күңел!
Ваклап сатылмый да, алынмый да,
Мәхәббәт ул товар, мал түгел.
Дөнья малларыннан өстен калып,
Сүнмә, дөрлә, мәңге ян, күңел!
Җан серләрен илгә кычкырмыйлар,
Мәхәббәт ул оран, дан түгел,
Бик тирәндә, эчтән генә сызылып
Сүнмә, дөрлә, мәңге ян, күңел!..

*1991*

# Хәсрәтле җыр

Минутлап, сәгатьләп
җыелган гомеремнең
белмәдем кадерен, —
син хаклы, бәгырем...
Минутлап, сәгатьләп
сүтелгән гомеремнең
йомгагы шул булды:
йөрәгем — көрәшче,
кул-аяк кол булды...
Минутлап, сәгатьләп
таралган гомеремнең
хәсрәтле азагын
коллыктан ычкынган
кул белән язамын...

*1991*

* * *

Әллә нигә йөрәк яна бу айда...
Гармуннарым, уйныйм әле, сез кайда?
Күңел тоя гомеремнең баешын,
Өзим әле гармуннарның каешын!
Уйныйм яшьлек, уйныйм картлык көен дә...
Гармуннарның берсе дә юк өемдә.
Искә төште: дус-ишләрдә калдырдым,
Гармун уйнап күпме йөрәк яндырдым.
Дусларымны юатырга теләдем,
Инде тәмам янып бетте йөрәгем.
Бер гомергә җитәр әйдә калганы,
Кирәк түгел миңа дусның ялганы!
Ялгыз башың — калган җаның сүрелер,
Дуслар белән бер утыру — бер гомер!
Мин бәхетле: дуслар белән күрештем,
Үз моңымны кызганмыйча бүлештем.
Әллә нигә йөрәк яна бу айда,
Гармуннарым, киттем эзләп, сез кайда?
Өзим әле гармунымның каешын,
Онытырмын, бәлки, гомерем баешын...

*1991*

* * *

Юк инде гамьсез шаяру
Һәм көлеш.
Бөкерәйдем... картайганчы...
Яшь килеш.
Ерак-ерак дәверләрдән
Килгәндер.
Җиде бабамның рәвеше
Сеңгәндер.
Ничә гасыр бөгелгән дә
Сыгылган.
Күпмеләре авырлыктан
Егылган.
Бу сыйфатлар улдан улга
Күчкәннәр...
Турайганның горур башын
Кискәннәр.
Бу гәүдәмне, бәлки, кабер
Турайтыр,
Токымымда «Турайдым!» дип
Кем әйтер?
Үлеп кенә качып булмас
Хурлыктан.
Җирдә кайчан котылырбыз
Коллыктан?
Гомеремне нәселдә кем
Озайтыр,
Гаделсезлек, ялганны кем
Турайтыр?
Дөрес анысы, әлегәчә
Баш исән.
Җәлладларым җиң сызганган,
Баш исәң...
Гәүдәм бөкере, тик шулай да
Баш туры!
Күзләремдә өмет белән
Яшь тулы...
*1991*

# Сагышлы мирас

Булганбыз без эре халык, тере халык.
Гасырларны кичә-кичә вакланганбыз.
Ваклансак та, без һаман да рухи Алып:
Тукай булып, Сәйдәш булып сакланганбыз.
Ни әйтсәң дә, Алыплардан яралганбыз.
Шул нигездә торасыбыз, корасыбыз.
Чәчелгәнбез, сибелгәнбез, таралганбыз.
Бабайларның бик сагышлы мирасы без.
Алып бабай тубалыннан чәчелгәнбез,
Үсмәсен дип чирү булып килгән ятлар.
Өзелмәслек тамырдан без, нәселдән без.
Җанга сеңгән моңсу җырлар, риваятьләр.
Ак син, җырым, Әтил сыман дулкынланып.
Тыңла, бала, шул дулкынны уйга талып.
Бабай менгән рухи үрдән төшә күрмә.
Төшә күрмә, Алыплардан калган халык!
*1995*

* * *

Искитәрлек булмаса да
Башымда акылларым,
Чит итмәде, якын күрде
Дусларым, якыннарым.
Йолдыз алып кайтам, диеп,
Күкләргә атылмадым,
Йөрәк кушканча яшәдем:
Сатмадым, сатылмадым.
Белсәм дә рәхәт яшәргә
Өлешем-хакым барын,
Читләтеп үттем дөньяның
Көмешен-алтыннарын.
Башкортларның сәсәннәрен,
Казакъның акыннарын
Юлдаш иттем. Юлбаш иттем
Йөрәгем ялкыннарын.
Әкрен генә сөйләдем мин,
«Тыңла!» — дип акырмадым.
Ишетте ерак тарафлар,
Үз итте якыннарым.
Искитәрлек түгел дә соң
Башымда акылларым...
Әүлия ук булмасам да,
Дәрвишләр затыннанмын...
*1995*

# Озак яшисегез килсә...

Җырлагыз...
Сәләтем юк, диеп тормагыз!
Авыр булганда да,
Юллар уңганда да
Җырлагыз,
Тавышым юк, диеп тормагыз!
Эчең пошканда да,
Дуслар кушканда да
Җырлагыз,
Кәефем юк, диеп тормагыз!
Җырлагыз,
Күңел тулганда да,
Өмет сулганда да
Җырлагыз,
Җырсыз гомер итеп сулмагыз!
Җырлагыз,
Яшьлек узганда да,
Йөрәк сызганда да
Җырлагыз,
Башыгызны иеп тормагыз!
Җырлагыз,
Бәйрәм иткәндә дә,
Шатлык киткәндә дә,
Гомерегезне сузып җырлагыз,
Җырлагыз!
Тавышым юк, диеп тормагыз,
Тавыш беткәндә дә,
Гомер үткәндә дә,
Эчтән генә... түзеп, җырлагыз,
Җырлагыз!
Үзегезгә үзегез җырлагыз,
Җырлагыз!..
*1995*

# Шом

Нишләр идем, әгәр:
Халкым бәла-каза кичергәндә,
Үз рәхәтем белән чикләнсәм,
Илем йөзен бәйрәм бизәгәндә,
Үз кайгыма кереп бикләнсәм?..
Нишләр идем, әгәр:
Эшем өчен түгел, дәрәҗәле
Постым өчен генә мактални,
Авыр чакта дусларымны сатып,
«Чоры шулай» диеп аклансам?..
Нишләр идем, әгәр:
Толлар-ятимнәргә күзне йомып,
Үзем өчен сарай салдырсам,
Үземнән соң якты рух калдырмый,
Җир йөзендә тик мал калдырсам?..
Нишләр идем, әгәр:
Үзем кичермәслек гөнаһ кылып,
Гомерем буе яшереп сакласам,
Мине өнәмәгән вак җаннарның
Яшерен өметләрен акласам?..
Нишләр идем...

Ә кемнәрдер шулай тын яши, —
Күңелемдә минем шом яши.

*1971*

# Кояшлы хыяллар

Кояшлы яңгыр ява ич.
Җир җылытып там, тамчы!
Хәсрәт яшьләрен киптергән
Тамчы булып тамсамчы!
Күңелем белән көндез — Кояш,
Төннәрен Ай булсамчы,
Елмайган көләч йөзләрне
Гел балкытып торсамчы!
Нурлардан күперләр салып,
Күрештереп торсамчы,
Сөенечләр китерүче
Бер тылсымчы булсамчы!
Сүнгән-сүрелгән җаннарга
Бер тамчы нур булсамчы!

*2004*

**ХӘСӘН ТУФАН**

# Алгы сафтагы шагыйрь

20 нче елларда тынгысыз Такташның әдәбиятка килүе олы вакыйга буларак кабул ителгән иде. Аның кебек үк, беренче адымнарыннан үзенә игътибарны җәлеп итәрлек шагыйрь күренгәнче, шактый озак көтәргә туры килде.

1955 елда шагыйрь Илдар Юзеевның «Таныш моңнар» поэмасы басылып чыкты. Ул шунда ук киң катлам укучылар арасында шөһрәт казанды. Чыннан да, Илдар Юзеев башка бик күп каләмдәшләреннән үзенчәлекле тавышы белән аерылып тора. Бу тавышта Такташ авазы да тоемлана. Илдар Юзеев халык шагыйренең җанга ятышлы традицияләрен остазы туктап калган ноктадан алып китте. Шул ук вакытта ул, шагыйрь буларак, Җәлил шигъриятен дә чит итмәде. Кыскасы, Илдар Юзеев турында, һич тә икеләнмичә, ул — заман шигъриятенең иң матур традицияләрен үзенә туплаган бәхетле шагыйрьләрнең берсе дип әйтәсе килә. Илдар Юзеев иҗатында җылы лирика, героика һәм патетика белән үрелеп, үзенә генә хас стиль барлыкка китерә. Юзеев реализмы романтик ашкыну белән заман яшьләренең бай рухи дөньясын җырлауга юнәлгән.

Минемчә, Илдар Юзеев — без яшәгән көннәрнең көен, аһәңен тапкан шагыйрь. (Бу җәһәттән ул халыкчанлыгы, ихласлыгы, тирән моңы белән әсир иткән Илһам Шакировка бик якын.)

*1968*

**СИБГАТ ХӘКИМ**

# Янар чәчәкләрнең яктысы

Мин сугыштан кайткач очраткан яшь шагыйрьләрнең берсе Илдар Юзеев булды. Сугыштан соң миңа бар да сәер иде. Арча белән Әтнә арасында май аенда бәрәңге утыртып ятучыларны күреп тә гаҗәпләнеп торган идем. Сугыш иң зур вакыйга булып калган, әйтерсең шуннан башка эш, һөнәр — бик кечкенә нәрсә. Бәрәңге утырту нииндидер яңалык булып тоелды миңа. Мин сугышта шагыйрьлегемне дә оныта язган идем инде. Дөресен әйткәндә, дөньяга яңа туган кеше итеп сиздем үземне. Белмәгән яшь шагыйрьне очрату да миңа сәер иде. Шуның өстенә мин иске буын шагыйрьләренә күнеккән кеше. Такташлар, Туфаннар, Җәлилләр, Кутуйлар, Фатих Кәрим, Әхмәт Фәйзиләргә ияләшкән кеше. Минем күз алдымда һаман шулар әле. Барысы да исән-сау кайтыр да, кабат шуларга кушылып китәрмен төсле тоела иде... Нииндидер бушлык урнашты күңелдә. Менә шул вакытта «Совет әдәбияты» журнал редакциясенең ишеген кагучыларның берсе — Шәүкәт Галиев, икенчесе — Илдар Юзеев, өченчесе Хисам Камалов булды. Үзем укып чыккан педагогия институтының әдәби түгәрәге Илдарлар, Хисамнар вакытында шаулады. Аннан Илдар яшьлеккә, мәхәббәткә алып кереп киткән «Таныш моңнар» белән очраштык. Һәр шагыйрьнең поэзия дөньясына сихерләп алып кергән бер әсәре бардыр. Минем үземдә алар — «Пар ат», «Шагыйрьнең балачагы». Илдарда — «Таныш моңнар». Шуннан бирле Илдарның мәхәббәттән айныганы юк.

Илдар минем күз алдымда үскән шагыйрь дип әйтә алам. Мин аннан егерме яшькә олы. Хикмәт анда түгел. Рухы белән якын. Авылның моңнарыннан аерыла алмый газапланган кешенең хисләре анда. Яшьлеге, мәхәббәте шунда, авылда. Хәтта бераз сентименталь романтика белән өртелгән моңсулык, Такташка якынаям дигәндә генә аерылып киткән моңсулык. Ул хисләрнең дәвамы «Миләүшә»ләргә күчте. Тора-бара Илдар икенче шагыйрьгә әйләнде дисәм, дөрес булмастыр. Хәзер ул егермеләп поэма авторы. Егермесе егерме характерда. Темалары төрле, хисләрнең яңгырашы төрле... Яза башлап, бер-ике әсәр яки бер-ике шигырь җыентыгы чыгару белән бер урында озак таптанган шагыйрьләрне беләм. Әйбәт башлыйлар, яшьлекнең бөтен хисләрен беренче җыентыкларга салып бетерәләр дә аптырап калалар. Илдар — шигырьдән шигырьгә, поэмадан поэмага үскән шагыйрь. Җырларын — поэмаларыннан, поэмаларын драматик әсәрләреннән аерып булмый. Рухлары белән алар бер-берсеннән үсеп чыгалар. Барысы да ләкин Илдарча, фәкать Илдарча. Баягы фикеремә яңадан кире кайтып әйтәм: аларда бернинди кабатлану юк. Тирәнәйгәннән-тирәнәя бара Илдар. «Язылмаган поэма» романтик-патетик тонда иҗат ителсә, «Соңгы сынау» — фәлсәфи характердагы драматик легенда. «Карурман», «Таш диварлар авазы», «Өзелмәс кыллар» кебек төрле яңгыраштагы әсәрләрдән соң ул яңадан «Мәхәббәт китабы»на борылып кайта. Яшьлеккә мәңге тугры икәнен раслаган шикелле, «Яшь наратлар», «Янар чәчәк», «Кыр казлары артыннан», «Серле чәчәк» җырлары белән әйтерсең бөтен язганнарын беркетеп куйды. Юмор, кызык фикер, экспромт шигырь юлларын адым саен сибеп-чәчеп йөргән, әрәм иткән бу шагыйрьнең рухы гаҗәеп дәрәҗәдә бай. Мине сокландырган, шатландырган нәрсә шул. Чөнки бөтен хикмәт шул рухи байлыкта. Бу яктан ул бәхетле. Бик бәхетле. Шунсыз шагыйрьне күз алдына китерүе кыен.

Туфан ни өчен яратты икән Илдарны? Туфанча ягымлылык белән башыннан сыйпап сөя иде. Гадилеге, тыйнаклыгы, халыкчанлыгы өчендер, мөгаен. Поэзиягә Туфанның үзе кебек тугры. Шөһрәт, дан артыннан кумый. Тәрҗемәләре аз. Монысы, бәлки, кимчелегедер. Шулай дим дә, икенче уй килә башка. Башта бит үз халкың сынавы аша узарга кирәк. Аннан инде, ышаныч тугач, икенче халыкларга күренергәдер. Их, Илдар урынында берәү булса, ул поэмаларын күптән тәрҗемә иттереп, киң дөньяга чыгарып җибәрер иде. Талант һәркемгә дә тигез бирелми икән шул!

Илдарга әле илле генә яшь. Миңа әле бөтенләй күтелмәгән яңа әсәрләрен укырга насыйп булыр дип ышанып калам.

*1983*

**ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ**

# «Үз йөрәгең янар чәчәк»

Илдар Юзеев... һәрвакыт моң тулы шигъри халәттә иде ул — күңеленнән илһам китеп тормагандыр. Сүзсез, кайчакта битараф күренгән шагыйрьнең рухи дөньясы тынгысыз, җанын әрнеткән хисләр кайный. Кулына гармун алса гына ташып чыга тойгылар — ашкынып, канатланып тантана итә шагыйрь җаны! Кушылып җырлыйм дигәннәр дә туктап тыңлый башлый: ул уйлаган таныш көйләр дә аның күңеле «эшкәртүендә» ирекле, дәртле симфониягә әверелә!

Моң — Илдар әсәрләренең җаныдыр. Бар иҗаты югары сәнгать дәрәҗәсендә, һәркайсы үзенчәлекле, ачышлы һәм табышлы. Әдәбиятыбызда Илдар Юзеевның төрле жанрларда иҗат иткән әсәрләр берничә авторга җитәрлектер! Ә бит дәүләтебез югары дәрәҗәдә бәяләгән, халкыбыз яраткан ул әсәрләр — гомер буе казна эшен башкарган әдип хезмәте; өстәвенә күпме җәмәгать эшләре башкарылган.

Илдар Юзеев иҗаты — милли байлыгыбыз, туган телебез хәзинәсе. Шунысы көенечле: ак кәгазьгә төшәсе күпме әсәрләре тумый калды... Шагыйрь үзе илһамланып янган чәчәк. Бер интервьюда үзе дә «эчтән янам» дигән иде. Шулай яшәде, шулай иҗат итте. Язмама исемне үзенең «Янар чәчәк» җырыннан алып куйдым.

# Мәңге бергә...

Безне шигърият очраштырды. 1956 елда чыккан «Таныш моңнар» китабында Илдарның беренче автографы шушы:

*Шәүкәт дус,*
*Мәңге бергә,*
*Булыйк бергә*
*Иҗат итеп,*
*Җәме?*

Шигърият безне гомерлек дус итте. Ярты гасыр дәвамында укучылар белән меңләп очрашуда булганбыз. Гаиләләр белән дуслар. Яшь язучылар белән эшләгәндә дә бергә туры килдек. Идел буенда Илдар урын алып куйган дачада күршеләр булып 36 ел яшәдек. Серләр-фикерләр уртак иде. Җыелышларда бергә күрсәләр, гел: «Сез һаман бергә икән», — дип шаярталар иде. Ахры, күз тидерделәр...

«Мәңге бергә...» Мәңгелекнең чиге юк, гомерләр санаулы шул. Үлемсезлек могҗизасы әдип калдырган әсәрләрдә генә буладыр.

# Сибгат Хәким егетләре

Бөек Ватан сугышыннан соң Язучылар союзына алынган беренче төркем идек без. СССР Язучылар союзы билетларын алгач, 1958 елның июнендә остазыбыз Сибгат абый Хәкимгә рәхмәтебезне әйттек. Гамил Афзал: «Сез Казанда гел бергә, мин — читтә. Әйдәгез, истәлеккә карточкага төшик әле!» — диде. Төрле яктан, төрле язмышлылар идек без. Иң яшебез — Илдар, аңа 25 тулган. Еллар үткәч тә бу фотоны икәүләп карый идек. Берзаман ачыш ясагандай булдык. Сибгат ага Хәким — Тукай бүләге лауреаты, Татарстанның халык шагыйре. Тора-бара Сибгат Хәкимнең әлеге егетләре дә һәркайсы шушы ике исемгә лаеклы булган икән. Алар: Хисам Камалов, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Гамил Афзал.

# Яшик әле!

Илдар, Тәфтилә ханым белән туган көннәр дә уртак бәйрәмнәр иде. Түгәрәк даталарда багышлау шигырьләре дә языштык. Бу икесе минем култамгалардан:

*Юзәй, синең туган көнең*
*Такташ белән янәшә.*
*Җырда серләшә-серләшә*
*Шулай янәшә яшә!*
*3 гыйнвар, 1965*

*Халык күңеленнән таптың, Илдар,*
*Шигърияtнең серле чәчәген.*
*Татар гомере озын булсын өчен*
*Кирәк синең Җирдә яшәвең!*
*2 гыйнвар, 1982*

Туган көннәрне искә алмый калдырмый идек. Бусына ике атна гына җитмәде — 2004 елның 21 декабре ышанып булмастай кайгылы хәбәр китерде...

...Ике ел элек кенә, 2002 елның 23 ноябрендә, минем туган көнгә Илдар «Серле чәчәк» исемле китабына култамгада: *«Җитмештән соң яшәүләр тагы да кызыграк икән... Яшик әле!»* — дигән иде...

# Шомыртларда кар чәчәкләре...

Илдар Юзеев белән беренче очрашуыбыз 52 ел элек — 1952 елның җәендә — Кайбычта булган иде. Әдәбият дип хыялланучы яшьләр кечкенә күпер янындагы яшел чирәмлектә, аннары редакциядә (редактор булып эшләгән чагым) тормыш һәм әдәбият турында кызып-кызып сөйләшкән идек. Казаннан алар өчәү килгәннәр иде: Илдар, Илдарның абыйсы Нил, Илбарис Надиров. 19 яшьлек Илдарның педагогия институтында укыган чагы. Моннан соң очрашулар гомер буе булды. Илдар безнең Тау ягын якын күрде. Апаста, туган авылым Олы Бакырчыда әледән-әле була идек. Сагынып, үз итеп туганнарча көтеп торуларын күрә иде.

Очрашулар Кайбычта да була торды. Ә 2004 елның февралендә соңгы кайтуы булган икән. «Кайбыч таңнары» газетасының «Таңчулпан» әдәбият түгәрәгендә балалар белән очрашырга Ләлә Гыймадиева, Рәзинә Исмәгыйлевалар бергә килдек. Бик мәгънәле булган иде иҗади сөйләшү-танышу.

«Сабантуй» газетасында Илдар ун ел эшләде, «лаеклы ялда мин» дип санашмады. Талантлы балаларга даими ярдәм итеп, әдәбиятка юл ачты. Уңышларына, танылуларына сөенеп эшләде. Туган телебезнең киләчәген кайгырткан фидакарь хезмәт иде бу.

«Шомырт чәчәк аткан чакта килегез әле!» — дип озатканнар иде Кайбычта. Килербез дигән идек. Февральнең ак бураннары булды Илдарның Кайбычта соңгы күргәне. Шомыртлар кар чәчәктә калды...

# Шагыйрь белән сөйләшү...

«Бер-берсен макташалар» дигән сүзләргә урын калдырмас өчен, матбугатта иҗатларыбыз турында язышмаска сүз куешкан идек Илдар белән. 70 яше уңае белән «Сабантуй» газетабыз сорагач, әлеге килешүне әзрәк бозып алган идем: «Дустың үзеңнән яхшы булсын» диләр. Илдар Юзеевка карата шуны раслый алам. Иҗатын остазларыбыз Хәсән ага Туфан, Сибгат ага Хәким белән янәшә күрәм, дигән идем. Үзе укып өлгерде. Әйтми калган булсам, үкенер идем. Үкенечләр болай да күп. Хәзер инде шагыйрь белән ул калдырган әсәрләре аркылы сөйләшергә калды...

# «Китмибез»

Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев Илдар Юзеевны 70 яше белән котлап чакырган иде. Шагыйрь иҗатын яшьлегендә — «Таныш моңнар» поэмасыннан бирле яратуын сөйләде. Әдәбиятны, сәнгатьне нечкәләп тоючы шигъри җанлы Илбашыбыз шагыйрьгә тормышында да ярдәмле булды. Очрашу форсатыннан файдаланып, бишәр томлы «Сайланма әсәрләр» өчен рәхмәтебезне җиткердек.

2004 елның 25 октябрендә Милли мәдәни үзәктә Илдар улы Салават Юзеевның дөньялар гизеп, тирән тарихыбызны өйрәнеп иҗат иткән «Китмибез» дигән документаль фильмын карадык. Олы уңышлары өчен сөенеп, Салаватны һәм әтисе Илдарны котлаган идек. Шушы фильм өчен М.Ш.Шәймиевтән Салават интервью алган иде — фильмда һәм матбугатта дөнья күрде ул әңгәмә.

...22 декабрьдә Г.Камал театрының матәм залында Илдар Юзеевны соңгы юлга озатырга Президентыбыз Дәүләт Советы утырышын калдырып килде. Тәфтилә ханымның, улы Салаватның, оныгы Саматның кайгыларын уртаклашты. Салаватны аталарча юатты, теләктәшлек белдерде. Үзенең чыгышында Президентыбыз Илдар Юзеев иҗатына югары бәя бирде, яраткан шагыйребезне халкыбыз онытмас, диде. Әдәбиятның югары сәясәт икәнен күрдек.

...Берничә айдан Татарстан Язучылар берлегенең чираттагы съезды булыр. Күренекле ике туган — Илдар белән Нил Юзеевлар гына булмас... Булыр Юзеевлар — Илдар улы Салават, Нил улы Айдарлар булыр. Икесе дә тарихыбызны дөньякүләм дәрәҗәдә өйрәнгән, зур хезмәтләр, нәтиҗәләргә ирешкән галимнәр. Салаватның фильмы «Китмибез» дип атала. Китми Юзеевлар, әтиләре юлыннан эстафетаны дәвам итәләр.

*29 гыйнвар, 2005*

**РОБЕРТ ӘХМӘТҖАН**

# Элегия

*(И.Юзәй ядкәре)*

Синең шигырьләрне төнката мин
Укып чыктым. Сызылып таң атты.
Кошлар талпынгандай, баш очымда
Җил тупылны шаулап уятты...

Таң җилеме өрде утлы кузга? —
Җетеләнде хәтер ут булып.
Син кайларга очтың соң, кайларга,
Шау дөньядан, бардан юк булып?!
Әллә сагыну, әллә илчең микән, —
Ак күбәләк оча тирәмдә?..
Мендәремнән җир авазын тыңлыйм,
Синең йөрәк тибә тирәндә!..

Күбәләктәй рухың җил иркендә
Очты микән таллар өстеннән —
Оча-уйный безнең тәрәзәгә
Син кайтасың бары кич белән...

Ни дип дәшим сиңа?
Сискәнмәсен, —
Минем йөрәк шул ук күбәләк...
Онытма син моңсу тәрәзәмне,
Күбәләктәй кит син килгәләп!

**ЛӘБИБӘ ИХСАНОВА**

# Эчкерсез дуслык

Илдар белән мине балалар әдәбияты дуслаштырды кебек. Бала күңеле кебек эчкерсез дуслык иде ул. Гомеребез буе шулай калды. Радиокомитетның балалар тапшырулары редакциясендә бераз эшләп алганнан соң, мине «Пионер» (берничә елдан соң без аңа «Ялкын» дип исем куштык) журналына баш редактор итеп куйдылар. Журналның җаваплы секретаре минем булачак уң кулым, «Таныш моңнар» поэмасы белән күпләрне әсир иткән гаять сәләтле шагыйрь Илдар Юзеев икәнен белеп килдем. Журналист буларак та тәҗрибәсе барлыгына ышанып килдем. Һәм ялгышмадым. Күп мәсьәләдә фикеребез уртак, таләпләребез бердәй булды. Иҗади хезмәткәрләр барыбыз биш кеше. Бер йодрыкның биш бармагы кебек бердәм эшлибез. Килешмәгән эшкә төртеп күрсәтү өчен генә ачыла ул бармаклар. Андый чаклар аз булмый иде эшләгәндә. Кискен сөйләшүләр күбрәк әдәби әсәрләр турында бара. Бүлекнең балалар иҗатына игътибары җитми. Илдар бигрәк шуңа көенә. Сәләтле каләмнәргә аеруча игътибарлы булды ул. Алардан килгән хатларны үзе укып барды. Озын-озын хатлар язды. Алар кадерле истәлек булып күпләрнең архивында сакланадыр әле. Инде «Сабантуй»да эшли башлагач та шулай булды. Хәл белергә дип янына керсәң, сөйләшеп утырган арада кинәт исенә төшкәндәй, бала кулы белән язылган дәфтәр битен бирер иде дә язманың нинди тәэсир калдыруын йөзеңә карап чамаларга тырышыр иде. Канәгать елмаюыңны күрсә, бала кебек шатланыр иде.

Яхшылыкның кадерен белә торган, итагатьле, чиста күңелле кеше иде Илдар. Графоманнарны гына сөйми иде. Начарны начар дип күзеңә карап әйтә торган булды.

Кешене беләсең килсә, аның белән юлга чык, дип әйтәләр бит. Бервакыт Әлмәт, Азнакай якларыннан йөреп кайтырга булдык. Ул да Илдар тәкъдиме белән булды бугай. Язучылар берлегенә килгән кеше Илдар эшләгән консультация бүлмәсенә керми калмый иде. Бер баруымда мин дә ачтым ул ишекне. Дусты Шәүкәт белән сөйләшеп утыралар.

— Берәр кая барып кайтырга уйлыйбыз, — диде ул, яннарына килеп утыргач.

— Мине дә алыгыз әле, — дидем, бик үк ышанмыйча.

Берсүзсез риза булдылар. Төркемебез «солидныйрак» күренсен дип, Заһид абый Хәбибуллинны да әйдәргә булдык. Бармый каламы соң ул? Әйтүгә риза булган.

Без, балалар кайтып киткәнче өлгерик дип, башта мәктәпкә киләбез. Ул елларда балалар китап укырга ярата, «Яшь ленинчы» гәзите белән «Ялкын» журналын алдыралар. Язучы белән күзгә-күз карап сөйләшү алар өчен зур вакыйга була иде. Сорауларны яудырып кына торалар, җавап бирергә өлгер.

Көндезге һәм кичке очрашулардан фатирыбызга дәртләнеп, тәэсирләнеп, күтәренке күңел белән кайтабыз. Чәй янында сәгатьләр буе сөйләшеп утырабыз. Берсендә этәч кычкырган тавышка сискәнеп киттек. Таң атып килә икән бит.

— Ятыгыз инде, иртәгә дә көн бар, — дип, урынымнан кузгалдым.

— Иртәгә түгел, бүген дип әйт, — дип калды Шәүкәт артымнан.

— Йокы үзе иске нәрсә, һәрбер ялкау аны яңарта, — дип, Илдар да өстәп куйды.

Ни әйтәсең инде боларга! Яннарыннан үткәндә ялгыш кагылуың була, бу икәүдән чәчрәп шаян сүз чыгарга тора.

Шулай итеп, бер-беребезгә ияләшеп беткәнбез икән. Казанга кайткач та очрашырга җай табып кына торабыз. Юлдашларым туган ягым Вятка буйларын күрергә теләүләрен сиздерә. Үземнең дә бу турыда уйлаганым бар иде, әйтергә кыюлыгым җитми торды. Безнең як халкы башка төрлерәк, руслар арасында яши, татар мәдәниятеннән аерылган, Татарстандагы кебек кабул итмәсләр дип уйлый идем, ялгышканмын. Клублар һәркайдагы кебек шыгрым тулы, имчәк балаларын күтәреп килгән хатыннарга хәтле бар. Бала-чагалар, гадәттәгечә, сәхнә алдын сырып алган. Заһид ага скрипкада бал кортлары выжылдавын, этәч кычкыруын, тавыклар кытаклавын сыза башласа, сәхнәгә менеп утыруларын да сизми калалар, ә Илдар, артист кебек рольгә кереп, ярсып, дулкынланып, Ватан сугышы каһарманы Мөҗәй турындагы поэмасыннан өзек укыганда, залдагыларның тын алуы да сизелми, хатын-кызлар яулык читләре белән күз яшьләрен сөрткәләп алалар.

Менә инде без бик дулкынланып кайтып барабыз, әйтер сүзләр әйтелгән, сөйләшәсе сөйләнгән, күргән-белгәннәрне күз алдына китереп, тын гына утырабыз. Шул вакыт Шәүкәт:

— Бик аз булды бит әле бу, — дип куймасынмы.

— Өйдә хатыннар да көтеп тормый, — дип, Илдар да шаяртасы итте.

Сүземне чынга алмаслар дип, сүз юктан сүз булсынга гына:

— Әйдә соң, төшеп калыйк, булмаса, — дип әйтүемә, шул сүзне генә көткән кебек, кабаланып җыена да башладылар. Минут та үтмәде, кузгалып китәргә торган поезддан

сикереп төшеп тә калдык. Поезд китте. Ә без, балаларча уйламый эшләвебезгә аптырап, перронда басып калдык.

— Инде нишлибез?— дип, башлап Заһид абый телгә килде.

— Райкомга барыйк әле. Ни эшләргә кирәген анда әйтерләр, — дидем.

Райком секретаре Булатов киңәшмә үткәрә икән. Без килгәнне белгәч, эшеннән бүленеп, яныбызга чыкты. Хәл белешкәч, озак сөйләшә алмавына гафу үтенеп:

— Хәзер сез «Коммунизм» колхозына барырсыз. Мин аларга шылтыратырмын. Әзер булып торырлар, — дип, шоферын чакыртып алды.

Әнә шундый күңелле маҗаралар белән үткән көннәре дә була иде иҗат кешеләренең.

Халкыбыз өчен бик кадерле кеше иде Илдар. Зур мирас калдырып китте. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр язу өстәле артында булды. Дан, дәрәҗә артыннан кумады. Даны да, дәрәҗәсе дә үзе килде аңа, халык мәхәббәте, халык рәхмәте булып килде. Такташлар, Хәсән Туфаннар белән мәңге янәшә булыр Илдар Юзеев дигән шагыйрь исеме!

**АЛЬБЕРТ ЯХИН**

# Болытлар артындагы кояш

Өметне югалту бик ансат,
Ни генә күрмәде бу башлар...
Башларны калкытты тик бер нур —
Болытлар артында Кояш бар!

*И.Юзеев*

Илдар белән беренче танышуым аның гармун уйнавын күрүдән башланды. Минем туган көн булса кирәк, чөнки ул уйнаган көчле тавышлы хромка гармун минеке иде. Кунакларның берсе уйнавын үтенгәч, Илдар бераз кыенсынып торды да уйный башлады. Әле дә хәтердә, көе бу елларда барыбыз да җырлый торган «Авыл көе» иде.

Илдар башын артка атты, күзләрен йомып, көй тактына салмак кына селкенә-селкенә уйнады. Көе гармунчы күңелен яулап алдымы, гармунчы көйгә эчтәлек салдымы, үзе генә белә торган башка дөньяга — моң дөньясына кереп югалдымы, ул чакта белә алмадым.

Илдар бераздан «Тургай чәчәге» исемле китабын бүләк итте. Туган авылы турындагы бүлектә укыйм — авылдашы Сәлимҗан фаҗигасе һәм аның җырлары калдырган тәэсире турында язган. Малай чакта Сәлимҗанның:

Алма диеп алган идем,
Йомарлаган кар булды.
Сынар өчен сөйгән идем,
Эч өзәрлек яр икән, —

кебек җырларын аңламый Илдар.

Сәлимҗан каядыр китеп югалгач, җырын юксына башлый. Үзе дә сизмәстән, аны сагынып, җырларын көйли.

Еллар үткәч, бу вакыйга турында шагыйрь болай дип язачак:

*«Хәзер инде мин бу сүзләрнең мәгънәсен, үзәк өзгеч хисен аңлыйм...*

*Әгәр минем әсәрләремдә лирик моң, тыштан әллә ни кычкырып тормый торган эчке бер өзгәләнү, янулы сагыш бар икән, барысы да авылдашым Сәлимҗаннан...*

*Төнлә, клубтан кайтканда, бөтен урамны уятырлык тавыш белән кычкырып түгел, үзем дә сизмәстән, йөрәк белән серләшеп, үзем белән сөйләшеп, Сәлимҗан абый кебек җырлап кайтам».*

Илдар күзләрен йомып уйнаган «Авыл көе» Сәлимҗан җырлап үткән, аны кабатлап Илдар үзе белән үзе сөйләшергә, «йөрәге белән серләшергә» яраткан көй түгелме? Гармунда онытылып уйнаган көе аны, бәлки, авылдашы калдырган сагышка үзенең дә «эчке өзгәләнү, янулы сагышы» кушылган хисләр дөньясына алып кергәндер.

Көй тудырган хыял дөньясы аны бала чагында ук урап ала:

*«Шул вакыт кай урындадыр, тирәндә, башта сизелер-сизелмәс кенә, аннан бөтен тәңгә-җанга таралып, таныш бер көй тирбәлә башлады. Нинди көй бу, кайда ишеттем мин аны? Сандугачлы-кәккүкле Мүксаз буйларындамы, йөгерек дулкыннарында тирбәткән Кәшти тугайдамы? Әллә иркә куллары белән бишек тирбәткән әнкәемнәнме? Әллә Ханнан чишмәсенең челтерәвендә ишеттемме мин бу көйне?.. Шулчак мин бөтен барлыгыма әнә шул көйнең таралуын, үзәк өзгеч таныш дулкыннар агышыннан тәннең рәхәт сулкылдап куюуын, күзләргә ихтыярсыз ачы да, татлы да кайнар яшьләр килүен тоям...»*

Илдар гармунда уйнаган көй, бәлки, аны туган як табигатенә алып киткәндер.

Мин Илдарның аннан соң да онытылып гармун уйнавын күрдем һәм тыңладым. Хәзер инде аның күзләрен йомып уйнаганда ни өчен күңеленең рәхәт сулкылдавын аңлый башладым. Мин гармунчының шагыйрь булуын искә алмаганмын икән.

Ул елларда радиодан «Таныш моңнар» поэмасын еш тапшыралар иде. Шуңамы әсәрнең үзен шактый вакыт узгач кына укып чыктым. Үзем укыйм, үзем Илдарның гармун уйнаганын искә төшерәм. Поэмасында Илдар, үзе уйнаган гармун моңына кереп югалган кебек, үзе тудырган хисләр дөньясында яши башлый. Чибәр Резидәсен матурлый-матурлый да, матурлый торгач, аңа үзе дә соклана башлый. Кызының күңеленә шатлык, хәсрәт, үкенеч хисләре тутыра да Резидәсе шатланганга үзе дә шатлана, кыз хәсрәтләнгәнгә үзе дә хәсрәтләнә. Уйлап чыгарган кызына тәмам гашыйк булып, аның белән үз итеп сөйләшә, аның хәсрәтен уртаклаша, аңа киңәшләр бирә, юата:

Ай-һай, гәүдәң бигрәк сылу икән!..
Син үзең дә

«Уф» дип куйдың, —
Ахры, түзмәдең...
...Ник, матурым, бигрәк моңайганнар
Төн карасы кебек күзләрең?..

Сирень яфраклары соң мәртәбә
Үбәргә дип кызга үрелде...
Күңелең тулып елап җибәрерсең,
Резидәкәй, тизрәк кер инде!..

Нигә бераз гына сөйләдең дә
Телсез калдың?
Әллә...
Резидә!
Каушама, Резидә,
Күтәр башың,
күтәр югары.
Канатланып вузга килүеңне,
сынау бирүеңне
оныттыңмы әллә?
Калдыңмы әллә кинәт югалып...
Нишләдең син,
Нишләдең син, сеңлем Резидә?..

...Илдар бу вакытта хәтта укучысын да онытa — хыялы тудырган вакыйгалар эченә кереп, чынлап торып ярата, шатлана, хәсрәтләнә, үзен дә юата. Мине аеруча гаҗәпләндергәне Илдарның хыялы тудырган үз хисләре дөньясында яшәү халәтен үзе яратуы булды.

Тынма, дәрья, айка, чайка:
Күнмәгәнмен тынлыкка.
Упкыннарың берни түгел,
Батырма тик моңлыкка... —

дип язган «Тынма, давыл» шигырендә Хәсән Туфан.
Чын шагыйрьләрнең даими халәте тынлыкка күнә алмый, көрәсең.
«Болытлар артында Кояш бар» шигырендә Илдар болай яза:

Усаллар, әрсезләр заманы...
Нәселдә һәммәбез юашлар.
Бабабыз әйтергә яраткан:
«Болытлар артында Кояш бар».

Поэма иҗат иткәндә, Илдар Резидәсеннән бик азга гына өлкән була.
Аның әле болытлар артында Кояш барлыгына һәм аның, һичшиксез, җиргә нур сибәчәгенә инанган бәхетле чагы.
Займищеда журналистлар янында язучыларга да дача төзер өчен җир биргәч, Илдарлар белән күршеләр идек. Еш очраштык. Төннәр буе сөйләшеп утырган чаклар күп булды. Мин аның көлә-көлә килеп кергән чакларын да, башын аска иеп, тамак кыра-кыра кергән чакларын да күрдем. Еллар үткән саен, тамагын кыра-кыра кергән чаклары арта барды.
Истәлек язам. Илдар сөйләгән сүзләрне язу сорала, ләкин гафу үтенәм. Бәлки, ул серләрен сөйләгәндер. Үзенең рөхсәтеннән башка шатлыгын да, зарын да яза алмыйм. Ул сөйләгәндә туган үз хисләрем турында гына әйтәм.
Илдар. Күзләре өстәлдәге бер ноктага текәлгәннәр. Хәзер мин бөтенләй башка Илдарны тыңлап утырам.
Илдар миңа үзенең хәсрәте, үкенече, борчылуы турында сөйли, ләкин хәзер яшь чагындагы кебек хыял дөньясында гизәргә яраткан күңеле шатланып очыныр өчен сәбәп эзләми, хәзер Илдар күңеле Кояшсыз тормыш тудырган авыр хисләрдән арыну юллары эзли...
Басылып чыккан китапларын Илдар «*Альберт белән Эльмира дусларга бергә үткәргән яшьлек еллары истәлеге»* дип кыска-кыска язмалары белән бүләк итә барды. Мин Илдар әсәрләрен шактый яхшы беләм. Шуңа күрә аның сүзләрен шигырьләренең әле берсе, әле икенчесе белән ялгый барам.
«Бергә үткәргән яшьлек еллары» артта калды, заманалар нык үзгәрде. Болытлар артындагы өмет Кояшы чыкмады, гомер буе ышанып яшәгән идеаллар җимерелде.
Ил идеалының җимерелүен Илдар үзенең шәхси фаҗигасе итеп кичерде. Болыт каплаган хакыйкать кояшын күрә алмаячагына җитмешенче елларда ук шиге калмады. «Нишләдем?» шигырендә Илдарның рухи халәте тамырдан үзгәрүен күрәбез:

Күкрәк читлегеннән сыеша алмый
Ташып чыга иде хисләрем.

Нишләдем?
Мин йөгәнсез чапкан бер тай идем,
Белми идем хыял чикләрен.
Нишләдем?
Тупасланганмы әллә хисләрем?
Йөрәгемне салып күрегенә,
Гармун уйный идем кичләрен.
Нишләдем?

«Хәсрәтле җыр» шигырендә йөрәген бертуктаусыз тырнап торган үкенү хисенең сәбәбен ул болай язды:

Минутлап, сәгатьләп
сүтелгән гомеремнең
йомгагы шул булды:
йөрәгем — көрәшче,
кул-аяк кол булды...

Бу хәлне без дә кичердек. Ләкин халык алдында тәүбә кылучы бер Илдар Юзеев булды. Шулай барыбыз өчен дә бу эшне Илдар Юзеев эшләде.

Таныш үземнең җырымны
Ишеттем әллә каян...
Ватан сугышы гарибе...
Кулына тоткан баян.
Күкрәгендә — медальләре,
Алдында — кәләпүше.
Синме соң бу иң-иң явыз
Дошманны җиңгән кеше?!
«Без көчле!» дип язган шагыйрь —
Ярдәм италмыйм мин дә.
Җырым да мохтаҗ ярдәмгә
Шушы хәерче илдә.
Берни юк... Заман җилендә
Чалланган ак башым бар.
Шушы хәлләрдә калуда
Минем дә катнашым бар...

«Чаян» журналында эшләгәндә, Илдардан шаян хикәя язуын үтендем. Ялына торгач, берсеннән-берсе кыска дүрт хикәя язып килде. Хикәяләр оста юморист кулы белән язылган иде. Шуннан соң күпме генә ялынсам да, хикәя язмады. Хисләренә хыянәт итмәскә ниятләгәндер, күрәсең. Ә бит искиткеч талантлы юморист иде. Минут эчендә теләсә нәрсә турында үткен фикерен сибепме-сибә иде. Юлда йөргәндә башка Илдар белән барасың. Юлаучысын тыңлый, үзе дә сүзгә кушыла, ләкин кечкенә генә пауза булдымы — шунда ук, нәрсәдәндер кызык табып, мәзәк әйтеп ташлый. Юморының мәгънәсен аңлавыңны абайласа, шаркылдап көлеп куя. Минем аңардан башкалар уйлап тапкан мәзәк ишеткәнем булмады. Аңа мәзәгенең тәэсирен күрүдән бигрәк кызыкны үзе уйлап табу гамәле әһәмиятлерәк иде. Ул бит уйлап тапкан күпсанлы мәзәкләрен җыймады да, кабатлап та сөйләмәде. Минемчә, ул шулай итеп уй-фикеренә өстәмә эш кушып, сүзләргә, әйбер сыйфатларына көтелмәгән мәгънәләр таптырып, хисләренә вакытлыча гына булса да ял бирә иде.

Мин берничә ел инде Чаллы төбәгендә укытучыларга лекцияләр укырга барам. Чаллыдагы Укытучылар белемен күтәрү институты Илдар Юзеев белән Шәүкәт Галиевне дә укытучылар белән очрашырга үгетләвемне үтенәләр. Рәхмәт аларга, үтенечемә бер тапкыр да каршы килмәделәр.

Арабызда Илдар юк инде. Кызганыч, безнең тормыш авыр, болытлы елларга туры килде. Халык үзенең Тукай, Такташ, Хәсән Туфан, Илдар Юзеев кебек зур шагыйрьләрен кояшсыз болытлы елларда тудырган. Бәлки, үзләре газап чиксәләр генә, безне юата алачаклар, дигәндер. Газап чиктергән, ләкин аның каравы барысын да татар әдәбиятының кояшы итеп үстергән.

**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**

# Илдар мәзәкләре

Якын кешең мәңгелеккә китеп баргач, күпмедер вакыт югалуына ышанмый йөрисең. Каядыр китеп торган кебек кенә тоела. Тора-бара аның кайтмаслыгына тәмам ышангач, сагышлы сагыну башлана. Ара ерагайган саен, хәтер якыная бара. Илдарның тормышы ал да гөл булмаса да, ул кайгы-хәсрәтләрен эченә яшереп яшәде, һаман да шаян, тапкыр сүзләр әйтеп безне гаҗәпләндерде. Ул татар сүзенең бөтен төсмерләрен белә, тоя иде, сүз уйнатырга яратты. Татарда «Авызың тулы кара кан булса да, кеше алдында төкермә» дигән мәкаль бар. Илдар, аны әз генә үзгәртеп, «Авызың тулы таракан булса да, кеше өстенә төкермә» дия иде, үзенә генә хас көлү белән кеткелдәп куя иде. «Ат азгыны тайга иярер» дигән мәкальне «Ат азгыны байга ияры» дип, байлар тирәсенә елышкан язучылардан көлә иде. Илдар шаяртуларының төбендә еш кына тирән фәлсәфә дә ята иде. Безнең арада Илдар белән бәйле бик күп мәзәкләр йөри. Киләчәктә аларны тупларга да кирәктер. Үзе көлкеле, ләкин афоризмга тиң җөмләләр әйтеп йөрсә дә, аларны язып бармады. Сүз уйнату буенча Илдар белән ярыша алырлык язучылар бик аз. Бервакыт чираттагы командировкаларның берсендә кунакханә номерында ял итеп ятабыз. Шунда үзебезгә бер шөгыль уйлап таптык. Татарда «Кулымдагы йөзегемнең исемнәре...» дип башлана торган җыр-такмаклар бар. Без дә дөньядагы танылган шәхесләрнең исемнәренә рифма табып такмаклар чыгарырга булдык. Дүртьюллык такмакның беренче ике юлын мин әйтергә тиеш. Соңгы ике юлы Илдарга кала. Ни өчендер иң беренче булып исемә Хрущев фамилиясе төште. Әйттем:

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Хрущев.

Илдар шунда ук такмакны тәмамлады:

Без утырткан кукурузлар
Бетте инде бөрешеп.

Шуннан китте. Мин:

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Чайболсан.

Илдар:

Чайболсандай булыр идем,
Шул мәйне эчеп алсам.

— Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Ким Ир Сен.
— Безне хурлаган кешеләр
Үз фәләнен кимерсен.

— Кулымдагы йөзегемнең
Исме Фидель Кастро.
— АКШның койрык астына
Кызган тимер кыстыра.

Илдарны төп башына утыртырга теләп, әллә нинди исемнәр әйттем, һәрберсенә рифма тапты. Иң көчле «һөҗүмем» Антуан де Сент-Экзюпери иде. Илдар бераз уйлап торды да:

Самолетта күк иңләгән
Антуан де Сент-Экзюпери.
Самолетта очудан куркып,
М.Туфан гел сөт эчеп йөри.

Бик күп исемнәр керде ул кичне такмакка. Алар, әлбәттә инде, шедеврлар түгел. Монда шунысы мөһим — мин ике юлны әйтүгә үк, Илдар бернинди паузасыз такмакны очлап куя барды. Бары бер исемгә генә рифма таба алмады — Брежнев.

— Кара, хәтта рифмага да туры килми торган фамилия. Башкасын әйтеп торасы да юк, — диде ул.

Без, ялгыш сүз әйттек, ахрысы, дип, бүлмәбезнең түшәм-диварларына күз йөртеп алдык. Брежнев заманы иде бит — тыңлап торып, безнең җүләр сатып утыруыбызга сәяси төсмер бирүләре дә ихтимал иде.

Илдар кешедән матур итеп көлә дә белә иде. Мыскыл итмичә, рәнҗетмичә көлә иде.

Бервакыт Мәскәүдә Башкортстан шагыйре Муса агай Гали белән очраштык. Муса агай авырыйм, чирлим дип зарланырга ярата. Бу юлы да очрашып-күрешеп хәл белешүгә, ул:

— Рәт юк әле, егетләр, бер ай чирләп яттым. Йөрәк өянәге белән, — ди.

Илдар шунда:

— Йөрәк өянәге чепуха бит ул, — дип әйтеп куйды да, — болай хәлләр ничек соң? — дип сорады.

Муса Гали:

— Пневмония белән яткан идем больницада, шул һаман да сиздереп тора. Үпкәләрнең рәте юграк, — ди.

— Үпкә чепуха бит ул, Муса абый, — ди Илдар, — тормышлар ничек?

— Тормыш ярыйсы да, бөерләр әйбәт түгел, — ди Муса абый.

— Бөерләр чепуха бит ул, — ди Илдар.

Бераз сөйләшә торгач, Муса агай үлемне искә төшерә.

— Үлем чепуха бит ул, — ди Илдар.

— Карале, Илдар, синең өчен барысы да чепуха, хәтта үлем дә... Нәрсә соң, алайса, чепуха түгел? — ди Муса Гали.

— Иң главные, сәламәтлегең булсын, — дип йомгаклап куйды Илдар.

Безгә шул гына кирәк, рәхәтләнеп көләбез. Муса агай үзе дә безгә кушылып көлә.

Китапларыбыз чыккан саен, бер-беребезгә автограф язып аларны бүләк итешәбез. Шаярып та, җитди итеп тә матур сүзләр, теләкләр язабыз. Берчак мин әйтәм Илдарга:

— Әйдә, иң кыска автографка ярыш уздырабыз, — дим дә китабымның титул битенә «Илдар, мә!» дип язып куям. Илдар үзенең китабы чыккач, язып бирә: «Туфан, тот!» Икәүләшеп тәгәри-тәгәри көләбез.

Илдарның юморны тирән аңлавы аның язган әсәрләрендә дә күренә. «Янар чәчәк» пьесасында, мәсәлән, салырга яратучы ферма мөдире:

— Председатель үтергәнче сыйларга вәгъдә биргән иде, — ди.

— Сыйламадымыни? — дип сорыйлар аңардан.

— Сыйлавын сыйлады да, үтергәнче булмады, — ди мөдир.

Илдарның мәзәкчәнлеге турында сөйләгәндә, ул гел уйнап-шаярып кына йөргән икән дип уйларга ярамый. Үзе көлгәндә дә, бүтәннәрне көлдергәндә дә күзләре һәрвакыт моңсу, сагышлы була иде. Ул ыгы-зыгылы, шау-шулы, кырыс, миһербансыз бу заманда үзенә урын таба алмый газапланды. Безнең тормыш өчен яратылмаган иде ул. Иҗат дөньясында яшәде. Шигырьләре белән дөньяны аз булса да матурларга тырышты. Минем уйлавымча, дөньяның бөтен рәхәтен шигырь язганда гына тойгандыр ул. Һәм гармун уйнаганда... Гармунны кулына алу белән үк үзгәрә иде. Күңеле белән бу дөньядан китеп тора, күккә — йолдызлар янына менә, фәрештәләр белән сөйләшә. Беркемгә дә сөйләргә ярамый торган серләрен гармунга сөйли, һәм ул серләр моң, көй белән дөньяга тарала иде.

Илдарның кем беләндер бәхәскә кереп әйткәләшкәнен мин хәтерләмим. Аның хәтерен калдырырлык сүз әйтсәләр йә гамәл кылсалар, ул тавыш куптармый иде. Йөзен чытып куя да йомыла иде. Һәм үзенә шундый ямьсезлек кылган кеше белән аралашмый — сөйләшми генә иде. Илдарны яшьләр бик яраттылар. Кулына беренче тапкыр каләм алучы күпме яшь шагыйрьләрне дөньяга чыгарды ул!

Шигърияттә Илдар үз дәрәҗәсенә менеп, бүтәннәрнең дә хөрмәтенә ирешә. Бер үкенече калды шикелле: драматургиясе тиешле бәяне ала алмады. Аңа, минемчә, Илдарның гаебе юк. Аның драматургиясен аңларлык театр табылмады. Марсель Сәлимҗановка берничә тапкыр:

— Нигә куймыйсың Илдарны? — дип әйткәнем булды.

— Шигырьне мин сәхнәгә куя белмим, — дия иде Марсель. — Шагыйрь буларак ул бөек, дәрәҗәсен төшерәсем килми, — дия иде.

Минемчә, Илдар пьесалары татар сәхнәсендә куелуны көтә. Аларның серенә төшенә алучы режиссер гына кирәк.

«Илдар мәзәкләре» дип башладым да җитдилеккә кереп киттем. Илдарның үзе кебек булды язмам. Шаян да, җитди дә, моңсу да...

Илдар турындагы язмам соңгысы түгелдер әле. Ходай кушып исән-сау булсам, тагын-тагын язылыр. Чөнки ул онытыла торган кеше түгел.

*20 декабрь, 2006*

**НӘҖИП ӘСӘНБАЕВ**

# Гүзәл зат иде...

Кызганычка каршы, миңа Илдар Юзеев белән еш аралашырга насыйп булмады. Моның берничә сәбәбе бар. Беренчедән, безнең яшь аралары шактый зур. Икенчедән, ул Казанда, ә мин Уфада яшәдем. Өченче сәбәп тә бардыр, бәлки, ни дисәң дә, ул шагыйрьләр затыннан, ә мин күбрәк драма жанрында иҗат иттем.

Илдарның да әйбәт кенә драмалары, трагедияләре бар. Шулай да ул бар булмышы, табигате белән шагыйрь иде.

Илдар искитмәле зыялы, итагатьле, сөймәлекле кеше иде. Аның зур талант иясе булуын да исәпкә алсак, һәркемнең күңелен үзенә тартып торырлык тылсымлы бер көчкә ия иде ул.

Башкортстанда туып үскән егет буларак, туган ягына бервакытта да хыянәт итмәде, киресенчә, ул үзенең Яңавылын сагынып (юксынып дип әйтсәк тә була) яшәде.

Уфага еш килә иде. Аның Уфадагы дуслары әллә ни күп булмаса да, аерым кешеләрне, атап әйткәндә, Әнгам Атнабаевны, Рафаэль Сафинны, режиссер Рифкать Исрафиловны нык ярата иде, аларның һәркайсысы белән аралашып яшәде, дуслык элемтәсен өзмәде.

Бигрәк тә Рафаэль Сафин белән дус булды. Аның юбилейларына да, иҗат кичәләренә дә килә торган иде. Әйе, дуслыкның кадерен белә торган асыл зат иде Илдар Юзеев. Мин аның Казандагы дуслары Аяз Гыйләҗев, Шәүкәт Галиев, Туфан Миңнуллин кебек әдипләргә гомере буе тугрылык саклавын, аларны яратуын яхшы беләм. Бигрәк тә Т.Миңнуллинны бик якын күрде ул, алар аерылмас дуслар булдылар. Уфага да гел генә дип әйтерлек бергә килә торган иделәр.

Ул әйбәт трагедияләр, драмалар язды, дидем. Шунысы кызык, Илдарның сәхнә әсәрләре күбесенчә М.Гафури исемендәге Башкорт академия драма театрында куелды. Хәтта Казанда артык игътибар яуламаган пьесалары да бездә шаулап барды.

Аның «Ак калфагым төшердем кулдан» драмасы нигәдер Казанда Г.Камал театрында куелмады. Бәлки, берәрсе аяк чалгандыр, бәлки, баш режиссер М.Сәлимҗанов белән уртак тел табылмагандыр (Марсель Хәкимҗан улы бик катмарлы, үзенчәлекле шәхес иде бит). Минем карашка, ул пьеса И.Юзеевның идея-художество кимәле ягыннан иң камил эшләнгән әсәрләренең берсе иде. Темасы да яңа, сюжеты да ифрат кызыклы — бер сүз белән әйткәндә, Русия драматургиясендә яңа сүз әйткән әсәр иде ул.

Бездә аны Р.Исрафилов сәхнәләштерде. Мин үземнең чыгышларымда (озак еллар драма секциясен җитәкләдем бит) Илдарның ул пьесасын татар-башкорт драматургиясендәге иң әһәмиятле сәхнә әсәрләренең берсе дип бәяләдем. Моны дәлилли дә алам. Хәзер кайчан икәнен ачык кына хәтерләмим дә инде, Р.Исрафиловның 50 яшен үткәргәндә, Уфага М.Сәлимҗанов, Т.Миңнуллин, И.Юзеев өчәү килделәр. Актерлар йортында сый мәҗлесе булды. Шунда Ә.Атнабаев, Р.Сафин һәм мин фәкыйрегез тамада ролен башкардык. Безнең трио искитмәле матур килеп чыкты. Ике шагыйрь, бер драматург, әзрәк төшереп алгач та, сандугачлардан да болайрак сайрадык, әмма без «кирәгеннән артык айнык та идек», һәм мин мәҗлестә утырган 150 кеше алдында (Башкортстанның бар сәхнә һәм әдәбият йолдызлары каршында) бер дә курыкмыйча, нәрсә уйлыйм, шуны әйттем:

— Менә монда Казаннан килгән олы кунаклар М.Сәлимҗанов, И.Юзеев, Т.Миңнуллиннар утыра. Дуслар! М.Сәлимҗанов белән Т.Миңнуллин, зинһар, үпкәләмәсен, менә И.Юзеевның яңарак кына бездә куелган «Ак калфагым төшердем кулдан» пьесасы республиканың мәдәни һәм иҗади тормышында зур вакыйга булды. Минем шундый да талантлы язылган, шундый да талантлы куелган сәхнә әсәрен күптән инде күргәнем юк иде. Рәхмәт сиңа, Илдар, яхшы пьеса язганың һәм аны туп-туры Уфага биргәнең өчен! Рәхмәт сиңа, Рифкать Вәкил улы, татар драматургының пьесасын искитмәле матур сәхнәләштерүең өчен! Һәм мин шушы күренекле вакыйга уңаеннан тост тәкъдим итәм!.. — дидем.

Узган гасырның җитмешенче еллары уртасында Мәскәүдә «Руза» дигән иҗат йортында драматурглар семинарында Илдар Юзеев белән бергә утырырга туры килде. Анда Казаннан А.Гыйләҗев, Т.Миңнуллин һәм Д.Вәлиев тә бар иде.

Аяз минем күптәнге дустым. Без Мәскәүдә Югары әдәби курсларда бергә укыдык. Менә шушы «Руза»дагы семинарда мин И.Юзеевны тагын ныграк яраттым. Талантлы, зыялы, басынкы, аз сүзле, сөймәлекле шәхес булуына тагын да ныграк инандым. Шушы гүзәл образны гомерем буе йөрәгемдә саклыйм.

Мәрхүм Илдар Юзеевка мин гомерем буе рәхмәтлемен. Ул 80 яшемне бәйрәм иткән көннәрдә миңа багышлап бик матур шигырь язып җибәрде. Аны кичәне алып баручылар тамашачыларга укып

ишеттерде. Шигырь барысына да ошады, мин аны үземнең китабыма да кертәм әле... Бу шигырь безнең күңелдә яшәгән күпьеллык дуслыкка һәйкәл булды...

**РӨСТӘМ МИНГАЛИМ**

# Илдар Юзеевка

*(Бераз шаярып)*

...Безнең урын,
бу нәкъ безнең җир, дип,
җиң сызганган идек.
Хуҗаларча йөреп,
ут өереп
эшләп алган идек.
Яшәр өчен урын
сайлаганда
ялгыштыкмы әллә?!
Турайт әле билең,
әйт кызык сүз,
хәлләрне күр әнә!
Без тормаслык гүзәл
бу урынга
яшьлек кора оя.
Кая китик?
Монда, әй, валлаһи,
картаерга оят.

*1977*

**СУФИЯН ПОВАРИСОВ**

# Иҗади дуслык ялкыны

1951 ел, 1 сентябрь. Мин Казан дәүләт педагогия институтындагы татар теле һәм әдәбияты бүлегенең беренче курс студенты. Икенче көнне Илдар Юзеев белән танышам һәм дуслашып китәм. Илдар лирик шигырьләр яза. «Тормыш җиңә», «Таныш моңнар» исемле поэмалар да иҗат итте. Үзе бик ябык, авыру, хәлсез иде. Мин дә шигырьләр язам. «Җәймә, әнкәй, мамык түшәгеңне», «Исмә, әй, җил, чиртмә тәрәзәсен», «Син күңелдә һаман тулган ай» дигән шигырьләремне кат-кат укыта иде Илдар. Ул елларда Хисам Камалов, Марс Шабаев, Роберт Әхмәтҗанов кебек талантлы шагыйрьләр дә укыды. Әмма без Илдар Юзеевның арабызда иң талантлы, көчле, аң-акылга, хис-тойгыларга бай, фикер йөртү офыкларының киң икәнлеген аңладык. Бер шигырь язсак, тизрәк Илдарга күрсәтергә ашыгабыз. Ул бик җитди кылана. Ашыкмыйча, түземлек, сабырлык белән анализ ясый. Мәгәр икейөзлелекне яратмый. Күңеленә ошаса, елмаеп куя, ошамаса, чыраен сыта.

Икенче курста укыганда, мине әдәбият түгәрәгенең старостасы итеп куйдылар. Язучылар союзы белән бәйләнешкә кердек. Талантлы шагыйрь С.Хәким шефлык итте. Кулъязмаларны тикшергәндә, Сибгат аганы институтка чакыра идек. Киресенчә дә була: шигырьләрне турыдан-туры Язучылар союзында тикшертәбез.

Бөтен эшне без Илдар белән бергә башкара идек. Диплом алгач, Илдар «Пионер» журналына сәркатип булып эшкә урнашты. Мин — Актаныш районындагы Бурсык мәктәбе директоры. Бик артта калган мәктәп иде. Өч ел гомер артталыктан алга чыгу мәшәкате белән үтте. Остаханә төзедек. Бер гектар җирне әйләндереп җиләк-җимеш бакчасы ясауга да күп вакыт сарыф ителде. Мине хәтта «агроном» дип атадылар. Бу хәбәр Казанга да барып ишетелгән. Илдар белән булган кайнар дуслык хәзер хат аша дәвам ителә. Бер хатында ул: «Аңла, Суфиян, син администратор түгел, шагыйрь булырга тиеш», — дип язды.

Өч елдан соң мин туган якларыма — Башкортстаныма кайттым. «Кызыл таң»дагы «Нефть-химия» бүлегендә әдәби хезмәткәр булып эшли башладым. 1959 елда Башкорт дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылгач, мине эшкә чакырдылар. Дөресен генә әйткәндә, фән дөньясына керү теләгем юк иде. Мәсьәләне өлкә комитет аша хәл иткәч, бармый нишлисең? Башта кандидатлык диссертациясе язып якларга туры килде. Мәгәр Илдар боларга, әйткәнемчә, теше-тырнагы белән каршы торды. «Ялгышасың, Суфиян, син әдәбият, сәнгать кешесе булырга тиеш», — ди иде очрашканда. Хатларында да, телефоннан сөйләшкәндә дә шул ук сүзләрне кабатлады.

Әлбәттә, миңа фән белән шөгыльләнми булмый. Шулай да әдәби әсәрләр язу теләгем көчлерәк. Анда да чәчелү, таркалу, берьюлы берничә куян койрыгы тоту өстенлек алды. Хикәя, повесть, романнар язам, пьесалар иҗат итәм, тәнкыйть, публицистика белән дә мәшгульмен. Илдар бу чәчелүне яратып бетерми иде. Моны «иҗади дуслык ялкыны» дип атарга мөмкиндер. Илдардагы поэтик ялкын миңа күп көчте. «Исле гөл янында иссез гөл дә хуш исләнә» диләр бит. Илдарның исле гөл булуы аерым каләм осталарына гына түгел, татар поэзиясенең йөрәгенә кереп тә кәрәзләнде.

Илдар эчкерсез, шаян табигатьле, матур күңелле кеше иде. Безне эчке хосусият, рухи халәт, дөньяга карашлар нык дуслаштырды шикелле. Бу дуслык ялкыны иҗатта да балкыды. Әллә ялгыш, әллә язмыш, 70 яшьтән соң мәшһүр язучыбыз, сүз сәнгате остасы Галимҗан Ибраһимов турында трилогия-эпопея («Пәйгамбәр таңы», «Күкнең җиденче катында», «Оҗмахка бер адым») язарга тотындым. «Казан утлары» журналында беренче роман басылып чыккач, Илдардан янә хат килеп төшә. Беренче романда Ибраһимовның балалык һәм яшьлек еллары гына. Илдар романны күккә күтәреп мактый, дәвам итәргә куша. Икенче роман янә «Казан утлары»нда басылгач, тагы да хат алам: «Суфиян, син моны М.Ауэзовның «Абае» кебек трилогия-эпопея итәргә тиешсең», — дип яза.

Алда әйтелгәнчә, Илдар белән мин 1955 елда кулга диплом алгач аерылыштым. Шулай да ике йөрәкне бәйләүче дуслык чылбыры беркайчан да өзелмәде. Даими рәвештә хат алышып яшәдек. Илдар шигърияттәге сүз-сурәтлелекне, идея-эчтәлекне, хис-тойгыны аңлап язучы талантлы шагыйрь, нәфис сүз сәнгате остасы иде. Ләкин беркайчан да мактанырга яратмады. Киресенчә, үзен-үзе тәнкыйть итеп яза иде. Хәер, талантлы каләм остасының һәркайсы да шулай.

Мин, гомерлек дус буларак, һәрвакыт аның шигърият таҗына тагын да ныклабрак менеп кунаклавы турында уйлап яшәдем. Бервакыт, шуны аңлатып, алты битлек хат яздым. Әйтәсе килгән фикер әллә ни зур да, шулай да бәләкәй дә түгел иде. «Тукай шулай дип әйткән», «Такташ болай дип әйткән» кебек образлы, идеяле, эмоциональ гыйбарәләрең юк дәрәҗәдә, Илдар, шуларга да игътибар ит әле син», — дигән идем. Үзем яздым, ә үзем хатны җибәрергә кыенсынам. Ярты еллап ятты. Бервакыт хатны хатыныма күрсәттем. «Нигә куркасың, Илдар — талантлы шагыйрь, аңлар ул синең борчылганыңны, җибәр хатыңны», — диде ул. Шушы ук фикерне уртак дустыбыз булган талантлы шагыйрь Рафаэль Сафин да куәтләде. Шуннан соң гына Уфадан Казанга очты дуслык хис-тойгылары белән тулы булган хат Илдарга.

Ниһаять, беркөн Илдарның рәхмәт әйтә-әйтә язган хатын алдым. Киңәшем турында нык уйлануын әйткән. Яшьлек! Иҗат! Истәлекләр! 2002 елда Илдар Юзеевның биш томлык җыентыгы басылып чыкты. Сагынганда аларның сәхифәләрен актарырга тотынам.

Кабатлап булса да әйтик, иҗади дуслык ялкыны йөрәкләребездә нәкышләнде. Ә инде хатлашу, телефон аша сөйләшү дәвам итте. Соңгы мәртәбә сөйләшүдән җиде көн үткәч, Илдарның гөнаһсыз дөньяга күчүен ишетеп тетрәндем. Әйтелгәнчә, Илдар гомер буе авырып яшәде. Рухи ныклык яшәтте аны. Бу очракта аның гомер юлдашы Тәфтилә ханымны телгә алмый һич мөмкин түгел. Үзенең матди, рухи ярдәме белән генә түгел, кешелеклелек, шәфкатьлелек, эстетик сыйфатлары белән дә озак яшәтте ул Илдарны.

Әлбәттә, Илдар бәхетле! Бу якты дөньяда фәкать якты рух, поэтик хис-тойгы, эстетик матурлык калдырып китүе белән бәхетле!

*Март, 2007*
*Уфа*

**МАРС ШАБАЕВ**

# Юксындыра...

Татарстанның халык шагыйре, М.Җәлил исемендәге комсомол премиясе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Илдар Юзеевның тууына 2008 елның гыйнварында 75 яшь тулган булыр иде.

Без бер тулай торакта яшәдек. Казан дәүләт педагогия институтының Молотов (хәзерге Зур Кызыл) урамындагы элекке хатын-кызлар монастыре бинасы иде ул.

Мин әле беренче курста гына укый башлаган идем, ә Илдар Юзеев инде соңгы курста, укуын тәмамлагач, кайда эшлисе дә билгеле — аны «Пионер» (хәзерге «Ялкын») журналына эшкә чакыралар. Хикмәт шунда, ул елларда татар әдәбияты укытучыларына мәктәпләрдә урыннар юк иде. Һәркем үзенә эш табарга тиеш булды.

Икебез дә булачак әдәбият белгечләре. Икебез дә шигырьләр язып йөрибез. Илдарның шигырь-поэмалары газет-журналларда еш күренә, ә минекеләр юк диярлек әле.

Таныштыруын безне Газиз Мөхәммәтшин таныштырган иде. Газиз — минем якташ. Минем шикелле үк, Минзәлә педагогия училищесын тәмамлагач, Казан дәүләт педагогия институтына укырга килгән, инде өченче курста. Ул да яшь язучылар исемлегендә, матур-матур көлкеле хикәяләр яза, кайберләре «Чаян» журналында да басылгалый иде.

Әле тулай торакка урнашып кына беткән идем, Газиз мине күрде дә:

— Әйдә, Илдар Юзеев белән таныштырам, — дип, тулай торак артындагы ишегалдына алып чыгып китте.

Мин инде Илдар Юзеевның кем икәнен ишетеп тә, укып та белә идем. Чыктык. Анда спорт мәйданчыгы бар икән, егетләр-кызлар шунда туп чөяләр. Карап утыручылары да бар. Газиз мине шулар янына алып килде, аксылрак чырайлы бер егет белән кул биреп күреште дә:

— Илдар, бу минем якташ Марс Шабаев, шулай ук шигырь җене кагылган егет, — диде.

Илдарның кулы дымлы һәм салкынча иде.

— Утыр, — диде ул, миңа урын күрсәтеп. — Мин Башкортстаннан, Яңавыл районының Ямады авылыннан.

— Ә мин Минзәләдән...

Безнең сөйләшү шулай башланып китте.

Без ничектер тиз дуслаштык. Мин үзем табигатем белән «ябалак»: соң ятам, соң торам. Шуңадырмы Илдар һәрвакыт диярлек безнең бүлмәгә керә дә, исәнләшми-дәшми аяк очына утыра. Мин түзмим, аны бер якка этеп, урынымнан кузгалам. Аннары без артык сөйләшми генә урамга чыгабыз, цирк бинасы янындагы кафега ашарга китәбез. Ашап алгач, Илдар:

— Мин институтка барып кайтам, — ди. — Ә син?

— Мин барып тормам инде. Көн уртасында ашханәгә генә сугылырмын.

Хикмәт шунда: без берничә егет ашханә пешекчесенә күпмедер түлибез дә ай буе әбәт ашап йөрибез.

Илдар гармунда әйбәт уйный. Гадәттә бөкрәебрәк йөрсә дә, гармун уйнаганда гәүдәсе төз була, башын гына бер якка кыегайтып куя иде ул.

Без укыган елларда, Иделдә Куйбышев ГЭСы төзелде. Су бик нык күтәрелде. Җәй башы. Вузларда имтиханнар вакыты. Без дә, китап-дәфтәрләребезне күтәреп, Казансу буена ашыгабыз. Юмарт кояш, җылы ком. Чишенеп сузылып ятабыз, баш астында — китап-дәфтәрләр. Рәхәт! Һич укыйсы килми. Әнә кызлар инде суга керергә дә өлгергәннәр. Араларында Илдар Юзеевның якташы Тәфтилә дә бар. Тәфтилә — чибәр кыз. Гел елмаеп кына тора. Ул, физика-математика факультетында укыса да, күбесенчә филологлар белән аралаша.

Мин түзмим, кызлар янына суга кереп китәм. Егет чак бит, кызларны кочаклаган булып чыркылдатып йөрү үзе кызык. Мин Тәфтиләнең иңенә кулымны салам.

— Әй, Шабай! — Илдар кычкыра икән. Миңа бармак яный, үзе көлә: — Тимә минем якташка! — ди.

— Төш безнең янга! — дип чакырам мин аны.

Ул башын гына чайкый. Нигәдер су керүне яратып бетерми иде ул. Керсә дә, бер-ике чумуга чыгып китү ягын карый иде.

Илдар әдәбиятка бик иртә килгән.

— Беренче шигырем район газетасында басылып чыкканда миңа ун гына яшь иде, — дип сөйләгәне хәтердә. Институтка килгәнче үк, Илдарның «Тормыш җиңә» дигән поэмасын укыган идем.

Бервакыт ул миңа:

— Әйдә, бер әйбер укыйм әле сиңа, — дип килеп керде. «Таныш моңнар» поэмасын алып килгән икән.

Укыдык.

— Әйбәт поэма. Тик озынрак шикелле. Ялыктырмасмы? — дидем.

— Ялыктырмас. Бүлекләргә бүләм мин аны. Бүлек башларына исемнәр дә куеп чыгам, — диде Илдар.

Бу поэманың язмышы бик бәхетле булып чыкты. Татарстан радиосы аны радиоспектакль итеп эшләде. Поэмадагы Зөфәр җыры — «Резидәкәй» — яшьләр күңеленә кереп калды. Аны байтак еллар җырлап йөрделәр.

Резидәкәй, зәңгәр күлмәгеңне
Кайсы елгаларда чайкадың?
Синнән гүзәл ярлар күрмәдем,
Синнән гүзәл ярлар тапмадым.

Әйткәнемчә, Илдар «Пионер» журналында эшли башлады. Атнага бер булса да мин аның янына керми калмыйм.

— Ә-ә-ә, килдеңме? — дип каршылый ул. — Менә шушы шигырьләрне карап чык әле. Юньлерәкләре булса, аерып ал, — дип, ул миңа балаларның бер төргәк шигырьләрен тоттыра. Мин карыйм, сайлыйм. Илдар эшләгән елларда «Пионер» журналы тышлыгының өченче битендә укучылар тормышыннан көлкеле рәсемнәр еш бирелә иде. Рәсем аслары, гадәттә, дүрт юллык шигырь белән языла. Аларның байтагын мин дә яздым.

— Яз, яз! — ди Илдар. — Бераз акчасы булыр. Син студентка ярап куя ул, — дип көлә.

Илдар тулай торакка да килеп йөри. Чөнки Тәфтилә әлегә шунда яши, әле студент чагы. Бервакыт Илдар миңа киңәшкә килде.

— Яшь бара, өйләнү турында уйланырга вакыт, — диде ул. — Тәфтиләгә өйләнәм дисәм, нәрсә әйтерсең?

— Үзе ничек соң? Риза булырдаймы? — дип сорадым мин.

— Укып бетергәнен көтәсе булыр инде. Ризамы дип. Без бит икебез дә Яңавылдан. Ул миңа шул чакта ук ошый иде инде. Үзе дә миңа караштыргалый иде шикелле.

— Алай булгач, өйлән, дус, чикмә ваем, Мәхәббәтле гомер бирсен Ходаем! — дип, Тукайча такмакладым мин.

— Шабай, син көлмә әле...

— Һич көлеп әйтүем түгел, Илдар. Өйлән! — Мин өйләнгән идем инде. Шунлыктан: — Рәхәт ул хатын белән яшәве, — дип тә өстәдем.

Шулай итеп, алар өйләнештеләр. Туйларында Роза белән без дә булган идек.

Берәр елданмы Илдарларның малайлары туды. Аңа, Салават Юлаев истәлегенә дип, Салават исеме куштылар. Аннары икенче уллары Илгиз дә озак көттермәде...

И гомер дигәнең тиз дә уза! Салават этисе юлыннан китте — журналист-язучы. Хикәяләре күренгәләп тора.

1973 елда Илдар Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укып кайтты. Укуы иҗатына да зур йогынты ясады. Аның гаҗәп тәэсирле, тарихи тирән эчтәлекле «Таш диварлар авазы» поэмасы нәкъ шул еллар җимеше иде.

Илдар Юзеев шул поэмасы өчен Татарстан Республикасының иң югары әдәби бүләген — Г.Тукай исемендәге премиясен алды.

Илдар Юзеев 2004 елның 21 декабрендә вафат булды, Казандагы татар зиратына җирләнде.

Нинди матур, ерак юлга чыктык,
Янар чәчәк иде юл башы.
Чәчәк сулган, синең йөрәгеңә
Ниләр булган, яшьлек юлдашым?..

Бу җыр Илдарның «Янар чәчәк» пьесасыннан. Чәчәк сулган... Юксындыра Илдар... Юксындыра...

*2007*

**МИРГАЗИЯН ЮНЫС**

# Моңсу шагыйрь

Гомәр Бәширов, Фатих Хөсни, Хәсән Туфан — болар минем остазларым, киңәшчеләрем, әсәрләремә бәя бирүчеләр иде. Ә менә әдәбиятка җитәкләп алып килүче, үземнән яшьрәк булса да чиктән тыш тәҗрибәле, иҗат эшенең нечкәлекләрен энәсеннән җебенә кадәр аңлаучы Илдар Юзеев булды. Без аның белән «Ялкын» редакциясендә минем «Занзибар...»ым шул журналда басылганда таныштык һәм «дуслаштык» дип әйтеп җибәрә яздым. Юзеев белән якыннан танышып, озак еллар серләшеп яшәгәннән соң гына татар әдәбиятының иң моңсу, иң иманлы шагыйре белән дуслашуның җиңел түгел икәнлеген аңлауга ирештем. Дөрес, аның тирәсендә дуслыкларын реклама итеп озак еллар җылысына сырышып түшләренә тагып йөрүчеләр аз булмады. Юзеевның дусты саналу чиктән тыш отышлы иде. Әле дә шулай. Без бит аның журналларда басылган һәм китапка кергән шигырьләрен генә беләбез. Сөйләшкәндә, Илдардан даими шигырь коелып тора иде. Әгәр аңа диктофон тагып йөрткән булсак, Юзеевның сайланма әсәрләре ким дигәндә илле-алтмыш томнан торыр иде.

Илдарның Мәскәүгә ВЛКга (Югары әдәбият курслары) укырга килүе һәм тулай торактагы бүлмәсен «әдәби салон»га әверелдерүе әле дә күз алдымда. Мәскәү — татарларны бик тиз һәм көчле рәвештә руслаштыра торган урын. Мәскәү татарлары бергә җыелсалар, йә өлкән абзыйлар телендә, яисә «мин пыйцак белән картух суйдым...» дип сөйләшәләр. Илдар бүлмәсендә без саф татарча сөйләшәбез. Сөйләшәбез генә түгел, милләтнең берләштергеч гомуми иманы, вөҗданы хезмәтен үтәп торырга тиешле рухи көч — әдәбият белән турыдан-туры очрашабыз. Юзеев вокзалдан Казанга ит җибәреп кайткан. Без килүгә күп итеп ит пешергән. Һәммәбезнең алдында ак кәгазь өстенә куелган зур-зур тәмле майлы калҗа. Итне Алтын Урда, Казан ханлыгы чорында яшәгән бабаларыбызча пешерә белә иде Илдар. Ашыйбыз. «Эчәбез» сүзе батмый, чөнки без сөйләшү тәменең гаҗәеп татлы булуыннан исерәбез һәм хуҗаны тыкырдата башлыйбыз:

— Әйдә, яңа шигырьләреңне укы! Син бит татар шагыйре, классик!

Илдар башта каләмдәшләренең балта белән юнып әмәлләгән шигырьләрен укый. Шул рифмалы халтурага оялаган коры куыклыкка, аларның партиягә, хакимияткә ялагайлануын интонация, басым ярдәмендә фаш итеп укый. Безгә шушы юл белән шигърият илә халтура арасындагы аерманы аңлатып бетергәннән соң гына үз шигырьләренә керешә һәм без иҗатчының үз авызыннан яңгырап чыккан тылсым көченнән изрәп дөньябызны онытабыз. Сәгатькә карасак, метро ябылыр вакыт җитеп килә — саубуллашырга да онытып, ишеккә ташланабыз.

Илдарның җан дуслары күп түгел иде. Аның тыйнаклыгы, изгелеге дуслык дип ялгышып йөрүчеләрне үзенә якынайта алмый иде. Табеев һәм Мөҗәһит Вәлиев чорында Юзеевны берничә тапкыр Язучылар берлеген җитәкләргә кодалап карадылар. Ул баш тартты һәм дөрес эшләде. Өч йөз алты татар язучысы арасында машинага утырып, зур, затлы кабинетның хуҗасы булып Татарстанның җитәкчеләре янында, түшенә депутатлык билгесе тагып йөрүдән баш тарта алган тагын кем бар бездә?! Җитәкчелектән Туфан Миңнуллин киткәннән соң бушаган тәхетне яуларга ташланучылар күз алдыма килеп басканда, мин Илдар турында уйларга тырышам. Шагыйрь күпмедер дәрәҗәдә пәйгамбәр дә булырга тиештер дип уйлыйм мин. Кол Гали һәм Мөхәммәдъяр, Тукай һәм Дәрдмәнд, һичшиксез, пәйгамбәрлек вазифасына таянып иҗат иткәннәр. Хәсән Туфан пәйгамбәр иде, һәм ул эстафетаны Илдар Юзеевка тапшырып китте. Хәзер мин баш ватам: киткәндә, Илдар эстафетаны алырга лаеклы кеше таптымы икән? Бүгенге көндә эстафета кем кулында?

Трибунадан сөйләргә яратмый иде Илдар. Нотык сөйләр өчен фикеремне сүзгә әверелдерә алмыйм дип зарлана иде. Ә инде шигырьләрен сөйли башласа... Нәрсә илһам бирә иде икән аңа бүгенге прагматиклар, җансатарлар җәмгыятендә? Чыннан да, бүгенге көндә рәхәт яшисе килгән кеше иң элек вөҗданын салып таптарга, аннан соң хакыйкатькә арты белән борылырга тиеш. Шуннан соң гына мул, рәхәт тормышта яшәүгә дәгъва кылып була. Илдарның иҗат диапазоны хәйран калдыра мине. «Таш диварлар авазы»ндагы («Без — коллар. Без төрмә салабыз... Һай авыр!») монументаль, колачлы образлар. «Яшь наратлар»дагы лирик нечкәлек, хисләр сафлыгы. Аның турында, сүз дә юк, күп язылган, ә чын-чыннан Илдарның иҗатын тулаем бәяләгән әдәби анализ, белмим, кайчан туар икән?

Илдар Юзеев иҗаты әдәбиятыбызның шигърияткә бай, талантлы шагыйрьләрнең шактый күп чагына туры килде. Шунлыктан аның әдәбияттагы урынын дөрес билгеләү өчен вакыт кирәк. Бүгенге чынбарлык исә әдәбиятны, сәнгатьне акча көче хәрәкәткә китергән бизнес, эшмәкәрлек өлкәсенә сөйри. Менә шундый шартларда Юзеевның әсәрләре тагын да кыйммәтрәк, баерак тоела. Бүгенге чынбарлык исә шундый, әдәбият әкренләп шоу-бизнес тарафына якынлашып бара. Шундый шартларда Илдар иҗатының бәясе, аның әсәрләрендәге риясызлыкның кадере арта.

Илдар Юзеев — шагыйрь. Ул үзе исән чакта ук классик иде. Ә менә драматург буларак аңа кыен булгандыр. Сәхнәне яулау өчен барган көрәш чиктән тыш аяусыз һәм авторның әрсезлегенә бәйләнешле булгангамы, аның пьесаларын сирәк куйдылар һәм тамашачыларның карарга атлыгып торулары да сәхнәдән төшерүгә каршы килә алмады. Бәлки, шагыйрьнең сәхнә серләрен бәяләргә әзер дә булмаганбыздыр. Киләчәктә, мин ышанам, ул пьесалар кабат сәхнәгә менәчәкләр.

Гасыр алышынган 2000 ел. Әлмәт Язучылары берлеге җитәкчесе, Илдар Юзеев һәм Мирсәет Яруллин иҗатларына мөкиббән Разим Вәлиуллин аларга «Ромашкино» санаториена юллама тапты. Шул чакта мин шушы ике шәхес белән унике көн аралашып яшәдем. Унике көн!

Без Герцен белән Огаревның, хәтта Штепсель белән Тарапунькаларның дуслашып яшәүләре турында хәбәрдар. Ә менә Илдар Юзеев белән Мирсәет Яруллин арасындагы озак елларга сузылган рухи яктан саф бу шәхесләрнең сокландыргыч дуслыгы белән кызыксынырга иренәбез. Бергә сабан сөргәндә, печән чапканда, бигрәк тә өстәл янына җыелып «керосин эчкәндә» дуслашу әллә ни катлаулы түгел. Ә менә зыялы белән зыялының дуслыгы... Бу турыда Гамил Афзал:

Шагыйрь белән шагыйрь дуслаша алмый.
Дуслашса да, бары тыштан гына —
Түрә белән бары куштан гына... —

дип язган иде.

Мирсәет белән Илдар бер бүлмәдә яшәделәр. Кичләрен без бергә җыелабыз. Серләшә торгач тарихның яулап алучылар тарафыннан пычратылган, җимерелгән ерак гасырларына, Евразия киңлекләрен кысып кочаклап яшәгән бабаларыбыз арасына, бары тик музыка гына үтеп керә алган кайнар хисләр дөньясына һәм Россиянең мәңге бетмәс михнәтләренә кереп китәбез. Шул сөйләшүләр вакытында Мирсәет үзенең Көньяк Йәмәндә Гарәп диңгезе ярындагы Мукалпа шәһәрендә йөргәнен сөйли. Минем өченче буын татар зыялысын Бәбәль Мандәп бугазы янында очрату мөмкинлегем дә булган икән, әмма Мирсәет белән аралашу бәхетен миңа Илдар бүләк итте. Шул «Ромашкино»да узган унике көн исемә мәңге онытылмас бәйрәм булып кереп калган. Татарның рухи байлыгына зур өлеш керткән шагыйрь һәм композитор, аларның озак елларга сузылган саф дуслыгы күңелне җылытып әле һаман миндә яши бирә.

Мине Казан консерваториясе оештырган иҗат кичәмә чакыргач, анда Илдар да катнаша алмасмы икән, дип сорадым. Шагыйрь консерваториягә миннән алда килеп җиткән иде. Һәм студентлар, укытучылар арасында Юзеевның аларга якын, үз булуы сокландырды гына түгел, хәйран калдырды. Әйтерсең Илдар консерватория остазларының берсе, алар белән бергә яши.

Сүзне Илдар Юзеевка бирделәр. Ул трибунага барышлый түш кесәсенә кулын тыгып карады да капылт кына залдан чыгып китте. Тирән тәэсирле киеренкелек туды. Кичәне ничек дәвам итәргә белмичә аптыраушта утырганда, Юзеев барлыкка килде һәм трибунага юнәлде. Шактый нык бөкрәя төшкән, гәүдәсе сул якка авышып тора. Кораб шундый хәлгә юлыкканда, диңгезчеләр: «Деффирент на нос и левый крен», — диләр һәм балласт танкларына су тутырып турайталар. Илдардагы хасталарның авырлыгын бернинди дәва җиңә алырлык түгел иде. Дәвалану, дару эчү аркасында түгел, үзенең искиткеч гайрәтле һәм саф рухы ярдәмендә шактый озак яши алды ул.

Консерваториядәге кичәдән соң күпме вакыт узды икән? «Илдар вафат бит...» — диләр телефоннан. Юзеевның җеназасында чыгып сөйләүчеләр күп булды. Ярый әле миңа сүз бирмәделәр. Барыбер сөйли алмас идем. Һәм шул матәм көннәрендә мине радиога чакырдылар. Иҗат кичәсендә Илдарның залдан чыгып китүенең сере ачылды. Ул кичәгә миңа багышланган шигырь алып килгән булган икән. Ул аны югалткан һәм икенче көнне залны җыештыручы аны табып алган һәм текстны радиога тапшырганнар. Мин радиодан Илдар турында сөйләгән арада, әлеге шигырьне дә укыдылар. Нишләптер соңгы елларда чыгыш сүзләрен өнәми башладым.

«Сәхнә» журналына эшкә барырга ишек тоткасын кулына алган җиреннән Юзеевны «ашыгыч ярдәм» машинасы алып киткән. Илдар дәрәҗәсендәге шәхесләр эшкә йөрмичә гонорарга яшиләр. Ул соңгы көненә кадәр эшләде. Һәм эшкә барышлый гына фани дөнья белән саубуллашты.

Замандашларымнан мин Мөхәммәт Мәһдиевне, Аяз Гыйләҗевне, Нурихан Фәттахны һәм башкаларны озаттым. Илдар Юзеев та китте. Адәм баласы яшәүдән беркайчан да туймый. Мин ялгыз түгел. Сердәшләремнән Равил Рахмани, Рәис Даутов, Мирсәет Яруллин, Мансур Мортазин, Шәһит Таипов һәм тагын күп кенә якыннарым бар. Нишләптер яшәүдән алҗуны тоя башладым мин Илдар киткәч. Һәр якын дус теге дөньяга синең бер өлешеңне алып китә. Һаман бәләкәйләнәсең, әзәясең... Иң зур өлешне, бәлки, Илдар алып киткәндер?

*18 май, 2007*

**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**

# Тапкыр сүз хикмәте

Дус-ишләрдән берсе: «Илдар Юзеев турында истәлекләр җыентыгы әзерләнә, бәлки, әйтер сүзең бардыр», — дигәч, башта бераз аптырап калдым һәм уйландым.

Уйланырлык та шул: кырык елдан артык таныш һәм, татар әйтмешли, «пачти яшьтәш» булсак та, никтер безгә әллә ни нык аралашырга, утырдаш булырга, ягъни бер-беребезне якыннан белергә туры килмәгән икән. Ә бит очрашкан чакта ихлас җылылык белән кул кысыша, хәл-әхвәл сораша, хәтта үз итешеп сөйләшеп тә алгалый идек. Шуннан арыга никтер узылмаган.

Ә менә бертуган Юзеевларның олысы Нил әфәнде белән мин чагыштырмача якыннанрак аралаштым, дөресрәге, фән буенча беркадәре хезмәттәшлек итү бәхетенә ирештем. Чын галим Нил әфәнде дә, энесе кебек, гаделлек, кешелеклелек һәм зыялылыкның гүзәл үрнәге иде. Ләкин бу язмамда сүз, табигый, Илдар хакында булыр.

Илдар үзе миңа карата күңелендә нинди мөнәсәбәт, нинди хис саклагандыр, анысын төгәл әйтә алмыйм. Ләкин мин үзем бервакытта да аңар карата битараф булмадым. Әсәрләрен күзәтеп бару, уңышлары өчен сөенү, җитешсезлекләренә (миңа шулай булып тоелганнарына — иҗат бит ул бер калыпта гына бармый...) көенү белән бергә аның кайбер хикмәтле сүзләрен, хәтта кеше аркылы ирешелгәннәрен дә ишетүдән үзенә күрә тәм таба, ләззәт хисе ала идем. Илдар әйткәнчә... шикеллерәк берәр сүз башын ишетүгә колакларым үрә тора, тагын нинди тапкырлык күрсәтте икән ул дип, сүзнең дәвамын көтә идем.

Әйе, гаҗәеп бер җылылыкка ия лирик шигырьләр, мәгънәле поэмалар, кызыклы һәм заманча драматик әсәрләр авторы Илдар Юзеевның тагын бер үзенчәлекле сыйфаты, өстенлеге бар иде. Сөйләшеп, әңгәмәләшеп утырган чакта берәр гамәл, фикер яки сүз уңае белән шул мәлдә үк экспромт рәвештә әйтелгән юмористик, иронияле реплика, астарлы, ягъни ике төрле аңларга мөмкин тапкыр сүзләр әйтә алу осталыгы.

Мондый осталык, җәһәт тапкырлык һәркемгә дә, һәр кешегә дә хас түгел, әлбәттә. Бигрәк тә шәхескә каты бәрелмичә, кешене рәнҗетми, кимсетми торган җиңелчә ирония белән шаярта алу осталыгына. Телебезнең үзенчәлегеннән, кайбер сүзләребезнең мәгънә җәһәтеннән сыгылмалыгыннан оста файдалана алу сәләтенә.

Шуны да әйтергә кирәк, мондый сүз уйнату, тел чараларыннан шаярту рәвешендә файдалану гадәте, башкалар белән чагыштырганда, безнең кавемдә ешрак очрый сыман. Моның иҗтимагый сәбәпләре дә бар шикелле... Шуңа күрә мин Илдарның шаяртуларында милли үзенчәлегебезнең бер сыйфаты калкурак чагылганлыгын күргәндәй булам.

Сүз сәнгатенең кыскалык, мәгънәле образлылык һәм күңеллелек хасиятләренә ия булган хикмәтле мөмкинлегеннән Илдар Юзеев бик еш һәм гаять оста файдалана иде. Кайбер очракларда ике-өч сүз белән дә образлы фикерләү тудырырга ирешә ала иде. Шул ук вакытта аның реплика-җаваплары, минемчә, кызык сүз әйтим әле, көлдерим әле бер үзләрен дигән төсле алдан уйланган, максатчан, ясалма сүз уйнату да түгел. Бәлки алар табигый рәвештә, ничек бар, шулай килеп чыккан канатлы үткен сүзләр, гыйбарәләр була иде. Ягъни төрле яктан күрә алу, төрлечә фикерли белү рәвешендә килеп чыккан тапкыр сүзләр. Берничә генә мисал.

70 нче елларның ахырлары иде бугай, Щапов урамындагы Актерлар йортында еш кына ШТМ дип исемләнә торган һәм шуныңише башка күңелле кичәләр, очрашулар уздырыла иде. Берсендә шагыйрь Шәүкәт Галиев белән бергә утырабыз. Халык тәмам җыелып бетмәсә дә, пәрдә ачылып, бер-ике номер да башкарылган иде. Шаяртулары билдән түбәнрәк, җырлары ясалмарак булгангамы, без икебез сытык чырай белән утыра идек. Шул арада яныбызга Илдар да килде:

— Нәрсә суган тәмләп утырасыз, әллә ике ысулы кадимчегә батарлык түгелме болар? — дип, янәшәдәге буш урынга утырды.

Шәүкәт тә аптырап калмады:

— Бераз тыңлагач, үзең дә өченче ысулы кадимче булырсың...

— Әллә, — диде Илдар, — «өч борынга» ук чакырасыз?..

Беркөнне кичкә таба Бауман урамындагы Матбугат йортының дүртенче катындагы редакция мөдире Шәүкәт Галиев бүлмәсендә өч-дүрт кеше, аягүрә нәрсәдер турында кыза-кыза сөйләшеп, бәхәсләшеп тора идек. Шыгырдап кына ишек ачылды, аннан нәшриятның кадрлар бүлеге мөдире Гөлшат Зәйнашева килеп керде.

— Нәрсә, утырыштан киттеме әллә? — дип сорады ул.

— Юк, Гөлшат ханым, — диде Илдар шунда ук, — басыштан китте, басыштан!..

— Әйе, китап басудан, — дип ашыкты сәяси саклык күрсәтүгә яратучан Кыям Миңлебаев.

Ишек ябылуга, Илдар:

— Аллага шөкер, «дагаланган» кешеләр бездә бар икән, әй! — дип йомгаклап та куйды.

Бары шуннан соң гына рәхәтләнеп көлештек.

«Дагалану» хакындагы төрттерү, бер карауга, артык сәяси саклыктан көлү булса, икенче яктан, андый саклыкның да сәбәпләренә ишарә бар иде. Чөнки күп мәгънәле, астарлы сүзләр куллануның көлкеле генә түгел, күңелсез нәтиҗәләре дә булгалаган. Ерак заманнарга, патшалар чорына барып тормыйча, үз гасырыбыздан да күп кенә мисаллар таба алабыз.

Әдәбият тарихлары әтрафлап, җентекләп өйрәнелгән, бигрәк тә шәхесләр роленә тиешле игътибар бирелгән җәмгыятьләрдә андый тел-сүз «кыйпылчыклары» һәрвакыт исәпкә алына; әдипләрнең тормыш юлларын, иҗатларын яктыртканда, алар хәрәкәткә кертелә, ягъни файдаланыла. Шуңа күрә конкрет шәхесләрнең андый үзенчә күрә белү һәм фикерләү «чаткыларын», дөресрәге, тел-сүз энҗеләрен «әйткән — беткән» рәвешендә бер көлеп кенә селтәп ташламыйча, эзлекле рәвештә җыеп барасы, гадел һәм дөрес итеп теркәп куясы иде. Алар иҗат иясенең шәхесен дә, ул яшәгән, кайнаган мохитнең, хәтта чор-гасырларның үзенчәлекләрен дә дөресрәк аңларга, аңлатырга ярдәм итәчәкләр.

Илдар Юзеев мирасында да аның бу жанрдагы канатлы сүзләре, оста шаяртулары, мәгънәле репликалары күп булырга тиеш. Аларны җыясы, теркәп калдырасы иде.

*Август, 2007*
*Наратлы*

**МИРСӘЕТ ЯРУЛЛИН**

# Асыл зат иде...

1955 елның октябрь ае урталарында язучыларның Г.Тукай исемендәге клубында яшьләр иҗатына багышланган кичә уздырылды. Кичәдә И.Шакиров, Ә.Авзалова, Ф.Әхмәдиев, А.Батыршин, шулай ук шагыйрьләр һәм башка артистлар бар иде. Шул исәптән Казан музыка училищесының беренче курс укучысы мин дә чакырулы идем. Менә шушы кичәдә Илдарны беренче күреп таныштым. Тора-бара бу танышуыбыз Илдарның вафатына кадәр сузылган дуслыкка әйләнде.

Искиткеч үзенчәлекле талант иясе, сабыр, зирәк акыллы һәм юморга бик бай мондый асыл зат белән танышуым өчен язмышка зур рәхмәтлемен. Илдар янына мин еш кына Матбугат йортына килә идем, ул да башта музыка училищесына, аннан консерваториягә килгәли иде. Беренче тапкыр халыкка композитор буларак танылуым да Илдар белән бәйләнешле.

1961 елны Г.Камал исемендәге театр Илдарның «Янар чәчәк» пьесасы буенча спектакль әзерли башлады. Шушы спектакльгә музыка язарга мине чакырдылар. «Янар чәчәк»тән «Фәүзия җыры», «Лира җыры» тиз арада бигрәк тә яшьләр арасында популяр булып китте.

Озак еллар аралашу нәтиҗәсе буларак без бергәләп шактый күп җырлар иҗат иттек. Мәсәлән, «Серле чәчәк», «Канкай углы Бәхтияр», «Яшьлек дустыма», «Таң кызы» һәм башкалар. Бу җырларның һаман да репертуарда саклануында, әлбәттә, Илдарның югары зәвыклы текстларының әһәмияте бик зур.

Мин әдәбият белгече дә, тәнкыйтьче дә түгел. Шулай да Илдар шигырьләрен кемнәргәдер ошасын дип язмый иде дигән уйда торам. Аның һәрвакыт үз карашы, принципиаль позициясе бар иде. Бу урында И.С.Тургеневның Пушкин турында әйткән фикерен искә төшерәсе килә. «Независимый гений Пушкина скоро освободился и от подражания европейским образцам и от соблазна подделки под народный тон. Подделываться под народный тон, вообще под народность — так же неуместно и бесплодно, как и подчиняться чуждым авторитетам...» (И.С.Тургенев. Избранное. Москва: Современник, 1981, 589 с.).

150 еллар чамасы вакыт үткәч, Илдар Юзеев бөек урыс язучысы фикеренә бик тәңгәл килә торган үз сүзләрен әйтә. «Мин аның «Пиросмани» (Зөлфәт шигыре) турындагы шигырен кат-кат укыдым. Мондый шигырьләр әзерлекле, зыялы укучыны сорый. Болары да булсын: поэзия гади укучыдан алдарак барырга тиеш тә. Әнә шул миссиясен югалтуы сәбәпле җыр жанры үзешчән дәрәҗәдә бер урында таптана, алга китә алмый» (И.Юзеев. Сайланма әсәрләр. 2 т., Казан: Татар. кит. нәшр., 2002, 122 б.).

Илдарның таланты укучыларын үз артыннан ияртеп барырлык көчкә ия иде. Аның белән якыннан аралашкан әдипләр дә һәммәсе үзләренең әсәрләре белән милли хәзинәбезнең алтын фондына үз өлешләрен керткән шәхесләр. Аларның исемнәрен генә санап чыгу да күп урын алыр иде. Шулай да Илдарның өендә танышкан берничәсен әйтеп китәсе килә: Миргазиян Юныс, Әнгам Атнабаев, режиссер Рифкать Исрафилов — искиткеч кызыклы шәхесләр.

Хәтерлим, Илдар «Татар моңы» һәм «Фәтхрахман» поэмаларын беренче булып миңа укыды. «Фәтхрахман» поэмасы бигрәк тә нык тәэсир итте. Соңгы юлларын укыганда, Илдарның тавышы карлыгып калды, авырлык белән укып бетерә алды. Шулчак безнең икебезнең дә күзләребездә яшь иде. Беркайчан онытылмас мизгел.

Язмамның башында Илдарның юморга бик бай булуы турында сүз булган иде. Бер очракны искә төшерәсе килә. Мин Матбугат йортына Илдар янына килдем. Ул эш бүлмәсеннән чыкты да, без йортның Язучылар союзы урнашкан башындагы вестибюльдә басып сөйләшеп торабыз. Шул вакыт Сибгат ага Хәким килеп керде. Алар бер-берсен бик хөрмәт итәләр иде һәм «син» дип сөйләшәләр.

Матур гына исәнләшеп хәл-әхвәл сорашып алганнан соң, Сибгат ага Илдарга сүз кушты һәм алар арасында әңгәмә башланды, моны күреп мин бераз гына читкә тайпылдым. Ике олпат шагыйрь нинди проблема хәл иткәннәрдер, бик ачык хәтерләмим, ләкин бервакыт Илдар әйтеп куйды: «Сибгат абый! Син Ленин урамында «Күңелем Ленин белән сөйләшә» дигән җыр текстыңны уйлап йөргәндә бит инде синең башыңнан бүрегеңне алып киттеләр, шулаймы?» Сибгат ага «кхем, кхем» дип куйды да сүзен дәвам итте. Бераздан Илдар тагын: «Шуннан соң бит инде син «Башка берни дә кирәкми» дигән җырыңны яздың», — диде. Сибгат ага тагын Илдар сүзләренә бик игътибар бирмичә генә сүзен дәвам итте. Мин инде түземсезлек белән Сибгат ага ничек җавап бирер икән дип көтәм. Әңгәмә тәмамланып, Сибгат ага китә башлагач кире борылды да: «Илдар, син ике ел Мәскәүдә укып кайттың бит әле, юкка гына язмагансың инде «Җирдә калсын эзләрең» дип», — Илдар шигыренең бер юлын әйтте дә китеп - барды.

Татар халкының бөек улы, көне-төне иҗат утында янган, милләтебезгә искиткеч зур хәзинә бүләк иткән Илдарыбыз хәзер безнең арада юк инде. Ләкин шагыйрь Илдар Юзеев һәрвакыт безнең белән.

**РАВИЛ ТУМАШЕВ**

# Теләктәшләр булып...

Безнең Илдар белән әле күрешмичә танышуыбыз «Бөркетләр кыяга оялый» спектакле турындагы очрашуыбызга хәтле үк булган иде.

1954–1955 елларда аның яшьләр арасында ул елларны (һәм соңыннан да) бик популяр «Таныш моңнар» исемле беренче поэмасы дөнья күрде, һәм ул елларны Республика күчмә театрының баш режиссеры булып эшләгән әнием Кәшифә Тумашева миңа бу әсәр белән танышырга тәкъдим итте.

Ул әсәрнең инсценировкасы Академия театры артисты һәм композитор Шакир Мәҗитовның үзе тарафыннан язылган музыкасы белән Казан радиосы аша бик еш тапшырыла иде, ләкин мин аны ишетмәдем һәм нигәдер ул авторлар белән элемтәгә керергә ашыкмаган идем, әмма алар (Шакир Мәҗитов һәм аның хатыны Академия театры артисткасы Фатыйма ханым Камалова) минем белән иҗади элемтәгә керергә бик тә телиләр иде шикелле. Ниһаять, әни ул спектакльне үзе куярга булды, һәм ул шактый уңышлы гына гастрольләрдә уйналып кайтты.

Әле танышып очрашуыбызга хәтле, без Илдар белән берникадәр иҗади бәйләнештә идек инде. Сүзне үзенә биреп карыйк әле:

— Минем драматик әсәрләремә ишекне Татар дәүләт күчмә театрының режиссеры Равил Тумашев ачты. 1957 елда Татарстан радиосыннан «Таныш моңнар» поэмасы яңгырагач, радиопостановкага көйләр иҗат иткән композитор Шакир Мәҗитов миңа шул әсәр нигезендә бергәләп комедия язарга тәкъдим итте. «Мин аны сәхнә әсәре, бигрәк тә комедия итеп күз алдына китерә алмыйм» дип, мин баш тарттым. Шакир абый берүзе «Резидәкәй» дигән пьеса язды. Ни гаҗәп, аны Татар дәүләт күчмә театрының ул чактагы режиссеры Кәшифә Тумашева сәхнәләштерде. Шулай итеп, минем киләчәктә туачак драматик алымымны иң беренче аңлаучы Кәшифә Тумашева булды дип әйтә алам. Аңа алмашка килгән улы Равил Тумашев мине театрга тартып китерде. Һәр авторның үзенчәлеген, алымын аңлаучы, һәр әсәремне җиренә җиткергәнче эшләтүче режиссер минем алты әсәремне сәхнәгә менгезде. Ул вакытта театр чын мәгънәсендә драматургларның иҗат лабораториясенә әйләнде. Р.Тумашев — әзер әсәрне сәхнәгә куючы гына түгел, репетицияләрдә артистлар өчен, пьесаны куярга әзерләгәндә драматурглар өчен тәҗрибәле педагог, иҗат кешесе.

Шактый өлеше шигырь белән язылган «Бөркетләр кыяга оялый» водевилен Р.Тумашев Күчмә театр шартларында да тамашачыларны рухи кыяга менәрлек итеп, поэтикасын югалтмыйча куюга иреште.

«Улыбыз өйләнә — без аерылышабыз» исеме белән Татар дәүләт академия театрында Дамир Сираҗиев куйган спектакль, гәрчә тамашачы тарафыннан яратып каралса да, андагы бөркетләр кыядан җиргә төшкән иде, шигъри өлеше прозалашкан иде.

Аннан соң бер-бер артлы «Сандугачлар килгән безгә», «Кыр казлары артыннан», «Кайтмый калсам, көтәрсеңме?», «Онытылмас бәет», «Бәхетемнән узып барышлый» дигән пьесаларымның Р.Тумашев тарафыннан куелуы — драматург буларак минем Күчмә театрдан башка режиссерга күчмәү чорым. Ул пенсиягә киткәч, минем күчмә тормышым башланды...»

Безнең Илдар белән булган мөнәсәбәтләр чын дусларча иде. Башкача була да алмый иде, чөнки ул миңа тәкъдим иткән һәр әсәрендә мин аның кешеләрдә иң элек алардагы матурлыкны күрә белүен тоя идем. Ә инде калганы эш дәверендә чарлана иде. Күп вакытта Илдар минем белән бик тиз килешә иде һәм мин тәкъдим иткән төзәтмәләргә каршы килми иде.

Әмма, ни сәбәпле икәнен хәтерләмим, ләкин бер онытылмаслык һәм Илдарга хас булмаган вакыйганы искә төшерә алам.

«Бәхетемнән узып барышлый» спектакленә репетиция барган вакытта булды бу хәл: Илдар тамашачылар залында утырып сәхнәдәге вакыйгаларны күзәтеп бара иде, ә мин, әлегә репетициядә катнашмаган бер артистым белән аның башкарган образы турында бәхәсләшеп, үземчә аңлатып биргәндә, Илдар кинәт кенә, кулларын ике якка кайтара-кайтара, үзенең сәхнәдәге репетициягә карата ризасызлыгын катгый рәвештә белдереп, сәхнәгә таба йөгереп килде дә: «Болай булмый, ярамый болай!» — дип, үзенең килешмәвен белдерде. Йөзе кызарган, хәтта иреннәре дә калтырана иде. Әмма бераз гына аңлашкач, вакыйганың ни дәрәҗәдә ачык һәм хаклы булуына ышангач, ул шундук көлә дә башлады. Күп вакытта ачык чырайлы, көләч йөзле һәм тапкыр сүзле була иде ул. Шундый булып исемдә калды да.

Илдар белән беренче очрашуыбызны мин хәзер хәтерләмим, ләкин аның үзенең яңа әсәрләрен артистларча укуы бүгенгедәй күз алдымда. Берникадәр карлыккан тавышы белән ул тыңлаучыларга әсәрендәге геройларының кичерешләрен аеруча җиткерергә тырыша иде. Шул ук вакытта кул хәрәкәтләре белән укылган кайбер урыннарын дирижерлык итеп тә ала иде.

Безгә Илдар белән бервакытта да кискен каршылыкка җиткәнче бәхәсләшергә туры килгәне булмады, чөнки аның да, минем дә кешелек дөньясын күреп, кешенең төп сурәтен аңлавыбыз

бертөрлерәк иде шикелле, һәм аның әсәрләрендә салынган төп фикерләр белән мин һәрчак килешә идем.

Әмма «Сандугачлар килгән безгә» әсәренә ясаган яңа төзәтмәләрен мин аңламадым да, кабул да итмәдем. Аларның хата булуларын мин Илдарга яшермичә туп-туры әйттем. Килештеме ул минем белән, юкмы, анысын әйтә алмыйм, әмма 1992–1993 елгы спектакль үзгәрешсез барды, һәм Илдар аны карап кабул итте. Бу хәлнең килеп чыгуы кайбер тәнкыйтьче-рецензентларны аптырашта калдырып ялгыш фикерләр ясарга һәм буталышларга китерде. Аларның фикерләүләрен укып, әллә болар әсәрнең беренче вариантын бөтенләй белмиләр дә микән дип уйлыйсың. Ярый, калдырып торыйк үзләрен. Шунысы кадерле: Илдар белән без теләктәшләр булып яшәдек һәм шундый булып калабыз.

**ГАЙНУЛЛА ШАКИРОВ**

# Сагыш

Мин үзем шагыйрь дә, язучы да түгел. Шуңа карамастан әдәбияттан читтә тормыйм, күп кенә язучыларның әсәрләре белән танышып барам, ә Илдар Юзеевның бер китабын да укымыйча калдырмадым. Кәеф бераз сүрелеп торса, аның шигырьләрен укып күңелне күтәрә торган булдым.

Илдар! Илдар Илдар гына түгел, ул гасырыбызның әдәбият чишмәсе. Күз алдына гына китереп карагыз: Илдар 40 тан артык китап бастырып чыгарды. Күпме шигырьләр, поэмалар, пьесалар, җырлар сыйдырды икән алар.

Илдарлар белән без семья дуслары булдык. Шәүкәт Галиев, Мирсәет Яруллин һәм башкалар. Бәйрәмнәр гел бергә үтә иде. Табында өч гармунчы, шуларның икесе танылган композитор. Җырчылар да юк түгел иде. Шуңа күрә табын бер зур хорга әйләнә торган булды. Илдарның кечкенә генә хромкасы бар иде. Бераз кызып киткәч, Илдар шул хромкасы белән «Баламишкин»ны уйный башлагач, бөтенләй аңлый алмаслык күтәренкелек, моң чорнап ала иде. Илдар шулкадәр бирелеп уйный иде хромкасында, бу тирә-юньдәге булган бар моңнарны үзенә җыя мәллә дип уйлый идек. Баяннар, аккордеоннар бөтенләй кырыйда торсыннар ул вакытта. Җаннарны айкый торган моңнар белән озата иде ул кунакларны. Илдар үзен бер дә эре тотмады, бервакытта да бернәрсә белән дә масаймады. Һәрвакыт гади булып калды. Аның белән төрле темага сөйләшеп була иде, аның белән бер сөйләшү яхшы лекция тыңлаудан ким булмый иде. Ул сөйләшүдә күтәрелгән сораулар турында соңыннан озак вакытлар уйлыйсың, үзеңә берәр файдалы һәм кирәк нәтиҗә ясап тормышта кулланырга тырышасың. Хәтер бит ул, нишлисең, бергә булган чакларга әйләндереп кайтара, уйлата, шул вакытлар бик сагындыра.

*6 июнь, 2007*

**РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН**

# Яңавылга — Илдар Юзеевның туган җиренә бер сүз

Туган илсез, туган җирсез
Шагыйрь нишли ала ул?
Мәхрүм итмә нигезеннән
Шагыйреңне, Яңавыл!

Исән булганда нигезе
Әле дөрләп яна ул.
Янсын әле! Яндыр әле
Шагыйреңне, Яңавыл!

Шагыйрьнең аның җанында
Йә ташкын да йә давыл.
Давыл җанлы шагыйреңнең
Кадерен бел, Яңавыл!

Шагыйрьләрнең бу дөньяда
Язмышлары, ай, авыр.
Яңа җыр яза шагыйрең —
Доганны кыл,
Яңавыл!

**МӘСГУТ ИМАШЕВ**

# Җырлап узган гомер арасы...

...Мә, ал, дускай,
Узар яшьлегебез
Истәлеге итеп карарга —
Җырлар бирәм,
Моңлы җырлар бирәм,
Җил дә алмый
Һәм кырау да тими аларга...

*И.Юзеев. «Җырлар бирәм»*

1952–1956 елларда Казаннан килеп торган газеталарданмы, журналданмы кулыма кергән шушы шигырьне һәвәскәр артист буларак туган ягымда — Пермь якларында — бик яратып сәхнәдән укып йөрдем. Казан радиосыннан, күземнән яшьләр килә-килә, «Таныш моңнар» поэмасын, андагы Зөфәр белән Резидәнең моңлы мәхәббәт җырларын тыңлаганым да булды. Ләкин ул вакытта әлеге шигырьнең һәм бу радиоспектакльнең авторы Илдар Юзеевны кайчан да булса күрә алуым уема да килмәде. Минем өчен, Уралдагы бер хәрби заводның яшь эшчесе өчен, Казан шәһәре, андагы шагыйрьләр, гомумән, акыл ияләре, татар мәдәнияте кешеләре бик еракта, буй җитә алмаслык югарыда иде...

Еллар үтеп, батырчылык итеп Казан консерваториясенә укырга килеп кергәч, әкрен генә әдәбият, сәнгать вәкилләре белән аралаша башладым.

...Илдар Юзеев белән беренче очрашуыбызны хәтерләмим, һәрхәлдә, ул берәр әдәби-музыкаль кичәдә булгандыр. Ихтимал, Бауман урамындагы Матбугат йортының Тукай клубында күрешкәнбездер — ул елларда язучыларның халык белән очрашу кичәләренә безне, студент-җырчыларны, еш чакыралар иде.

...Нинди генә чыганакта (газетамы, журналмы, китапмы) очратсам да, Илдар Юзеевның шигырьләрен, поэмаларын мин яратып, йотлыгып укый идем һәм, үзе белән күрешкәндә, шушындый мөлаем, юаш, тыйнак, аз сүзле кеше ничек йөрәккә үтеп керердәй сүзләр табып, укучының тирән хисен кузгата торган әсәрләр иҗат итә ала икән дип шakkата идем.

Ниһаять, 1960–1961 елларда безнең аралар бик якынаеп китте. Мин укуым белән бергә Камал театрында артист булып эшли башладым, һәм шул сезонда Илдар Юзеевның «Янар чәчәк» комедиясе сәхнәләштерелде. Шәүкәт Биктимеров, Вера Минкина, Рауза Хәйретдинова, Вәкил Закиров, Асия Галиева, Рәсим Сәлахов, Дэллюс Ильясов, Ибраһим Гафуров, Габдулла Фәтхуллин, Газиз Зыятдиновлар белән бергә мин дә уйнадым ул спектакльдә — ролем Җидегән исемле парторг иде. Беренче репетицияләргә автор да килеп, режиссер Празат Исәнбәттән рөхсәт сорап кына үзенең кайбер җөмләләрен төзәткәләгәне исемдә. Комедиядә төп образлар үзләренең хисләрен җыр белән дә аңлаталар иде, моны драматург музыканың тамашачыларга тәэсир көчен аңлап шулай эшләгән, күрәсең. Ул әсәргә музыка язган композитор Мирсәет Яруллинның (Илдар Юзеевның бик якын дусты) көйләре әле бүген дә халык арасында яратып җырлаundalар. Мин бу спектакльдә дә, гомумән, концертларда да Илдар Юзеев шигырьләренә язылган байтак җырларны яратып җырладым һәм җырлыйм: «Кайтам инде» (С.Садыйкова), «Резидәкәй», «Шофер» (Ш.Мәҗитов), «Серле чәчәк», «Яшьлек дустыма» (М.Яруллин), «Сине уйлап янам» (С.Ибраһимов), «Яшь наратлар» (Җ.Фәйзи), «Төнбоек» (Л.Айтуганов) һәм, әлбәттә, көйләрен үзем язган җырлар. Ә инде җыр укытучысы буларак бүген мин театр училищесында үземнең класста һәр студентка Илдарның лирик һәм патриотик җырларын өйрәтми калмыйм. Аның нечкә хисле шигырьләре ничаклы композиторларның күңел кылларын тибрәткән бит: әле аталганнардан тыш Ф.Әхмәтов («Яшьлегем кояшы»), Ф.Мортазин («Хуш инде»), А.Гыйләҗев («Мәтрүшкәләр»), Р.Хәким («Бездә бәйрәм, бездә туй»), А.Монасыйпов («Ай моңы»), З.Хәбибуллин («Ерактагы үзәннәр»), И.Сафин («Онытма мине»), Р.Абдуллин («Балачак чишмәсе»), В.Әхмәтшин («Җиләккә дип барган идем») һәм башкалар. Мин үзем дә Илдарның биш спектакленә көйләр язганмын: «Кыр казлары артыннан», «Сандугачлар килгән безгә» (К.Тинчурин театры), Гашыйклар тавы, «Олы юлның каены» (радиоспектакльләр), «Онытылмас бәет» (театр училищесы). Спектакльләр өчен язылган җырларның кайберләре тамашачы күңеленә хуш килеп, сәхнәдән аерылып та яши башладылар — бу икебез өчен дә зур шатлык, билгеле.

Берсендә «Олы юлның каены»на көйләр язар алдыннан мин каушап калдым. Чөнки Илдар катгый шарт куйды: «Туган ягым каеннары» дигән җыр халыкчан булып, халыкка таралып китәргә тиеш», — диде ул. Мин шигырьнең һәр юлы азагында кабатланып килгән «инде» дигән сүз белән нишләрмен икән дип сагайдым... Әмма көй язылды, һәм Илдарның теләге кабул булды — радиоспектакль эфирда

яңгырагач (җырны төп герой ролен башкаручы Илдар Хәйруллин җырлады), бу җыр, чыннан да, безнең шатлыкка, халык арасында җырланып, яшәп китте.

Илдарга да, миңа да сөенечле мизгелләр бүләк иткән, безгә канатлар үстергән тагын бер генә җырыбызны атап үтәсем килә. Анысы — К.Тинчурин театрында Исламия Мәхмүтова җырлаган «Кыр казлары артыннан». Пьесаны укыганда ук мин Ясминә образын бик кызганып, аның җырының сүзләре белән танышкач, хисләрем нечкәреп, күңелем йомшап, нык тетрәнгәнемне хәтерлим — Илдарның җыр сүзләрендәге гомумиләштерелгән мәгънәви тирәнлек, героиня язмышының чарасызлыгы мине шундый халәткә китерде ки, көй язылып беткәнче йөрәгем ярсудан туктамады... Шөкер, бу җырыбыз да моңлы кешеләрнең күңелләрен юата дип беләм — радиога килгән сорауларның күплеге шуның дәлиле.

Илдар Юзеев әсәрләрен укыганда, аның шигырьләренә көйләр язганда, мин тирән эстетик канәгатьләнү кичерәм һәм үземне бик бәхетле тоям, миңа яшәве рәхәт. Поэмаларындагы лирик геройлары белән бергә тәүге мәхәббәт хисләремне яңартам, тискәре образларга нәфрәт уяна, дөньякүләм иҗтимагый проблемалар күтәргән бәгъзе поэмалары эченә «кереп китеп», автор белән бергә планета язмышы өчен борчыла башлыйм («Тынлык белән сөйләшү», «Таш диварлар авазы», «Фәрит-Фәридә», «Язылмаган поэма» һ.б.) — шагыйрьнең җанлы, ягымлы сөйләшүе, фикерләве, кызыксындыра белүе мине беркайчан да битараф калдырмый.

1976 елда Камал театры К.Әмировның Әфган сугышы турында «Зөлфия» дигән пьесасын куя башлады, музыкаль бизәлешен миңа тапшырдылар. Спектакльдә Әфганстанга эләккән бер егет әнисен сагынып җыр чыгарырга тиеш. Пьеса авторы җыр сүзләрен язмаган. Мин нишләргә тиеш — озак уйлап тормастан Илдар Юзеев шигырьләрен, поэмаларын актарам, сагыну хисләрен тирән чагылдыра белгән шагыйрь дустым иҗатында кирәкле шигырь табачагыма ышанам. Һәм 1960 елларда язылган «Әнкәй» поэмасында нәкъ миңа кирәкле сүзләрне таптым:

Улың киткән якка күзең текәп
Торасыңмы капка төбендә?
Аңлыйм, әнкәй, ямансудыр сиңа
Ялгыз яшәү картлык көнендә...

Спектакльдә җырны, үзе гитарада уйнап, Николай Юкачев җырлады, матур җырлады. «Нигә килми, әнкәй, хәбәрең?» дигән бу җыр Илдарның күңеленә дә хуш килде.

...Казанда да, республикабыз районнарында да күпсанлы шигъри-музыкаль очрашуларда бергә катнашуыбыз Илдар белән безне якын иҗатташ дуслар итте. 1971 елны Һади Такташ юбилеена, аның туган авылы Сыркыдыга (Мордовия) зур төркем язучылар, артистлар барганыбыз хәтердә саклана. Иҗаты буенча Илдарны шәхсән мин Такташның дәвамчысы дип саныйм.

Муса Җәлилнең 80 еллыгына бугай безне икебезне Ягъфәр Камалов атлы корреспондент егет инициативасы белән Пермьгә дә чакырдылар. Зур Мәдәният сараеның 1200 кеше сыешлы шыгрым тулы залында Илдар Җәлилнең тормыш юлын сөйләде, шигырьләрен һәм үзенең аңа багышланган әсәрләрен укыды, мин М.Җәлил сүзләренә язылган җырлар җырладым; шәһәр һәвәскәрләре концерт бирде. Барганда да, кайтканда да юлда Илдар белән сөйләшеп рәхәтләндек, нинди генә темаларга кагылмадык без! Кайтыр көнне, Казанга туры самолет булмыйча, Ижауга очтык. Ижау пилотлары, Казанга килеп җиткәч, җиргә төшәр алдыннан нигәдер шәһәр өстендә зур божра ясадылар. Шул вакыт Илдар, мине иллюминаторга якынрак чакырып: «Кара әле, Мәсгут, Казаныбызның гүзәллеген, ул Иделне әйтимме, Кабан күлләренме, Болак буйларын, — ничаклы сулыклар, Сөембикә манарасы белән Кремль... Венецияләрең, Парижларың бер читтә торсын, малай», — ди. Ә мин аның Казан белән горурлану хисе чагылган нурлы елмаюлы йөзенә сокланып карап утырам.

...Тормышта аз сүзле булуына карамастан, дуслар җыелган җирдә Илдар нинди дә булса бер шаян сүз әйтми калмас иде, йә шундагы берәр шәхескә төрттерә, йә берсенең җитди сүзенә, рифмалаштырып, шук «койрык» ясап куя... Минем фамилиямне дә бер шаян такмакка тагып уйнатканы булды. Бервакыт шулай күп кенә язучылар, артистлар автобуста очрашуга барабыз... Казан уртасындагы трампаркның озын агач коймасының буеннан-буена кеше зурлыгындагы хәрефләр белән «ОКРАШЕНО» дип язып куйганнар. Шуны күрүгә, Илдар шагыйрь Гәрәй Рәхимгә (керәшен егете Григорий Родионов) мөрәҗәгать итә: «Гөргөри, карале монда, сезнең халыкны зурлап, итальянча лозунг язганнар, беренче «О» дан соң өтерен куярга гына онытканнар», — ди. Һәммәбез тәрәзәгә ябырылдык, һәм Гәрәй белән бергә рәхәтләнеп көлештек, аның җавабы бер генә сүз булды: «А как же!» — диде ул.

...Безнең өйдә Илдар Юзеевның дистәләп китабы бар. Шуларның икесе шагыйрь дустымның кадерле автографлары белән. «Соңгы сынау» дигән драматик легендасы басылган китабының әсәр исеме язылган битендәге култамга: *«Мәсгут! Бу әсәр иң соңгысы булмас дип уйлыйм... Илдар Юзеев, 13 март, 1971, Саба районы».* Ә «Яшьлек дустыма» дигән китабына Илдар мондый сүзләр язган: *«Мәсгут! Картлык дустым да син булсаң иде... Илдар Юзеев, 1971, март, Саба районы».* Күренгәнчә, бу китаплар Саба якларында очрашуларда йөргәндә бүләк ителгәннәрдер.

...Илдар Юзеев үзе исән вакытта аның шигыренә, аның үтенече белән язылган соңгы җырыбыз «Хуш, исән бул, Яңавылым!» булды.

Мин бит синең кырларыңда
Тәгәрәп үскән бала,
Йөрәгемә суларыңның
Дулкыны күчкән бала.
Китәм инде, хуш, исән бул,
Яңавыл дигән кала!
Бала чакта атлап киткән
Юлларым синдә кала.
Урамнарың, урманнарың
Шигырьләр сөйләп кала,
Өзелеп чыккан сүзләремне
Кошларым көйләп кала.
Китәм инде, хуш, исән бул,
Яңавыл дигән кала!
Яшьлек сыман шаулап узган
Елларым синдә кала.
Яшьлек кала моңсуланып,
Чишмәдәй чыңлап кала,
Синдә туган көйләремне
Кырларым җырлап кала.
Китәм инде, хуш, исән бул,
Яңавыл дигән кала!
Кошларыңа сердәш булсын, —
Җырларым синдә кала...

Минем өчен бу җыр Илдар дустымның дөнья белән бәхилләшүе булып калды.

Соңгы 4–5 елын ул ничек тә үзенең 70 яше тулган көннәрен күрәсе килеп яшәде, һәм, Аллага шөкер, бу теләгенә ирешеп, иҗатының алтын тантанасын күреп китте.

Урының җәннәттә булсын, якын иҗатташым, меңнәрнең рухи дусты, киңәшчесе, юатучысы!

*9 гыйнвар, 2007*

**ШӘҮКӘТ БИКТИМЕРОВ**

# Яшәргә стимул биреп китте

45–50 нче еллар. Без — театр училищесын тәмамлаган яшь артистлар. Минем белән бергә Айрат Арсланов, Мәрьям Арсланова, Әминә Сафиуллина, Ринат Сакаев, Госман Әхмәтҗанов һ.б. укыдылар. Яшьлек дәрте белән эшли башладык. Сугыш беткән еллар. Күп язучылар әйләнеп кайталмады, күпләре, Хәсән Туфан кебек, авыр язмышларга дучар булды. Кайтканнары җиңү тантанасы, киләчәккә якты өметләр белән тулы әсәрләр иҗат итә. Алар арасында Сибгат Хәким, Зәки Нури, Әнвәр Давыдов, Салих Баттал, Нәби Дәүли, Гамил Афзаллар бар. Без аларның әсәрләрен күтәп кенә торабыз да радиодан, сәхнәләрдән сөйләп халыкка җиткерәбез. Ә 50–60 нчы елларда әдәбиятка сугышта катнашмаган, ләкин аның әчесен тулысы белән татыган яңа буын шаулап-гөрләп килеп керде, һәм алар арасында яшьлек романтикасын, мәхәббәтне җырлаучы тургай булып Илдар Юзеев үз урынын алды. Мин бик күп спектакльләрдә уйнадым, шул исәптән А.Островский пьесаларында да. Шул чорны тирәнрәк аңлар өчен миңа режиссер Габдулла абый Йосыпов Короленконың бер китабын укырга киңәш итте. Ул китап «История моего современника. О шестидесятниках 19-го века» дип атала. Шул китапны укыгач, мин үземә бер ачыш ясадым. 19 нчы гасырның уртасында 50–60 нчы елларда әдәбиятта, сәнгатьтә бер күтәрелеш, «всплеск» булган икән. Шул ук күтәрелеш 20 нче гасырның 50–60 нчы елларында, ләкин инде яңа сыйфатта, алга китеш белән.

Бауман урамындагы Матбугат йортының бишенче катында Тукай клубы бар иде. Аның авыл өендәге сәке хәтле генә сәхнәсе, сәхнәдә Тукай портреты тора. Атна саен шунда әдәби җомга уздыралар иде. Шагыйрьләр, прозаиклар яңа әсәрләрен укыйлар. Х.Туфан, Г.Бәширов, С.Хәким кебек мәшһүр әдипләр дә катнаша иде. Зал шыгрым тулы, сыймаганнары коридорда басып тыңлыйлар. Аннан алып чыккан хисләр киләсе җомгага хәтле сүрелми, җомганы түземсезлек белән көтеп алабыз.

Ул вакытта «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы ай саен күзәтү алып бара иде. Яңа шигырьләрне, проза, драма әсәрләрен укып бара идек. Алар кечкенә генә брошюра кебек, кесәгә сыярлык китап булып та чыгалар иде, бәясе дә 30–40 тиен генә. Илдар Юзеевның мин бөтен шигырьләрен, поэмаларын радиодан, сәхнәләрдән сөйләп чыкканмын икән. Аның китаплары кесәдә йөреп тузып беткән, ләкин һәммәсе исән, һәммәсен саклыйм. Шулай итеп Илдарның үзе белән танышканчы мин аның иҗаты белән таныштым һәм нинди шәхес, нинди талант иясе булуын белә идем инде. Илдарның поэмалары буенча күп радиопостановкалар куелды, мин анда геройларын уйный идем. 1956 елда Илдарның «Таныш моңнар» поэмасы китап булып чыкты. Хәким абый Сәлимҗанов күреп алган да: «Куябыз, — ди, — Зөфәр ролен син уйныйсың», — ди миңа. Шакир абый Мәҗитов бик матур музыка язды постановкага, шул исәптән Зөфәр җырын. «Мин җырлый белмим бит», — дим Хәким абыйга, ә ул: «Анысы синең эшең түгел, без җырчы таптык инде», — ди. Музыка училищесында укучы, әле беркемгә дә таныш булмаган Илһам Шакиров Зөфәр җырын башкарды. Шуннан соң Зөфәр җырын башкаруны сорап хатлар агыла башлады. Шундый бер вакыйга истә калган. Азнакайда спектакль куйдык, спектакль беткәч, тамашачылар миннән Зөфәр җырын җырлавымны сорыйлар. «Мин җырламадым аны», — дим — ышанмыйлар. Җырла, бетте-китте. Ахырда райкомның беренче секретаре Багаутдинов миңа: «Шәүкәт, җырла инде, халык сорый бит», — ди, артистлар да җырларга куша. Җырларга мәҗбүр булдым. Шуннан соң гына халык ышанды: «Син түгел икән шул», — дип таралыштылар.

Илдар белән якыннан аның «Янар чәчәк» исемле пьесасын сәхнәләштергәндә таныштым. Спектакльгә яшь композитор Мирсәет Яруллин бик матур музыка язды. Әсәрне сәхнәгә Празат Исәнбәт куйды, мин Фәнәви ролен башкардым. Халык бик яратып кабул итте ул спектакльне.

Илдар бик тыйнак кеше иде һәм беркайчан да «минем пьесаны куегыз» дип таләп итеп кеше борчып йөрмәде. Аның күп пьесаларын Күчмә театр (хәзерге К.Тинчурин театры) куйды. Режиссер Равил Тумашев, Илдарның нечкә лирикасын аңлап, аның белән уртак тел табып, театрны зур уңышларга ирештерде. Илдарның драматургиясе дә шигъри, романтик рухта бит. Аның «Кыр казлары артыннан» пьесасындагы җырга Мәсгут Имашев искиткеч матур көй язды, һәм ул җыр адәм баласының бер гимны кебек булып китте. Кеше гомере буе югарыга омтыла бит. Илдарның хыялы кыр казы булып зәңгәр һаваларга менеп җирнең, дөньяның матурлыгын күреп, шуны кешеләргә күрсәтеп, күңелләрендә мәхәббәт уятып аларны сафландыру иде. Шул сафлык, нечкәлек Илдарның үзенә хас иде, чиртсәң, катырак кагылсаң, кыйммәтле ваза кебек таралып китәр төсле иде ул. Йөрәге тулы моң иде аның, моңны поэзиясе аша түкми-чәчми кешеләргә өләшә иде. Гел моңнан гына торган бер изге зат иде Илдар Юзеев. Моң бит ул гел елау, кайгы-хәсрәт кенә түгел, андый моң туйдыра, тыңлыйсы килми башлый. Моң ул — адәм баласының күңелен сафландыра торган дөнья кебек чиксез бер хис.

Илдар белән бер вакытта бер бүлектә больницада ятарга туры килде. Кич саен аның белән әдәбият, сәнгать, тормыш турында сәгатьләр буена сөйләшеп утырабыз. Минем җәмәгатемне югалткан кайгылы көннәрем. Бер кичне Илдар шигырь күтәреп кергән. Минем хәләтемне, кичерешләремне шигырь белән әйтеп биргән:

...Ах, без анда да очрашсак иде...
Күккә карап күзләр арды бит.
Иркә назны һич кызганмас идем,
Әйтелмәгән сүзләр калды бит.

Тагын бер тапкыр Илдар белән больницада туры килдек 2003 елда. Сөйләшеп туялмыйбыз. Тагын бер шигырь язып кертте:

...Яшик охшап Әлдермештәй
Таза ирләргә,
Узып китик сәлам бирми
Газраилләргә!
Мәңге монда яшәмәбез,
Тик башны имик.
Яшик әле тегендә дә
Гел исән-имин...

Нинди оптимизм, заряд, яшәргә стимул биреп китте ул. Кешене моңландыра да, күңелен дә күтәрә белә иде шул Илдар.

*2006*

**АЙРАТ АРСЛАНОВ**

# Романтик рухлы иҗатчы

Союзыбыз заманында
Гөр килгән Союз ие.
Яшь язучы, яшь шагыйрь —
Барысы җиде йөз ие.
Анда һәркем үз ие,
Чөнки анда бар ие
Союзның үз Юзие!

*Р.Миңнуллин*

Шагыйрь язганны куәтләп, Союзның үз Юзие, кодрәтле таланты, баш хәрефтән әйтелә торган чын кешесе бар иде, дип әйтәсе килә.

Үткән гасырның алтмышынчы елларында без Илдарны Язучылар берлегенең әдәби консультанты, ә җитмешенче елларның ахырыннан Татарстан Язучылар берлегендә яшь авторлар белән эшләү буенча Берлек идарәсе рәисенең урынбасары вазифасын башкарганда яшь шагыйрьләр белән бик еш күрә торган идек. Җиде йөз яшь авторның ничә йөзен шигъриятнең тылсымлы дөньясына алып кергәндер, анысы безгә нәмәгълүм, әмма ләкин күп шагыйрьләрнең: «Безнең укытучыбыз, олы әдәбиятка җитәкләп алып кергән гаҗәеп лирика остасы, гүзәл җанлы олуг шәхес Илдар ага Юзеев булды», — дигәннәрен шактый ишетергә туры килде. Хәзер инде ул яшь шагыйрьләрнең күбесе үзләре күренекле шагыйрьләр, журналистлар, мәдәният эшлеклеләре һәм башка өлкәләрдә уңышлы эшләүче шәхесләр. Үзе исән чакта Илдар аларның иҗатларына, эшләренә сокланып карый торган иде, ә инде хәзер - укучылары зур хөрмәт белән искә алалар. Каян килгән соң шагыйрьгә яшь авторлар белән эшләүдә тәҗрибәлелек, яшьләргә игътибарлы караш, итагатьлелек?

Бу тәҗрибә үзенең укытучылары, шигъриятнең олуг затлары Хәсән Туфан, Сибгат Хәкимнәрдән килгәндер...

Илдар Сибгат аганы искә алып болай сөйли торган иде:

«Мин 1951 елда Казан дәүләт педагогия институтына укырга кердем, кайчандыр мәшһүр шагыйребез С.Хәким укып чыккан уку йортына. Шунда әдәбият казанында кайный башладым. Үзәгендә Х.Камалов, С.Сафуанов, М.Шабаев, Г.Мөхәммәтшин, Р.Әхмәтҗанов, Б.Камалов, Д.Зөбәеровалар торган әдәби түгәрәгебез ул елларда шаулап-гөрләп торды. Шул түгәрәкнең бер утырышына без күренекле шагыйребез Сибгат ага Хәкимне дә чакырдык, ул көнне без яраткан шагыйребезнең яшь иҗатчыларга һәрвакыт ярдәм итәргә әзер торган изге шәхес икәнен аңладык. Иң беренче шигырьләребезне «Совет әдәбияты» журналында чыгаручы да Сибгат ага булды.

Үзеннән соң әдәбиятка килгән яшьләргә ярдәм итү остазыбызның гомере буена дәвам иткән асыл сыйфаты иде. Ул безне, илленче елларда поэзиягә килгән яшьләрне, гомеренең соңгы көннәренә кадәр күздән югалтмады, әсәрләребез турындагы фикерләрен телдән дә, матбугатта да әйтә килде. Язучылар союзының яшь авторлар белән эшләү бүлегендә эшләгән елларда Х.Туфан һәм С.Хәкимнең зур ярдәменә таяндык. Матбугат битләрендә әдәби язмалары белән күренгән яшь иҗатчыларны барлап, аларның исемлеген төзедек. Сәләтле яшьләрне барлау максатыннан чыгып, районнарда зона конференцияләре үткәрдек. Барган урыннарда мәктәпләрдә укучыларның иҗатын да тикшерә идек. Бөтен Татарстанны йөреп чыктык. Анда табылган иң сәләтле авторларны югалтмыйча, алар белән даими эш алып бара идек».

Менә бит ул ничек эш тәҗрибәсе тупланган, берәмтекләп диярлек яшь, талантлы авторларны эзләп тапканнар һәм аларның иҗаттагы үсеш юлында зур булышлык күрсәткәннәр. Әлбәттә, Илдарның бу юнәлештәге уңышларына үзенең укытучылары булган олуг шагыйрьләрнең зур ярдәме аркылы ирешүе бик ачык күренә. Менә шулай туа да инде шагыйрьнең үзендә осталык һәм остазлык мәктәбе. Сибгат ага Хәким үзе дә Илдар иҗатын һәрдаим күзәтеп барып, аның поэзиясенә югары бәя бирде:

«Илдар Юзеевның иҗаты башыннан ахырына кадәр яшьлек турында. Аның чордашларыннан бу теманың стихиясенә кереп, үзенең тәмам романтикасына әйләндергән башка бер шагыйрь дә юк. Ул картайганчы яшьлектән айный алмый торган шагыйрь булып калачак. Һәр чорның үз яшьлеге, беркайчан да кабатланмаган үз мәхәббәте, һәр чорның үзенә хас проблемалары, янулары, көюләре. Кыскасы, үз Резидәләре, Миләүшәләре, янар чәчәкләре бар. Аларны шулар арасыннан күтәрелгән шагыйрь генә җырлый ала. Илдар Юзеев поэмаларын күтәренке рухлы, романтик рухлы дибез.

Лирик, драматик поэмалар, легендалар. Илдар Юзеевның таланты күбрәк шушы жанрларда ачылды. Илдар Юзеев — поэзиягә Мусалар буыныннан соң килгән шагыйрь. Әсәрләренең бөтен рухы, юнәлеше, оптимистик омтылышы белән ул шул сугышчан поэзиянең традицияләрен дәвам итгерә».

Бу — Илдар Юзеев иҗатына остазы тарафыннан бирелгән бик зур бәя иде. Илдар андый бәягә зур җаваплылык хисе белән карады һәм үзенең бөтен иҗат юлында остазлары тарафыннан күрсәтелгән олы ышанычны лаеклы үтәү өчен бөтен иҗат ялкынын биреп эшләде. Илдар дустыбызның татар әдәбиятын һәм мәдәниятен күтәрү өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре бихисап. Аның иҗаты күпләргә үрнәк иҗат. Илдар белән танышлыгым алтмышынчы еллар уртасында, ул «Пионер» (хәзерге «Ялкын») балалар журналында җаваплы секретарь, аннары «Чаян» журналында әдәби хезмәткәр булып эшләгән вакытта булгандыр дип уйлыйм. Аңа кадәр дә Тукай клубында да танышлар булып күрешеп, исәнләшеп йөри идек.

Җитмешенче елларда мин эстрадада, Татарстан радиосы һәм телевидениесендә Илдар Юзеев поэзиясен пропагандалауда актив катнаша башладым. Ул елларда филармония концертларында шагыйрьләребезнең күп әсәрләре башкарыла иде. Филармониянең әдәби музыкаль лекториенда шагыйрьләр иҗатына багышланган махсус концертлар оештырыла иде, мин әдәби концертлар белән республикабызның күп районнарында булдым ул чакларда. И.Юзеев әсәрләре буенча төзелгән «Шагыйрьләр нигә картаймый?» һәм «Моң турында баллада» дип исемләнгән программалар культура йортларында һәм мәктәпләрдә яратып кабул ителәләр иде. Радиода Илдар әсәрләреннән «Язылмаган поэма», «Әнкәй» поэмасы буенча радиокомпозиция, «Таш диварлар авазы» һәм «Мәхәббәт китабы» поэмалары буенча эшләнгән тапшырулар, ә соңрак елларда «Сандугач җаны» дигән радиокомпозиция авторның үзе тарафыннан да яратып кабул ителгән тапшырулар булды. Төрле тематик концерт программалары төзегәндә Илдарга еш кына мөрәҗәгать итә идем, ул бик теләп үзенең яңа әсәрләрен тәкъдим итә торган иде. Менә шушы иҗади дуслык күп еллар буена дәвам итте. Илдар минем иҗади эзләнүләремдә ярдәмгә килде, сораган гозерләремне җавапсыз калдырмады. Шагыйрьнең «Сәйдәш урамында уйлану» дигән әсәрен мин күп концертларда башкардым. С.Сәйдәшевкә һәйкәл куелу озакка сузылу безнең һәр икебездә дә канәгатьсезлек хисләре уята иде. Мин Илдардан әсәрендәге берничә строфаны безнең хисләрне чагылдырырлык итеп үзгәртеп язуны сорадым. Ул бик теләп риза булды. Бу көн кадагына суга торган әсәр күпләрнең күңеленә хуш килде, аны без күп концертларда, хәтта композиторның тууына 100 ел тулуга багышланган юбилей кичәсендә дә укыдык. И.Юзеев поэзиясенең төп сыйфатлары — тирән фикер, моң, нечкә лирика — сәхнәдә күп башкаручыларда аның әсәрләрен башкару теләген тудыра иде сыман. Шул ук вакытта шагыйрьнең әсәрләрен сәхнәгә чыгару үзенең тирән фикере һәм философик яңгырашы белән аның әсәрләрен башкаручылардан әдәби әзерлек тә, шагыйрьнең оптимистик рухын, романтик пафосын аңлауны да таләп итә иде, минем фикеремчә.

Шагыйрьнең тирән моңы, поэзиясенең форма төгәллеге композиторларыбызга да аның текстларына көйләр язарга илһам бирәләр иде. Аның берничә дистә шигъри әсәренә көйләр язылган. Эстрадада, радио һәм телевидениедә үзенең оста башкаручыларын тапкан җыр сәнгате дә Илдарга халык арасында зур популярлык китерде. Аның сүзләренә язылган «Яшь наратлар» (Җ.Фәйзи), «Кыр казлары артыннан» (М.Имашев), «Кайтам инде» (С.Садыйкова), «Мәтрүшкәләр» (А.Гыйләҗев), «Серле чәчәк» (М.Яруллин) һ.б. күп җырлар халык тарафыннан яратып каршы алындылар һәм бүгенге көнгә кадәр популяр җырлар исемлегендә яши бирәләр. Әйтәсе килгән фикерем, И.Юзеев әсәрләре заманында Татар дәүләт филармониясе артистлары, опера җырчылары, сүз сәнгате осталары репертуарларында үзләренең лаеклы урыннарын таба килделәр һәм башкаручыларның да яратып башкара торган сәхнә әсәрләре булып әверелделәр.

И.Юзеев танылган татар драматургларыннан берсе, дистәләгән драма, комедия һәм трагедия авторы иде. Поэзиясендәге кебек, драмаларында да автор кеше күңеленең рухи матурлыгын, аның якты омтылышларын романтик буяулар белән сурәтләргә омтылды. Шуңадыр тамашачылар Илдарның сәхнә әсәрләрен яратып карыйлар иде, ул алар күңелендә якты хисләр, өметләр уятып, тормышның төрле негатив, әшәке якларына нәфрәт уята иде. Без яшьрәк чакта Илдарның «Таныш моңнар» поэмасы буенча сәхнәгә куелган спектакльне яратып каравыбыз истә. Яшь автор шул елларда үзенең «Фәрит-Фәридә», «Өчәү чыктык юлга», «Миләүшә» һ.б. әсәрләре белән яшьләрнең яраткан шагыйренә әверелде. Соңрак елларда язылган сәхнә әсәрләреннән «Бөркетләр кыяга оялый», «Янар чәчәк», «Кыр казлары артыннан», «Бәхетемнән узып барышлый», «Онытылмас бәет», «Гомернең алты сәгате» һ.б. пьесалары да, профессиональ һәм халык театрларында куелып, авторга зур уңыш китерделәр.

И.Юзеевның иң күп куелган пьесасы — «Сандугачлар килгән безгә» исемле моңсу комедиясе. Ул пьеса — К.Тинчурин исемендәге Драма һәм комедия театрында берничә постановкада барган, театр репертуарында лаеклы урынын алган уңышлы спектакльләрнең берсе. Ул пьеса буенча спектакльләр узган гасырның җитмешенче-сиксәненче елларында илебезнең күп театрлары сәхнәләрендә уйнала, Казан, Уфа, Ленинград, Кемерово, Тува телевидениеләре аша күрсәтелә, төрле фестивальләрдә уңыш казанып, театр коллективларына һәм авторга I дәрәҗәле дипломнар, лауреат исемнәре китерә.

Илдар үзенең күп пьесаларын Тинчурин исемендәге театрның ул вакыттагы баш режиссеры Р.Тумашевка китерә иде, аларның иҗат дуслыгы күп еллар буена дәвам итте һәм тамашачылар яратып карый торган спектакльләр туды, ул спектакльләр театр тарихында лаеклы урыннарын алдылар. Әмма Г.Камал исемендәге Академия театры Илдар Юзеев пьесаларына битарафлык күрсәтә иде кебек. Бу

театрда авторның ике пьесасы буенча спектакльләр куелды. Берчакны Камал театрында (кайсы ел икәнен төгәл генә хәтерләмим) М.Гафури исемендәге Башкорт драма театрының И.Юзеев әсәре буенча куелган «Бәхетемнән узып барышлый» спектаклен Илдар белән бергә караган идек. Матур куелган спектакль иде, актерлар да яхшы уйнадылар, без бик канәгать калдык. Антракт вакытында Илдардан сорыйм: «Башкорт академия театры татар драматурглары әсәрләрен бик теләп куя, ә нигә безнең Академия театры синең әсәрләрне сәхнәләштерми?» Хәтеремдә, Илдар болай дип җавап биргән иде: «Сиңа җавапны үз вакытында Н.Фәттахның матбугатта чыккан сүзләре белән бирмәкче булам. Ул болай дип язган иде: «Татар академия театры хәзерге көндә — бер режиссер, бер драматург һәм бер тәнкыйтьче театры ул».

Минем газеталарда яза башлавыма да Илдар сәбәпче булды. Ул «Сабантуй» газетасында эшләгән чагында миңа «Хәтерлим бер гүзәл мизгелне» дигән циклда үземнең сәнгатьтәшләрем турында мәкаләләр язарга тәкъдим итте. «Сабантуй»га беренче язган мәкаләм дустыбыз композитор Р.Яхинга багышланган иде. Шул көннән башлап төрле газета-журналларда ике йөздән артык язмаларым басылды.

Илдар белән без бер-беребезгә еш кына «якташ» дип эндәшә торган идек. Чөнки төньяк Башкортстанның Яңавыл, Балтач районнарында аның, минем балалык елларыбыз үткән, аралар ерак түгел. Мин Илдарга: «Мин бит синең туган авылың Ямады аша Казанда укыган чакта еш үтә торган идем, ул елларда Яңавыл станциясенә барганда күп авыллар аша үтәргә туры килә иде, ә соңрак яңа юл салынгач, авылларны читләтеп үтә башладык. Әгәр шул елларда Ямадыда татар әдәбиятының күренекле вәкилләре булачак Нил һәм Илдар Юзеевларның яшәгәнлекләрен белсәм, мин сезне эзләп табып, танышкан булыр идем», — дия торган идем, ә Илдар: «Ул елларда танышу тагы да кызыграк булган булыр иде», — дип елмая иде.

Минем өчен дә мондый якташым булу үзе бер бәхет, сөенеч бит ул!

**РЕНАТ ХАРИС**

# Илдар Юзеев

Исеңдәдер, Илдар абый, әллә ничек
очраштык та ЦДЛда*, төтен эчеп
утырганда, безнең шактый мул табынга
(ә татарга Мәскәүдә кунак табыла!)
Виктор Иваныч Кочетков** үзе килде.
Язучылар парткомында ул баш иде.

Куе төтенгә кушылгач бераз сыек
кайнарлык та, киттек, ахры, шактый кыеп —
бу тарихи бина буйлап сәяхәткә
чыгып кердек... Йөри-йөри күрдек хәтта
иң зур түрә язучылар бүлмәләрен.
Гид Кочетков сөйләп йөрде белгәннәрен.

Төгәлләдек сәяхәтне парткомда без.
Күн диванда рәхәтләнеп утырабыз.
Партсерләр сейфын ачты Виктор Иваныч,
алды аннан «Арарат» дигән юаныч,
салып чыкты Кубачи*** көмешләренә...
Менә-менә көмешләр тешкә бәрелә

дип торганда, хуҗаң әйтеп салмасынмы:
— Кайсыгызның нормаль түгел кан басымы?
Нормаль булса, минутларны итмик әрәм,
чираттагы эксперимент үткәрәм:
сез утырган шушы диван хәтәр тулы —
Александр Фадеев үлгән атылып...

Корт чаккандай, Илдар абый, син диваннан
сикереп тордың... Күз нурларың чеп-чи канга
манчылган кебек иделәр... Кубачиның
рюмкасын паркетка бәрдең һәм, ачынып,
әйттең йомшак тавыш белән каты итеп:
— Кан белән үртәү татарны хватит, җитте —

кипкәне дә, тамганы да, катканы да
гаеп ташлау тамырларда акканына...
...Агарынды, кабаланды хуҗа шулчак —
синең сүзләр, Илдар абый, булып пычак,
кадалды экспериментчы күзенә...
Аның хәлен аңлата алмас сүз генә,

төгәл итеп күрсәтә алмас кино да —
рус йөрәге татар җанында кыйнала,
сүз табалмый... Икесе дә сызланалар,
әйтерсең лә бүген солых бозган алар...
Һәм син әйттең: — Әйдә ресторанга күчик,
берәр бокал иң кыйммәтле дуслык эчик...

*14–15 май, 2004*

**НӘҖИБӘ ИХСАНОВА**

# Сагынам

Илдар... Илдар Юзеев... Шәүкәт Галиев... Альберт Яхин... Саный китсәң, алар шактыйга җыела. Бу исемнәр, минем тормышым Туфан белән бәйләнгәч, ничектер сиздерми генә эшебезгә, иҗатыбызга яхшы мәгънәдә йогынты ясадылар. Ә хәзер инде җае чыккан саен мактанып та алам. Мактану да түгел, ә чыны шулай. Ике бер-берсенә ят кешенең тормыш корып җибәрүе җиңелләрдән түгел. Аларны яшәтер өчен читтән ниндидер сихри көчләр кирәк, нәрсәгәдер тотынып яши башларга кирәк. Туфанның бүтәннәр белән иҗади аралаша, таный белүе безгә ярдәмгә килгәндер. Биш ел буе Мәскәүдә уку дәвамында ул Казан белән иҗади аралашып яшәде. Инде кайтып эшли башлагач рәхәтләнеп очрашалар, көннең-төннең кайсы вакыты булуга карамастан, безнең фатирыбызга килеп тулалар. Мин, билгеле, аларны зарыгып көтеп алмыйм, алай да тора-бара ияләшә башладым. Кызыклы кешеләр, иҗат кешеләре, рухи бай кешеләр. Сөйли китсәң, һәрберсе турында озаклап сөйләргә булыр иде. Күпме шигырь тыңланды, күпме җырлар җырланды! Әйтерсең лә мин янәдән бер мәктәп уздым. Иң хәтердә калганы, җанга җылы биргәне Илдар, Илдар Юзеев! Шаян шаяртулары, шигъри тәлгәшләреннән соң кулына гармун алулары... Очрашуның иң югары ноктасы җырга, моңга барып тоташа. Илдар танымаслык булып үзгәрә, бөтенләй икенче кешегә әйләнә, ул инде беркемне дә күрми кебек. Гармун ничек түзә икән диеп уйлый идем. Гармун күрекләре икегә аерылып тетелеп бетәргә мөмкин! Һәм мин үзем дә сизмәстән Илдар янына ыргылам. Ул, мине генә көтеп торган кебек, минем җаным ташкынына кушыла, җырлый башлыйм. Һәр очрашуның кабатланмас үз төсмере! Илдар үзенең җан торышына беркайчан да хыянәт итмәде. Гел үзе булып калды. Менә хәзер ул юк... Ә күңелнең аны юксынганы сизелә. Инде соңгы вакытларда артык еш та очрашмадык, һәрберебез үз оясында кайнашты. Телефоннан шылтыратуын шатлык белән көтеп ала идек. Сүзләребез һәрвакыт иҗат югарылыгында булды: тормыш турында булсынмы, сәнгать турында, шигърият турындамы — бар да чын күңелдән, чиста җан белән! Илдар юклыгы сизелә, Илдар җитми! Кәгазьләрем, рольләрем арасыннан Илдарның шигъри юллары килеп чыкты: башта Туфанның миңа калдырган язуы, аның сүзләрен раслап Туфан үзе, Альберт Яхин, Илдар Юзеев кул куйганнар, число, аен, елын язганнар. *«Нәҗибә! Эчтек тә без исердек тә. Сине хөрмәт иткән дусларың: М.Туфан, И.Юзеев, А.Яхин. 12.03.82».*

Болар Илдарның шигырьгә салынган сүзләре:

Ышанма син, Туфан алдый ул.
Әйтә: «Нәҗибә аңлый ул».
Дөрес, эчтек тә без исердек.
Әмма сине искә төшердек.
Шул вакытта гына айнып̆дык!..
Без китәбез хәзер аңлы, нык.
«Утыргансыз бездә аз», — димә,
Сау бул, ачуланма, Нәҗибә!..

Ә бу юлларны Илдар телефон аша тапшырды:

28 апрель. 1992 ел.
Т.Мин. юк чагында
Очень люблю, Нәҗибә!..
Халык артисткасы булдың —
Поздравляю тебя!

Илдарның миңа атап язган язуларын иң кирәкле кәгазьләрем белән бергә, сүзләрен күңелемдә саклыйм. Үзен сагынам.

**САИМӘ ИБРАҺИМОВА**

# Үзебезнең Юзәй

Әле Займищеда яши генә башлаган чак. Шундый бер момент искә төште. Җәйләрен без эшкә Займищедан йөри идек. Шулай беркөнне эштән кайтып киләм. Марс Шабаев белән бергә туры килдек. Марс анда яшәде микән, берәрсенә килүе иде микән, хәтерләмим. Безнең турыга җитсәк (Юзиләр белән өйләребез кара-каршы гына. Автографларына ул үзе «Юзәй» дип куя иде), Илдар баскыч төпләрендә гармун уйнап утыра. Аны бит «уйнап» дигән сүз белән генә әйтү бернәрсә дә әйтмәү дигән кебек ул. Аның кулындагы гармун әллә җырлый, әллә җылый, әллә йөрәген сызлата... Аның гармуны да бит шигырьләреннән ким тетрәндерми иде күңелне. Менә шунда без Марс белән аның каршысына килеп бастык та, сүз куешкандай, гармунына кушылып җырлап җибәрдек. Икенче көйгә күчсә, без аңа иярәбез, өченчесенә күчсә, без тагын иярәбез һәм тагын, тагын...

Ул чакта без барыбыз да хәзергегә караганда чәк-чәк кенә булса да яшьрәк булганбыз шул. Их, күңелле дә булган иде соң әлеге экспромт концерт! Марс хәтерли микән, бер дә бу турыда сөйләшкән юк.

* * *

Минем «Мәдәни җомга» гәзитендә эшләгән чак. Әле беренче саннарын гына чыгардык. Илдарга күптән түгел генә Халык шагыйре дигән мактаулы исем бирелгән иде. Гәзит битен тутырып шигырьләрен бирмәкче булабыз, горурланабыз инде!

Шунда минем колагыма гына әйткәндәй итеп әйтте Илдар:

— И, Саимә, берүк халык шагыйре дип куя күрмәгез, оялам мин, уңайсызланам... — диде.

Аның тыйнаклыгын әйтеп, сөйләп кенә бетерә торган түгел инде.

Илдарның күп шигырьләре автобиографик дип уйлыйм мин, һәрхәлдә, миңа шулай кебек тоела. Менә аның «Бөркет турында җыр» дигәне:

Яшь аралаш
Елмая ул:
Югарыда — баласы.
Ә баласы —
Күз карасы —
Сизмәде дә яшенне.
Ике канат,
Канап-канап,
Зур давылдан яшерде.

Илдар белән аның «Кыр казлары артыннан» дигән җыры турында сөйләшеп утырган булды. «Ул җыр шул телебез турында бит инде, ә шуны берәү дә аңламады, берәү дә аның турында фикер әйтә алмады. Чыны кыр казлары турында түгел бит аның...» — дигән иде Илдар, ачынып.

...Кыр казлары артыннан
Очарга дип талпынам.
Тик очалмыйм, карап калам
Кыр казлары артыннан...

«Серле чәчәк» дигән шигыренең ничек язылуы турында да сөйләгәне булды Илдарның.

Мин шуңа игътибар итәм: «Илдар шигырьләренә язылган көйләр-моңнар гел шигыре белән бергә бер күңелдә тугандыр кебек тоела миңа. Ул әлеге «Бөркет турында җыр»ын әйтәсеңме (аны радиодан «Бөркет турында баллада» дип игълан иткәннәрен ишеткәнем булды, баллада дип әйтү килешәрәк бит), «Туган як каеннары»нмы, «Мәтрүшкәләр»енме һәм башка бик күп җырларынмы. Күңелдәш композитор туры килә торган булгандыр дип уйлыйм. Бу турыда Илдарның үзенә дә әйткәнем булды.

**ИСЛАМИЯ МӘХМҮТОВА**

# «Җырың китмәс инде күңелдән»

«Һаваларда очкан кыр казына
Серле җырың белән ни әйттең?
Хыялыңда күккә күтәрелдең,
Киек кошларны да иярттең.

Хыялыңда түгел, чынбарлыкта
Күтәрелдең сәхнә түренә,
Үз артыңнан әйдәп кыр казларын
Алып кайттың туган күленә.

Иҗатыңда бик табигый булып
Хыял белән чынлык үрелгән.
Еллар үтәр, кошлар кайтыр-китәр,
Җырың китмәс инде күңелдән.

*«Кыр казлары артыннан» спектакленең аерым җыр булып яшәве дә артистлар тудырган драматик язмышлардан аерылгысыз. Чөнки җырга Ясминәнең заяга үткән гомере, тормышка ашмаган хыяллары, бәхетсез мәхәббәте кушыла. Сәхнәдә уйналган бу әсәрнең шулай озын гомерле булуы, һичшиксез, Исламия Мәхмүтованың талантлы башкаруына бәйләнгән дип уйлыйм. Исламиянең Ясминәсенә мин шулкадәр ияләштем, хәзер аны башка артистка уйнавында күз алдыма да китерә алмыйм кебек.*
*И.Юзеев, 20.11.1993».*

Илдар абый Юзеев бу шигырьле сүзләрне минем 50 яшьлек юбилеема бүләк иткән иде. Илаһи зат, халкыбызның күренекле шагыйре, драматургы минем иҗатыма шундый зур бәя бирде. Рәхмәт аңа, урыны оҗмахта булсын.

Дөрестән дә шулай. Нинди генә рольләр уйнамадым, нинди генә җырлар җырламадым, барыбер халкыбызның күңелендә мин Ясминә булып калдым. Кая гына барсак та, кайда гына уйнасак та, тамашачылар белән очрашуларда да, концертларда да кат-кат шул Ясминә җырын сорыйлар. Телевидениедән тамашачылар хатлар язып атна саен шул җырны яңгыратуларын үтенәләр. Радиодан да бик еш тапшыралар бу җырны. Менә 30 ел инде бу җыр минем репертуарымда яңгырый. Мин моңа горурланам. Монда Илдар абый белән бергә композитор Мәсгут абый Имашевның да йөрәк җылысы, мәңге онытылмас моңы кушылган. Алар мине бу җыр, моң белән кошлар биеклегенә күтәрделәр. Рәхмәт аларга! Бу җырны белмәгән бер генә татар кешесе дә юктыр, чөнки бу җыр халыкның үз җыры, үз моңы булып калды. Илдар абый К.Тинчурин театры белән иҗади дуслыкта иде. Без аның язган әсәрләрен зарыгып көтеп ала идек, аның әсәрләрендә — бер-берсен кабатламый торган саф күңелле яшьләр, мәхәббәт, гафу итә алмаслык язмышлар. Театрда аның 10 пьесасы куелган. «Резидәкәй» 1958 елда куелып бик күп еллар уңыш белән барды. 1991 елны аны кабат шәхсән мин үзем театрыбызның яшьләре белән сәхнәгә куйдым. Яшьләр, шул спектакльдә уйнап, тамашачыларның яраткан артистлары булып киттеләр. Илдар абыйның бездә куелган пьесалары барысы да алтын баганалар кебек. Алар режиссерыбыз Равил абый Тумашев белән иҗади дуслыкта, бер-берсен аңлап эшләделәр. Уй-фикерләренең тәңгәл килүе дә безнең театрга килергә, безнең белән аралашырга җиңеллек биргәндер.

К.Тинчурин исемендәге театр И.Юзеевның түбәндәге пьесаларын куйды:
«Резидәкәй» — 1958, 1991;
«Бөркетләр кыяга оялый» — 1970;
«Сандугачлар килгән безгә» — 1974, 2004;
«Кыр казлары артыннан» — 1976;
«Кайтмый калсам, көтәрсеңме?» — 1978;
«Бәхетемнән узып барышлый» — 1979;
«Онытылмас бәет» — 1981;
«Мәкәрҗәгә барган идек» — 1988;
«Безнең эти мировой» — 1991;
«Гашыйклар тавы» — 1992.

«Онытылмас бәет» пьесасын Илдар абый Хәлил белән миңа багышлап язып китерде. Тамашачыларыбыз И.Юзеев әсәрләрен онытмый, кабат шул пьесаларны куегыз әле, сагынабыз, диләр. Артистларыбыз да бу спектакльләрдә уйнап тамашачыларыбызның яраткан артистлары булдылар, зур дәрәҗәле исемнәр алдылар, иҗат биеклегенә күтәрелделәр. Әле Илдар абыйның пьесаларын кабат-кабат кайтып куярлар, бу пьесалар мәхәббәт белән үрелгән, онытыла торган түгел, алар мәңгелек!

**ХӘЛИЛ МӘХМҮТОВ**

# «Тик оча алмыйм...»

Шагыйрь, драматург Илдар Юзеев турында мин сәнгать өлкәсенә килгәнче үк белә идем. Театр училищесында укыганда Камал театрында беренче мәртәбә «Янар чәчәк» спектаклен карагач, озак вакытлар шул әсәрдәге җырны эчтән шыңшып йөрдем. Пьесаны — Илдар Юзеев, музыкасын минем якташ, бергә укыган Мирсәет Яруллин язган иде. Спектакль моннан 44 ел элек сәхнәгә чыгуга карамастан, җырның сүзләре әле дә хәтердә.

Ни өчен җырдан башладым?

Күчмә театрда эшләгәндә, Илдар абый безнең театрга «Кыр казлары артыннан» дигән әсәрен алып килде. Укыр алдыннан: «Мин моны Камал театрына да тәкъдим иткән идем. Алмадылар. Уйнарлык нәрсә юк дип кире кактылар», — диде.

Илдар абый әсәрне, артистлар шикелле янып, үзе уйнап күрсәтте. Соңыннан без, шаярып, Илдар абый шикелле сөйләп тә йөрдек әле. Без дә: «Нәрсәсе бар инде моның, «бытовой» әсәр!» — дип теләмичә генә эшкә керештек. Ләкин режиссерыбыз Равил Тумашев, һәр көнне репетиция башланыр алдыннан безгә «лекция» укып, Илдар абыйның романтик шагыйрь булуын, аның һәрбер сүзендә мәгънә ятуын аңлата барды. Равил абыйның көн саен бер сүзне кабатлап репетиция башлавына эч поша башлады, беркөнне конфликтка кадәр килеп җиттек. Еллар узгач, шул вакыттагы тотнаксызлыгыма үкенеп йөрим, гафу үтенгән булсам да. Яшьлек! Спектакльне чыгардык. Сәхнәдән яңгыраган һәр сүзнең тамашачы йөрәгенә үтеп керүен, спектакль беткәч тә залның тып-тын калып сәхнәдә булган хәлләрдән айный алмый утыруын күргәч кенә, без авторның нинди зур сүз остасы, нинди олы шәхес булуын аңладык. Уйнаучылары да көчле сәхнә осталары иде шул. Фердинанд Фарсин, Люция Фарсина, Ринат Мифтахов, Исламия Мәхмүтова, Юныс Сафиуллин, Нәзир Сафин, Наил Шәйхетдинов, Мария Чиякова һәм бу юлларның авторы Хәлил Мәхмүтов бер җан булып, оешып уйнадык. Спектакльдә көчле ансамбль бар иде. Соңгы елларда тормышта төрле үзгәрешләр булу сәбәпле, Гата абый Нуруллин, Кәримә апа Нуруллина, Роза Хәбибрахманова, Фәһим Ситдыйков һ.б. уйнадылар. Спектакльгә хилафлык килмәде.

Әсәрдә төп герой — Маликның хатыны — йомшак, мөлаем, иренә каршы дәшә алмаган Ясминә. Автор бу образга сүзне аз язган. Ләкин Ясминәнең бөтен күңел халәтен, эчке кичерешләрен ачып бирә торган җыр тексты өстәгән. Өч куплет җыр! Менә кайда ул драматургның осталыгы! Исламия җырны шулкадәрле йөрәккә үтеп керерлек итеп җырлый. Халык — тамашачы — башта (җыр тәэсиреннән айный алмыйча) тып-тын утырганнан соң, аңга килеп тыела алмыйча кул чабарга тотына. Ике спектакль. «Янар чәчәк» һәм «Кыр казлары артыннан». Икесендә дә җыр — спектакльнең йөзе, образларның характерын ачу ысулы. Менә кайда икән хикмәт. Мәсгут абыйның язган көе дә спектакльгә тәңгәл килде. Авторның — драматург Илдар абый Юзеевның, режиссер Равил абый Тумашевның, композитор Мәсгут абый Имашевның һәм театр артистларының зур, бик зур уңышы «Кыр казлары артыннан» спектакле. Илдар абыйның юбилеенда Исламия: «Илдар абый! Синең «Кыр казлары артыннан» әсәрен уйнап, без бөтен Россиядә яшәүче татар халкына танылдык! 18 ел буе уйнап, Татарстанның кайсы авылында гына булмадык та, Россиянең кайсы шәһәрендә генә булмадык. Рәхмәт сиңа! Синең җырың белән без күтәрелдек, халыкка танылдык!» — диде.

Соңгы тапкыр без Илдар абый белән Васильевода ял иткәндә очраштык. Хатыннарыбыз белән көн саен кич чәй янында сөйләшеп, кызык вакыйгаларны искә алып көлешеп утырдык. Илдар абыйның сабыр табигатьле, итагатьле кеше икәнен белә идем. Бу талант иясе белән якыннан аралашкач, аңа хөрмәтем тагын да артты. Ул ни өчендер моңсу иде. Сәбәбен сорарга уңайсызландым. Санаулы көннәр тиз узды. Без киттек, алар тагын берничә көнгә калдылар. Ләкин безнең соңгы очрашу булган... Кызганыч, Илдар абыйның җеназасында була алмадым. Ә ул минем хәтердә һаман исән.

— Исәнме, Малик-балык! — дип елмаеп кулын сузар кебек.

*28 октябрь, 2006*

**ӘХМӘТ ГАДЕЛ**

# Ачы яшь түгеп

Йөрәгемә ачы хәбәр сукты,
Синсез инде таңнар атармы?!
Ни эшләдең, Әҗәл? Бу адымың
Кануннарга сыяр-ятармы?!

Ник ташладың, Илдар, халкыңны син,
Юлда батыр юлын атармы?!
Син каһарман — татар шагыйре син,
Җырчысы син, җырчы татары!

Кулыңда бит татар сазы иде,
Тальян иде талмас кулыңда,
Тальяннарны сузып йөргәннәрне
Онытттыңмы әллә болында?!

Кемгә кала моңлы сазың синең,
Кемгә кала сынмас кураең?!
Сагынмас дип ташлап киттеңме әллә
Татарларың шагыйрь малаен?!

Ә тугайлар?! Дала моңы нишләр?!
Ник оныттың тургайлар зарын?!
Тартып алдың, алып очып киттең
Тургайларын, моңлы татарын!

Аһ син, Юзи* морза!
Олуг токым —
Бөек Болгар — Урал баласы.
Яшисе дә яшисе иде бит,
Барасы да иде, барасы...

Син Такташны уяткан батыр бит,
Син җырлаткан батыр Бабичны.
Син бит болгар-урыс шагыйренең,
Есенинның браты давнишний!

Нигә киттең, син бит кирәк илгә,
Син бит кирәк бүген милләткә:
Бердәмлекнең зур җырчысы кирәк
Хыялдагы бөек дәүләткә!

Һәй, Илдарым, күз яшьләрем — чишмә,
Тозлы чишмә җанны гүләтте.
Әллә инде бу халыкка артык
Диме сине Аллаһ кодрәте?!

**ФӘНИС ЯРУЛЛИН**

# Онытабыз

Киткәннәрне бик тиз онытабыз,
Онытмаска юкса кирәк тә.
Әмма урын бигрәк тар шул безнең
Мескенләнеп беткән йөрәктә.

Бу шигырь Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев вафатыннан соң күпмедер вакыт үткәч язылган иде. Шигырьне тулаем китереп тормыйм, чөнки ул бер Илдар Юзеевны гына күз алдында тотмый. Гомумән, бездә соңгы елларда оныту һәм яхшыны күрмәү чире көчәеп китте. Без яза башлаган алтмышынчы еллар бик бәхетле еллар булган. Язучылар бер-берләре белән аралашалар, хатлар язышалар, укыган әсәрләре хакында фикерләшәләр, яңа әсәрләрен матбугатка биргәнче үк бер-берләренә укыйлар иде.

Бүгенге сүзем Илдар Юзеев турында. Әдәбиятка ул илленче елларда «Таныш моңнар»ы белән шаулап килеп керде. Шагыйрьләр гадәттә башта үзләренең шигырьләре белән таныла, аннан соң, бераз каләм чарлагач кына, поэма жанрын капшап карый башлыйлар иде. Әйе, Илдар Юзеев үзенең «Таныш моңнар»ы белән шигърият сөючеләрнең мәхәббәтен казанды. Чөнки поэма шул чорның кайнар сулышын, яшьләр күңелендәге кайнаган хисләр давылын чагылдыра иде.

Кайчан да булса Илдар Юзеев белән аралашып, язган әсәрләребезне бер-беребезгә укышып яшәрбез дип уйламый идем.

Алтмышынчы еллар башында шигырьләрем республика матбугатында дөнья күрә башлагач, миңа Гөлшат Зәйнашева, Мәхмүт Хөсәен, Әдип Маликов кебек ул чорда инде танылып өлгергән шагыйрьләр хатлар язды. Ул хатларда шигырьләремне хуплау белән бергә киңәшләр дә була торган иде. Хат хат инде, көннәрдән бер көнне Марс Шабаев миңа: «Илдар Юзеев синең яныңа килергә җыена. Ул бик таләпчән шагыйрь. Юк-бар шигырьләреңне күрсәтмә», — дип кисәтеп язды. Мин әле ул чагында туган авылым Кызылъярда, инде хастаханә этапларын үтеп, бар булган көчне иҗатка багышлап, баш-аягым белән шигърияткә чумган идем.

Марс Шабаевның хатыннан соң Илдар Юзеевны көтеп яши башладым. Ләкин ул үзе килә алмады. Тиз арада популярлык казанган шагыйрьне күрергә өметләнеп торганда, үзе урынына аның хаты килеп төште. Минем кәеф төште, әлбәттә. Ләкин хатын укыгач, үпкәләр онытылды.

*«Фәнис!*

*Сиңа ялкынлы сәлам булсын!*

*Күптән күрешәсе килә инде синең белән. Шигырьләреңне укып барам һәм шигырьдән шигырьгә үсүеңне күреп шатланам. Шулай дәвам ит! Поэтик фикерли беләсең, ә ул кешегә бик авыр бирелә, поэтик фикерләү — шагыйрьнең үз авазы, үз стилен табуда ярдәм итә торган беренче шарт. Аннан соң, син шигыреңә тиешле урында соңгы нокта куя беләсең. «Кыскалыкта — осталык» диләр бит. Ләкин хат аша гына конкрет сөйләшеп булмый инде.*

*Сиңа барам-барам дип йөргәндә генә Беренче Май районына командировкага җибәрделәр. Кайтып, тагын чыгарга гына җыенып тора идем — обком партиягә чакырып алдылар да тагын командировкага җибәрәләр. Иртәгә Шәүкәт Галиев белән Октябрьск-Норлат зонасына чыгып китә-без. Аннан соң отпускыга китәм. Шулай итеп, Фәнис, май-июнь аенда гына без синең белән очраша алмабыз. Гафу итәрсең инде. Ничек тә барып чыгармын.*

*Хәзер сине Язучылар союзында да, Матбугат йортында да сәләтле яшь шагыйрь итеп беләләр. Аңа карап, ашыгып яза башлама тагын. Үзеңә таләпчән булуыңа мин ышанам.*

*Тазалыгың ничек? Яхшыру сизеләме?*

*«Ялкын»га да балалар өчен язган шигырьләреңне җибәр әле, яме!*

*Марстан сәлам. Хәзер без аның белән бер бүлмәдә утырабыз.*

*Үзем быел көз Мәскәүгә укырга барырга уйлап торам (Высшие литературные курсы).*

*Ярый, Фәнис, сиңа чын күңелдән тазалык һәм иҗат шатлыгы телим.*

*Әниеңә, туганнарыңа күп сәлам.*

*Очрашуны көтеп, Илдар Юзеев. 7 май, 1962 ел».*

Мине Казанга июнь ахырында китергәннәр иде. Очрашу «Иске клиника» дип йөртелгән Республика хастаханәсендә булды. Бик яшь чырайлы, куе кара чәчле, шактый буйчан шагыйрь минем караватым янына килеп хәрәкәтсез кулларымны кысты. Без нәрсәләр сөйләшкәнбездер, хәтердә калмаган. Билгеле, сүзебез шигърият турында булгандыр. Шунысы хәтердә: ул үзен зурга куймыйча, мине үз тиңе күреп сөйләште. Бу очрашу 1962 елның 5 сентябрендә булган, чөнки ул автографында: *«Фәнис! Сиңа иҗат уңышлары телим. И.Юзеев. 5 сентябрь, 1962»*, — дип язган иде. Ул миңа беренче

килүендә «Янар чәчәк» дигән китабын бүләк итте. Хәзер аның миндә автографлы ун китабы саклана. Ә мин фатир алып яши башлагач, безнең фатирларыбыз бер урамда булып чыкты, һәм Илдар абый вакытын-җаен табып еш кына безгә кереп йөри башлады. Ул инде «Янар чәчәк»ләре, «Соңгы сынау»лары белән әдәбият диңгезендә киң колач салып йөзүче шагыйрь иде. Шуңа карамастан мине дә үз тиңе итеп саный, масаймый. «Яшьлек дустыма» дигән китабына ул: *«Фәнис! Халык онытмаслык бер генә шигырь язасы иде. И.Юзеев. 9.07.67»*, — дип кул куюы аның тыйнаклыгын күрсәтмимени?

Бу юлларны укыгач гаҗәпләнеп калдым. Ничек инде бер шигырь турында сөйләргә мөмкин. Хәзер үк бит инде аның шигырьләрен яшьләр яттан сөйли. Шакир Мәҗитов «Таныш моңнар»ын сәхнәләштереп, үзе үк көйләрен язгач, андагы җырларны икенче көнне үк җырчылар күтәреп алды.

Илдар Юзеев тыйнак шагыйрь булу өстенә кеше сүзенә колак сала белә. Бервакыт ул үзенең яңа гына «табадан төшкән» поэмасын — «Соңгы сынау»ны алып керде.

— Менә сезгә яңа поэмамны укымакчы идем, тыңларга теләгегез булса, — диде ул.

— Бик рәхәтләнеп тыңлыйбыз, — дидек без өчәүләп.

Ул вакытта әле әни дә безнең белән тора һәм әдәби әсәрләр тыңларга бик ярата иде. Шигырь китапларын вакыты булган саен укый. Илдар абый, бераз тамак кыргалап алганнан соң, поэмасын укый башлады. Поэмада Муса Җәлилнең тоткынлыктагы чоры сурәтләнә, анда Мефистофель образы да килеп кергән. Язылышы буенча да поэма яңа: пьеса кебегрәк, ягъни гадәти эпик яки лирик поэма гына түгел, ә Шекспир драмаларындагы кебек төп фикер, төп вакыйга персонажлар сөйләме аша ачыла.

Поэма безгә бик көчле тәэсир итте. Без барыбыз да Илдар абыйны яңа уңышы белән котладык. Ә инде поэма китап булып чыккач, Илдар абый китабын безгә бүләк итеп кертте.

*«Фәнис, Нурсөя һәм апа! Бу поэманы иң беренче сезгә укыдым. Фатиха сездән. И.Юзеев. 22.12.69».*

Соңрак И.Юзеевның бу пьесасы Минзәлә дәүләт драма театрында сәхнәләштерелде. Телевизордан да күрсәтелде. Илдар Юзеев белән без кырык ел буе аралашып яшәдек. Башка язучыларның әсәрләрен укысак та, бер-беребезгә шылтыратышып: «Фәлән кешенең фәлән әсәрен укыдыңмы әле? Уңышлы әсәр язган» яки: «Бу әсәре йомшаграк, — дип, «Казан утлары»нда чыккан яңа әсәрләргә карата бәя бирә идек. Ул күп укый, үзе дә ныклы рухлы, шуңа күрәдер күңел төшенкелегенә бирелеп ятучыларны яратмый иде.

«Төнбоек» китабына язып биргән сүзләрдә дә аның шул сыйфатын күрергә була.

*«Фәнис дус! Синең рухыңа, көчеңә, хисеңә, талантыңа нык ышанам. И.Юзеев. 11.05.71».*

Ә менә 1973 елда чыккан «Карурман» китабына: *«Фәнис дус! Карурманны чыкканда борылып карарга онытма. Нурсөя, Фәнис борылып караганда һәрвакыт сине тапсын. И.Юзеев. 23.02.74»*, — дип, безнең бер-беребезне югалтмыйча яшәвебезне теләгән. Карурман — безнең халыкта катлаулы, серле һәм шул ук вакытта тормышның үзен сурәтләүче образ.

Илдар абыйның сөйләвенә караганда пьесалар язарга аңа да Туфан Миңнуллин киңәш биргән. К.Тинчурин театрында Равил абый Тумашев баш режиссер чакта Илдар Юзеев драматург буларак ачылып китте. Һәр ел саен диярлек яңа премьера. Драматургка үзен ачар өчен үз режиссеры, аны аңлаучы, иҗатына хөрмәт белән караучы режиссер кирәк шул. Илдар абыйның бәхетенә, аның спектакльләренә уңышлы көйләр яздылар. «Кыр казлары артыннан» пьесасындагы җырны башкарып Исламия Мәхмүтова күпме тамашачының күңелен тетрәтте?! «Бөркетләр кыяга оялый» спектаклендәге «Бөркет җыры»н Зиннур Нурмөхәммәтов үз репертуарыннан төшермәде.

Илдар абыйга укып карарга дип мин дә бер пьесамны җибәргәнмен икән. Хатлар арасыннан Илдар Юзеевның пьесага карата фикерен әйтеп язган хаты килеп чыкты.

*«Фәнис! Сәлам!*

*Пьесаңны укып чыктым. Алга таба атлагансың. Вакыйгаларның күбесе ышандыра. Сюжет шактый төзекләнгән. Әмма, минемчә, карыйсы урыннар бар. Аерым сценаларны көчәйтергә кирәктер. Беренче актта бигрәк тә комичность, кызыклылык (арзан көлке турында әйтмим) җитми. Салихның килеп керү, балаларына сорау бирүләрен яңадан карап чыгарга иде. Патша кызы турындагы диалоглар үзен һич акламый, ышандырмый да, кызык та түгел. Гомумән, диалог синдә дә, миндәге кебек, беренче актта йомшаграк. Икенче акты кызыграк, әйбәт язылган. Иң уңышлысы — үзен талату өлеше. Бәхтинең бурасын урлатуы да, минемчә, хәзер ярыйсы. Ринитның кызга юри генә өйләнү, загска бару күренеше әлегә барып чыкмаган. Ул кызга «миңа юри генә кияүгә чыксаң, фәлән-фәлән бирәм» дигән кебегрәк шарт куй, соңыннан кыз моны Салих алдында фаш итсә иде. Бу күренешкә комичность җитми. Яңадан уйла әле. Туфан карандаш белән укыды бугай. Ул детальнорак язар.*

*Эшең әйбәт бара! Пьеса шулай инде ул. Эшли-эшли шомара. Мин монда интегеп ятам әле әллә ни язалмыйча.*

*Уңышлар! Илдар Юзеев. «Крутушка». 15.01.80».*

Илдар Юзеев турында сөйләгәндә, аның гаять дәрәҗәдә юморга бай, иң авыр чагында шылтыратсаң да: «Синең алда зарлану оят, Фәнис», — дип, сүзне иҗат мәсьәләләренә боруын, зарланмыйча кала алуы белән дуслары алдында үзенең дәрәҗәсен тагын да күтәрүен әйтми мөмкин түгел.

Илдар Юзеевнең тагын бер матур сыйфатын әйтмәсәм, сүзем тулы булмас. Ул минем берәр әсәремне ошатса: «Молодец, Фәнис, шәп әсәр язгансың», — дип әйтергә үзендә көч таба иде. Хәзер, кызганыч, каләмдәшләр бер-беребезгә җылы сүз әйтерлек көч таба алмыйбыз. Күңелләр тарайды. Берәрсенә яхшы сүз әйтсәк, бу аңа зур бүләк булыр дип куркабыз бугай. Ә бит югыйсә кешене шатландыру үзеңә дә рәхәт.

*3 май, 1987*

**РӘДИФ ГАТАШ**

# Остазыбыз!

Илдар Юзеев — Татарстанның халык шагыйре... Халык шагыйре... Яздым да, ничегрәк яңгырый әле дигәндәй, тагын бер тәкрарладым. Әйе, бик матур, нәкъ тиешенчә ишетелә икән ләбаса: халык шагыйре...

Сиксәненче елларга кадәр без бу исемне Тукаебызга карата гына куллана идек. Әйе, Гафури да татар халык шагыйре түгел иде шикелле, ә Башкортстанның халык шагыйре... Такташ исә — сөекле шагыйребез, трибун шагыйребез. Муса Җәлил — ялкынлы көрәшче, патриот шагыйрь. Хәсән Туфан — зур шагыйребез, аксакал әдип... Официаль указ белән дә халык шагыйре исемен алу бәхетенә беренче булып замандашыбыз Сибгат ага Хәким ирешге — моңа ихлас шатландык. Аннары Гамил ага Афзал... Инде менә Илдар Гафур угылы Юзеев — алтмыш яшен тутырган өлкән, ихтирамлы каләмдәшебез бу исемгә лаек булды. «Горурлан, Шигърият-әнкә, менә нинди талантлы улларың бар!» — дип кычкырып горурлансаң да урынлыдыр, мөгаен... Тәгаен шулайдыр.

Илдар Юзеев — халык шагыйре... Әйе, бала чагында ук шигырьгә килеп, әле ун яшендә фронттагы әтисенә хатны шигырь белән язган, «сәлам белән шагыйрь улыгыз» дип горур имза куйган сабый шагыйрь — халыкның үз баласы, үз шагыйре иде бит!

Инде кырык елдан артык шушы юлдан армый-талмый атлап килүче, «Таныш моңнар» поэмасыннан башлап бүгенгәчә халыкны — укучыларын гел сокландыра, гаҗәпләндерә, яраттыра белүче шагыйрь — чын-чыннан халыкның үз моңнары иясе, бәхетле шагыйрь ул. «Фәрит-Фәридә», «Әнкәй», «Карурман» поэмаларында да халыкның үз язмышы, ул баш куйган «таш диварлар авазы», татарның үлемсез рухы, сикәлтәле, борылмалы юллары... «Соңгы сынау» булыр дип ышанган Җәлилләр, «очты дөнья читлегеннән» дип кабатлаган Тукайлар моңы... Халык фаҗигасе һәм өмет. Үлемсез моң һәм көч.

Менә шуларны шигъри театр итеп дөньяга чыгару белән дә ул — халык шагыйре. Әйе, лирик-фәлсәфи һәм эпик стильләр синтезы булган шигъри театр. Ә театр халык рухының көзгесе түгелмени?

Ә җырлар? Әлеге «Таныш моңнар»дан күңелләргә күчкән «Резидәкәй» (Ш.Мәҗитов), «Яшь наратлар» (Җ.Фәйзи), «Кайтам инде», «Бөркет турында җыр» (Сара апабыз Садыйкованың сагынычлы көйләре!), «Серле чәчәк» (М.Яруллин), «Кыр казлары артыннан» (М.Имашев) һәм башка бик күпләр. Кайда гына җырламыйлар аларны! Халыкчан алар, якты, ашкынулы, сагышлы рух белән өртелгән алар! Ниһаять, бу моңның «Ерактагы кәккүк авазы» булып рок-операга (Р.Кәлимуллин) күчүе... Тарихи моң юллары бу!

Драматургиясендә дә Илдар ага — шул ук лирик шагыйрь. «Янар чәчәк»не, «Сандугачлар килгән безгә»не, «Кыр казлары артыннан»ны һәм соңгы пьесаларыннан берсе — «Ак калфакны төшердем кулдан»ны искә төшерик. Шул ук сурәтле фикерләүләр, халыкчан бизәкләр, шигъри тел һәм чаралар аларда!

Шулай, республикабызның Г.Тукай һәм М.Җәлил премияләре лауреаты И.Юзеев — бик күп эшләгән, нәтиҗәле язган әдип.

Моңлы. Әрнүле. Шашкын романтик. Фәлсәфи фикерле олпат ир. Җитди аксакал. Йә юмор-көлке белән дә ялтырап китүче әдип — әйе, бу өлкә дә ят түгел аңа; балалар шигыре дә чит түгел.

Шунысын да әйтми кала алмыйм: ул күпләребезне иҗатка илһамландырган шагыйрь булу белән бергә турыдан-туры остаз да. Күп аның шәкертләре, бик күп. Хәтта үзеннән ун яшькә өлкән Мәхмүт Хөсәен дә (урыны җәннәттә булсын!) аңа «остазым» дип мөрәҗәгать итә иде кичәләрдә. Язучылар берлегендә күп еллар яшь иҗатчылар белән эшләде ул. Шигърият һәм әдәби осталык турында мәкаләләрен дә күп язды. «Сигез йөз яшь язучыбыз бар!» дип горурланып сөйләп йөрде. Моны күпсенделәр, азайтырга куштылар. Ә хәзер: «Җиде миллионлы халыкка җиде мең язучы да күп түгел», — дибез. Хак та. Иркен ил — суверен Татарстан талантларын да кайгырткан, алдан чамалаган икән булачак халык шагыйре!

Кыскасы, бу олуг исемгә лаек булу бәйрәменә шагыйрь зур әзерлек белән һәм зур иҗат белән килгән. Бу — бәхәссез. Шунысы куанычлы: бу мәртәбәле үсеш юлы безнең, замандашларының күз алдында. Шуңа да бүген аны кычкырып, сөенеп котларга хакыбыз бар дип беләм:

— Мәрхәбә, юлыңны озак дәвам ит, халык шагыйре Илдар ага! Халык моңыннан аерылмыйча озак яшә, яз! — дип эндәшәм аңа.

*1993*

**РАБИТ БАТУЛЛА**

# Әзерҗавап Илдар Юзеев

«Әзерҗавап» сүзе үткен телле, югалып калмыйча шундук җавап бирә торган кешегә карата кулланыла. Илдар абый белән бер генә тапкыр мәҗлестә утырган кеше дә аны гомере буе онытмаячак. Юк, ул күп сүзле түгел иде, табындашларын игътибар белән тыңлап утыра-утыра да бер-ике генә сүз кыстырып куя, мәҗлестәшләр шартлап көлә.

Илдар Юзеев чит кешеләр янында мәзәк сөйләмәс, сүзгә катнашмас иде, әмма сере сыя торганнар янында аның авызыннан мәшһүрләребез турында мәзәк хәлләр, кызганыч вакыйгалар чишмә суы кебек туктаусыз агып тора иде.

Илдар Юзеевның иҗатын ике канат һавада тотып тора. Аның берсе — лирика, икенчесе — юмор. Кайсы гына поэмасын алып карама, анда сагыш, лирика, моң чыңлый. Аның шигъри моңнары драматургиясендә дә колач җәя, лирикасы белән юморы, бергә үрелеп, тамашачы күңелендә җылы хатирәләр калдыра.

Аның үз холкы иҗатында тагын да ачык булып чагыла. Илдар ага Юзеев тормышта гел моңсу, хәтта сагышлы да иде. Дус-ишләре белән очрашкач, аның сагышы каядыр юкка чыга, табын янында әзерҗавап, үткен телле чичән утыра.

Аның мәҗлесләрдә сөйләгән бихисап күп мәзәкләре, сагышлы вакыйгалары ничә еллар буена каләмдәшләренең күңелен күтәрде, мәгълүмат бирде. Ләкин, ни кызганыч, аларның күбесе онытыла бара.

Шулай да мин заманасында ул сөйләкләрнең кайберләрен куен дәфтәренә теркәгәнмен, хәтеремдә саклаганмын. Шуларның берничәсен укучылар игътибарына тәкъдим итәм.

# Мизгелдәк

Бер мәҗлестә Илдар Юзи шундук әйтелгән сүзләргә рифма табуы белән бөтен мәҗлестәшләрен шаккатыра. Шулчак Нәби Дәүли әйтә:

— Илдар, мин әйткән сүзгә рифма табалмыйсың! — ди.

— Табам! — ди Илдар.

— Табалмыйсың! — ди Нәби Дәүли.

Бәхәсләшәләр болар, отылган кеше табынга түләргә тиеш була.

— Әйт сүзеңне! — диләр Нәби Дәүлигә.

— Давление! — дип кычкыра Дәүли.

Илдар Юзи шундук мизгелдәк әйтә:

Их, дусларым, сезнең белән
Күтәрелә давление;
Ул тагын да күтәрелә,
Күрсәм Нәби Дәүлиене.

Мәҗлес шартлый, көлә, Илдарны котлый, Нәби Дәүли хисабына сыйланачагын сизенеп, котыра-котыра кул чаба. Нәби Дәүли сүзендә тора.

# Ике сөяркә

Туфан Миңнулла:

— Йөремсәк ир-ат «мәхәббәт»ләренең күп булуы белән масая. Илдар, синең сөйгәннәрең ничәү булды?

Илдар Юзи:

Сөйгән ярың синең ничә, диеп,
Син сорыйсың, Туфан, сорама!
Сөйгән ярым минем икәү, Туфан,
Берсе — шигырь, берсе — драма, —

дип җавап бирә Туфанга.

**МАНСУР ШИҺАПОВ**

# Кирәклеләр китә

*Илдар Юзеев вафатына*

Китә кеше... Җаның сызлап кала,
Язмышка без бик зур үпкәдә.
Ни аяныч, кирәклеләр китә,
Алар кирәк, ахры, Күктә дә.

Пәйгамбәрдәй затлы җаннар сүнә,
Ачынудан йөзләр саргая.
Әллә инде Тәңре тирәсендә
Пәйгамбәрләр сафы азая.

Иртә сүнә шагыйрь, әдипләре,
Намус, вөжданкае сыкрап.
Шундый исәненең үкчәсенә
Заман басып килә җан сорап.

Китә кеше... Яхшылары китә,
Гүя йөрәк тамырларын актарып.
Кирәкленең гомерен озайт, Аллам,
Сүнгәч булмый аны кайтарып.

**РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН**

# Ул минем остазым иде

Казаннан миңа хат язган беренче чын шагыйрь Илдар абый Юзеев булды. Ул Язучылар союзында әдәби консультант булып эшли башлагач, мин аңа үземнең шигырьләремне юллаган идем. Ул матур итеп җавап язып җибәрде. Казанга килгәч, яшь шагыйрьләр семинарында йомшак кына шигырьләрем турында үзенең җылы сүзләрен әйтте, беренче фатихасын бирде. Семинардан соң «Социалистик Татарстан» газетасында яшьтәшем Фәннур Сафин белән икебезнең шигырьләрне кереш сүз белән бастырып чыгарды. Беренче шигырьләремне «Беренче карлыгачлар» җыентыгына әзерләп бирде. Өченче курста укыганда бугай, мине эзләп, ул үзе университетка килеп керде. Яшь шагыйрьләрнең Ереванда узачак V Бөтенсоюз фестивалендә катнашырга бер яшь иптәш кирәк булган да мине шунда җибәрергә уйлаганнар икән. Илдар абыйның фатихасын алып, шунда булып кайттым. Беренче китабыма да кереш сүзне ул язды. Язучылар союзына керергә дә ул тәкъдим итте. 50 яшемә чыккан «Уфа — Казан юллары» исемле китабымдагы баш сүз дә Илдар абыйныкы.

Ул минем остазым иде. Фикердәшем, сердәшем иде. Гомерем буена өлкән дустым булып калды. Бөекләрнең үзе вафатыннан соң дуслары күп булучан. Әмма бу очракта, тыйнаксызлык булып тоелса да, шулай дип расларга хакым бардыр. Ул дуслык, әлбәттә инде, остаз белән шәкертнең фикер уртаклыгына, үзара ихтирамлылык хисләренә нигезләнгән дуслыгы иде. Ул мине, Башкортстаннан килгән яшь шагыйрьне, җитәкләп диярлек шигърияткә, әдәбият дөньясына, язучылар арасына алып кергән әдип. Бүгенге көнгә кадәр минем иҗатыма күз-колак булып яшәде, усаллардан якларга, гаделсезлекләрдән сакларга тырышты. Яшермим, якташлыкның да файдасы тигәндер. Күңелләр, хисләр бертөрлерәк иде шул, серләребез сыя иде, дөньяга, шигырьгә, язучылар даирәсенә карашларыбыз туры килә иде. Безнең дуслыгыбыз шагыйрьләр дуслыгы гына түгел, ә абый белән энекәш дуслыгы да булды шикелле. Һәрхәлдә, мин һәрдаим шуны тоеп яшәдем. Сүзләремне Шәүкәт абый Галиев тә хуплар дип уйлыйм. Ә менә алар чын дуслар иде инде! Ике олуг шагыйрьнең олуг дуслыгы. Дистә елларга сузылган, ерак юлларда узылган, авыр заманнарда чыныккан һәм бер генә дә суынмаган дуслык! Гомумән дуслары күп булды аның: Гариф Ахунов, Әнгам Атнабай, Рафаэль Сафин, Марат Кәрим, Туфан Миңнуллин, Альберт Яхин, Рәдиф Гаташ, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалим, Зөлфәт... Ул һәрчак каләмдәшләренә, якташларына, өлкәннәргә һәм яшьләргә тартылып яшәде. Кеше аерып тормады, күңеле тартса, үзе дә тартылды, яхшы, ышанычлы дус була белде. Аның һәрчак халык арасында буласы килә иде. Сәламәтлеге мактанырлык булмаса да, иренмәде, сәфәрләрдән кайтып кермәде. Төрледән-төрле мәҗлесләрдә, табыннарда, кичәләрдә һәм җыелышларда Илдар абыйның булуы бик тә табигый, бик тә килешле тоела торган иде. Үзенең җор, тапкыр сүзләре белән һәркемне сокландыручы шагыйрь чын мәгънәсендә чичән иде. Илдар абыйның сирәкләрдә генә очрый торган бу сәләте җәмәгатьне җанландырып, мәҗлескә ямь өстәп җибәрә. Аңа ияреРгә тырышучылар да табыла. Без дә кушылган булабыз. Әмма кая инде Илдар абыйга җитүләр! Аның бит һәр сүзгә рифмасы әзер, һәр җөмләсе — афоризм, һәр җавабы — энҗе-мәрҗән... Остазның бу сыйфаты бигрәк тә юлда йөргәндә, ерак сәфәрләргә чыкканда ярап куя торган иде. Аның белән әйтешә-әйтешә, сүз ярыштыра-ярыштыра, аны тыңлый-тыңлый юл озынлыгын сизми дә каласың.

Илдар абый беренче карашка шат күңелле, ачык чырайлы, бернинди кайгысы булмаган бер бәхетле кеше шикеллерәк тәэсир калдыра иде. Ә бит ул чыннан да татар әдәбиятының бәхетле бер шагыйре. Беренче поэмаң белән үк халык арасында популярлык казанып, шуны ярты гасыр дәвамында бер генә көнгә дә югалтмый кара әле син?! Ул шигърияткә бик яшьли килде, тормышта да, иҗатта да яшь күңелле булып яшәде, шул яшь күңелле килеш китеп тә барды... Әмма аның күңеле тулы фаҗига, җаны тулы хәсрәт иде.

Ул болай үзара сөйләшкәндә юашрак, кыюсызрак холыклыга охшаган иде. Көндәлек тормышта да тыйнаклыгы белән аерылып торды. Сәламәтлеккә дә туймады, бәлки, шуңа күрә шулай тоелгандыр да. Асылда исә, аннан да принципиальрәк, аннан да туры сүзлерәк шагыйрьләр тагын булды микән? Бигрәк тә шигырь турында сүз барганда, бигрәк тә татар шигыренә тел тидерә башласалар, Илдар абый ярсыган арысланга әйләнә торган иде. Ә шигырьләрен ничек укый иде ул? Янып, ялкынланып, кайнарланып. «Язылмаган поэма»сын укыганын ничә тапкыр тыңлаганым булды. Яратып сөйли иде ул аны, җитмәсә, яттан сөйли иде...

Илдар Юзеев әдәбиятта тыңлаучан, акыллы һәм лаеклы шәкерт була белде. Аның остазлары Хәсән Туфан белән Сибгат Хәким иде. Ул бик яшьли остазларының игътибарын җәлеп итте, аларның күңел җылысын тоеп яшәде. Аларны һәрчак ихтирам итте, аларны берчакта да сатмады. Ул холык-фигыле белән дә, иҗатының олылыгы белән дә остазларына охшаган иде. Шунысы гаҗәп, аның иҗатына бер генә тәнкыйтьче дә тәнкыйть сүзе әйтә алмады. Сибгат Хәким иҗатына да әйтә алмаганнар иде. Бергә

җыелган чакларда, арабызда нинди генә усал телле каләмдәшләр очраса да, Илдар абыйдан көләргә, аны кимсетергә тырышучыларны хәтерләмим. Туфан кебек әүлия кеше иде шул ул. Үзе дә кешелекле, ярдәмчел һәм ихлас остаз була белде. Бөекләрнең матур традицияләрен үзенең шәкертләренә биреп калдырды. Аның шәкертләре татар әдәбиятында бихисап. Безнең буын, бездән соңгылар — барыбыз да Илдар абыйның шигърияттәге энекәшләре һәм сеңелкәшләре.

Ул югары урыннарда эшләмәде, гомере буена яшь иҗатчыларга ярдәм итеп яшәде. Хезмәт юлын «Ялкын» журналында башлаган иде, Язучылар союзында, «Казан утлары»нда дәвам итте. Инде пенсиягә чыккач, безнең сүзне тыңлап, яңадан балалар басмасына — «Сабантуй» газетасына эшкә килде, бөтен җаны-тәне белән яңадан балалар иҗатына чумды. Өр-яңадан балалар өчен яза башлады. Без аның белән иңгә-иң торып балаларга хезмәт иттек. Киңәшләшеп, фикерләшеп, бергәләшеп эшләдек, якынаеп, туганнар кебек булып беттек.

Аның Олы Иҗаты күпкырлы, ә Илаһи Сазы күп кыллы иде. Ул кыллар — татар халкының күңел кыллары. Ул тылсымлы кыллардан чыккан мөкатдәс моңнар безгә бик тә якын, бик тә кадерле. Ул татар күңеленә иң якын шагыйрьләребезнең берсенә, халкыбызның бәгырь кисәгенә әверелде...

Без аны сагынабыз.

Без аны бик озак сагынырбыз әле.

*2002*

**ЗӨЛФӘТ**

# Яшьлекләрнең яшьтәше

Шагыйрь Илдар Юзеевның яшьлек, саф мәхәббәт бөркелеп торган романтик иҗаты — бөтен татар дөньясын хисләндергән чор — минем яшүсмер елларыма — беренче мәхәббәттән иләсләнгән, шул иләслектән күңелдә шигырьләр тәлгәшләнгән көннәремә туры килде. Илдә Хрущевның «яз җилләре» исә башлаган чорлар. Ялтыравык-шалтыравык шигырьләрдән ялыккан яшь йөрәкләргә табигать һәм заман шундый лирик талантны бик белеп биргәндер. Баксаң, шигырьләрнең көче сәхнәгә чыгып кычкыруда гына түгел икән. Шигырьне күзең-күңелең төшкән кызга мәктүб язганда, кызны тәмам эретер өчен өстәп язарга да мөмкин икән әле. Ай яктысында шул кызга иң үтемле сүз шигырь икән ләбаса. Безнең буынга ягымлы лириканың шаукымы әнә шулай килеп кагыла башлады.

Ул чорда илне, әдәбиятны дер селкеткән, бөтенләй үзгәрткән-яңарткан хәл-әхвәлләрне хәзер барыбыз да бик яхшы беләбез инде. Әмма нәфислекнең, хиссиятнең күңелләр өчен никадәр тансык булуын шул шаукымлы чорны үзләре кичергән кешеләр генә тулаем беләдер, мөгаен.

Язмышым, шөкер, татар шигыре дөньясында шагыйрьнең үзе белән очраштырды.

Илдар абый туктаусыз иҗатта. Һәм бу иҗат гаять тә колачлы. Дөнья классикасына аһәңдәш шигъри фаҗигаләр. Җәлилнең, Тукайның фаҗигале һәм бөек язмышларын татарны гына түгел, бүтән халыкларны да тетрәтерлек колачлы һәм фәлсәфи поэмалар-трагедияләр.

Һәм мондый яңгырашлы шагыйрьнең сәхнә әсәрләре төрки телле театр сәхнәләрендә әле дә яңгырый тора икән, бу һич тә гаҗәп түгел.

Поэзиядә һәм, гомумән, әдәбиятта трагедия һәм юмор бергә үрелсә, сискәндергеч әсәрләр дөньяга килә. Илдар абыйга Ходай юмор хисен дә, трагизм хисен дә мулдан биргән. Шушы ике агым бергә кушылмаса, тоташ елау һәм тоташ көлү генә торып калыр иде. Фәлсәфи акылы һәм уйнак йөрәге шагыйрьгә шул ике агымны колачлы-күләмле әсәрләрендә нәкъ кирәгенчә кушарга ярдәм итә, күрәсең. Һәрхәлдә, миңа шулай тоела.

Шактый еллар инде мин «Чаян»ның әдәбият бүлегендә. Һәм мин белә-белгәннән бирле Илдар абыйның шук каләме «Чаян»га җан өрә килә.

Гомумән, аның белән «нормально» гына сөйләшеп булмый. Шагыйрь һичтуктаусыз каламбурлар сибә, экспромт рәвешендә иҗатташларына эпиграммалар «тондыра». Кыскасы, юмор җене һаман кытыклап тора аны.

Юморга аерата балалар хирыс. Шуңа күрә дә И.Юзеевның балалар өчен язганнары «Пони малае Җирәнкәй» белән генә чикләнми. Балалар бакчалары тәрбиячеләре, мәктәпләрнең татар теле һәм әдәбияты укытучылары кулында һаман сез И.Юзеев язган китапларны күрерсез.

Мин ышанам: аның иҗаты безнең яшьлек өчен нинди серле яңалык булса, яңа буыннарның яшьлеге өчен дә ул иҗат шундый ук серле яңалыктыр.

Кыскасы, яшьлекләргә яшьтәш иҗат бу... Чорның төсмере булырлык иҗат. Зур, чын иҗат кына чор төсмере була ала.

Киләчәк буын, И.Юзеев поэзиясенә карап, безне — чорыбызны аңларга, күз алдына китерергә теләсә: «Шигъри заманда яшәгән болар, билләһи!» — дип уйга калыр.

Шагыйрьнең китаплары безнең хакта сөйли. Һәм сөйләячәк әле.

Кырыс, болгавыр заманга юлыктык әле бүген...

Иманым камил: чор кырысланган саен, күңелләрдә шигъриятнең кадере артачак. Күңел дигәнең һәрчак җылыга мохтаҗ. Мондый дәвердә бигрәк тә. Бик тә кыен чакларыгызда, бисмиллагызны әйтеп, ачыгыз шигырь китабын! Җылыныгыз шигырь җылысында!

*18 март, 2002*

**РИЗВАН ХӘМИД**

# Мәңгелек булмаса да, гомерлек...

Фатирыбыздагы шәхси китапханәмдә Шекспир, Тукай, Исхакый, Камал, Тинчурин, Такташ, Еники кебек классикларның китаплары белән бер рәттә Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев һ.б. үзем якыннан аралашкан замандаш классикларның әсәрләре дә иң дәрәҗәле киштәләрдә торалар. Әгәр дә әдипнең үз сүзләре белән әйтсәк, «язу карасына исерек килеш ялгыш тәпиләрен манып чыккан таракан эзен хәтерләткән» почерклы Илдар Юзеев автографларын хронологик тәртиптә тезеп куйсак, икебезнең арабыз ничек, елдан елга үзгәрә барып, фикердәшлеккә әверелә-әверелә якынаюын күз алдына китерергә була. *«Ризванга — КДПИда очрашу истәлеге. Илдар Юзәй. 10.VII.67. Казан».* Бу — аның иң беренче бүләге: «Яшьлек дустыма» дип аталган гади дәфтәр калынлыгы, уч төбе чаклы кечтеки генә китабыннан монысы. Мондый автографны шагыйрьләр очрашу вакытларында үзләренә таныш булмаган теләсә кемгә сырлап бирәләр. Мин — икенче курс шәкерте: шунда тыныч кына укуымны бүлдереп, өч елга якын Кара диңгездә чик буе корабында хезмәт иттергәннән соң, укуны ары дәвам итәргә кайтканыма берничә ай гына әле. Хәрби диңгезче киемем белән бүтән студентлардан аерылыбрак торганмындыр, бәлки — шуңа тәтеде микән миңа бу автографы? Чөнки, хәтерлим, ул чакларда язучылардан, әрсезләнеп, автограф сораганым юк иде сыман. Ә менә бусы — тагын унбиш ел узганнан соң язып биргәне — «Мәхәббәт китабы». Беренчесе белән монысының аермасы — җир белән күк арасы: *«Ризванга — бергә яшьнәп узган яшь гомерләр истәлеге. Илдар Юзәй. 11.V.82. Казан».* Янә өч елдан: *«Ризван! Синең белән булган һәрбер очрашу мәңгелек булмаса да, гомерлек... Илдар Юзәй. 6.VIII.85».* Шигырьләрен, поэмаларын, трагедияләрен берләштергән «Мәңгелек белән очрашу» дигән китабында. Шуннан соң биргән автографларын барысын да монда китереп тормыйм: алары, үземә бик кадерле булсалар да, ике арадагы мөнәсәбәттә «стабильлек» чоры урнашканын гына раслыйлар. Ә бит мәшһүр әдип нәкъ шул чорда гаять тирән кичерешләр белән яшәде: үз иҗатын, үз гомерен аяусыз тәнкыйть күзлеге аша үткәреп, кабат барлап чыкты, үзе өчен бик үк уңай булмаган кырыс нәтиҗәләр ясады:

Ник кадерсез соң без, кадерсез?
Була кайчак: югаласы килә
Хәбәр-хәтерсез һәм каберсез...

Бу өметсез һәм рәнҗешле юллар туксан икенче елда язылганнар.

Һәм менә алты елдан Илдар Юзеев миңа «Уйлый күңелем төрлесен...» дигән җыентыгына түбәндәге сүзләрне язып бирә: *«Ризван! Әле дә шагыйрь булмадым дип, гел сөенеп йөрерсең... Илдар Юзәй. 22.01.98».* Чын халык шагыйре... шагыйрь булуына үкенә! Ник дигәндә, ул шушы үтә болгавыр «үзгәрешләр» чорында, башка кеше гомере буе җөрьәт итә алмаган тәвәккәллек эшләп, дөньяга, яшәешкә, тормыш һәм мәдәният, бигрәк тә милли мәдәният фәлсәфәсенә, әдәбият кыйбласына ревизия ясап, үз карашын-мөнәсәбәтен тамырыннан яңартты, элегрәк бик мөһим дип санаган кайбер карашларыннан арынды һәм... яшьләрчә җиң сызганып шигъри иҗатка башы белән чумды: юк, инерция белән генә, үҗәтләнеп иҗат итү түгел иде ул, Илдар Юзеевның ренессанс чоры иде! Моңа кадәр шагыйрь, әдәбиятка самимиләрчә бөтен җаны-тәне белән гашыйк булып язса, хәзер инде ул үз иҗатының «полководецы», аңа читтән карап бәя бирә ала, оста стратег шикелле әсәрләренең сафларын-рәтләрен, вак-төяк тактик максатлар белән мавыкмыйча, «мәңгелек» максатлардан чыгып тезә һәм шул ук вакытта элекке нечкә хисле, сизгер колаклы, чын сәнгатьчә нәфис сыйфатлы каләмен җуймыйча, уңга-сулга карамый бер-бер артлы шедевр исәпләнерлек шигырь көлтәләре, тирән эчтәлекле һәм мәгънәле шигъри трагедияләр тудыра. Ул елларда, тыйнакланып тормыйм, үзара мөнәсәбәтебез дә риясыз һәм эчкерсез җан дуслыкка әверелеп өлгергән иде инде: мин аның, язганнарымны укып, олпатларча бераз шелтәләп, бераз төртмә телләнеп, бераз минем өчен сөенгәнен белдереп, җиз быргыга алданып абынып куймасын бу җегет дигәндәй, дилбегәмне бераз тарткалап әйткән һәр сүзенә ышанам һәм ихлас рәхмәтем белән кабул итәм, ул да минем һәр киңәшемә колак сала. Их, кайтарып аласы иде шул елларны...

Инде хәзер Гафурычның — иң якын сердәш дуслары гына шулай үз итеп дәшәргә базына ала — миңа язып биргән соңгы автографына күз салыйк: *«Ризван! Проза сәхнәсенә — шәп драматургиягә — безеsettingездән сәлам вә ихтирам! Илдар Юзәй. 13.X.2002».* Ишарәсеннән үк аңлашыладыр, «Шагыйрь сәхнәсе» дип атаган җыентыгын бүләк иткәндә язган иде ул бу багышлавын. Күренгәнчә, Илдар Юзеев хәзер алдагы автографларында кулланган кырысрак җитдилеген ташлаган, Гафурыча нечкәлек һәм тыйнаклык белән йомшак кына шаярта. Дөнья куяр алдыннан ул миңа чыгып яткан күптомлыгын да бүләк

итәчәген әйтеп куйган иде — насыйп булмаган икән, ни кызганыч, өлгермәде. Анда ниндирәк сүзләр язып калдырган булыр иде икән ул?

Илдар абый Юзеев белән үзара танышлыгыбыз «миңа автографлар биргән чоры» белән генә чикләнми, дөресрәге, минем аны белә башлавым мәктәптә белем эстәгән елларыма ук карый. Унике-унөч яшьләрдә идем, «Тукай буласым килеп», үзем дә шәйләмәгәндә «Мәче белән сычкан» дигән көтүче чыбыркысы озынлыгы «поэма» язып аттым бервакыт шулай. Нишләргә инде хәзер бу су буе нәмәрсә белән? Дус париннарым мактыйлар сүз тезмәмне: «Син моны әрәм итмә, Казанда «Пионер» дигән балалар журналы бар, шунда җиффәр син аны!» Фәрештәнең «Амин!» дигәненә туры килгән, ахры, тәвәккәлләдем бит тәки. Атна-ун көн үтмәгәндер, ә ул көннәрнең һәр минуты ел тоелды, әлбәттә, китап хәрефләре белән ташка басылган җавап килеп төшмәсенме! Үземнең исем-фамилиям белән җавап бирүченең кул куюы гына гади каралы ручка белән сырланган: *«Сәлам белән Илдар Юзеев абыең».* Ә ташка басылган өлешенең эчтәлеген хәзер телем белән кайнар таба ялатсалар да исемә төшерә алмас идем, чөнки әле дә күз алдымда *«Хөрмәтле укучыбыз фәлән-фәлән!»* дигәне ярылып ята, аңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән эндәшү рәвеше башка сүзләрен томан белән каплады; чамалап кына хәтерлим, анда *«каләмең өметле», «тик сиңа әле күп укырга кирәк», «Тукайларны, Такташларны укы», «әлегә журналыбызда басып чыгарырлык түгел»* кебек сүзләр бар иде бугай трафарет җавапта. Ләкин бит, бәхетемә, килгән хатның әзер трафарет икәнлеген кем белгән ул чакта! Иң мөһиме, миңа, борыны кибеп бетмәгән малай кисәгенә, кем хат яза дисез? Бүген генә бер журналдан шигырен табып укыган зур шагыйрь Илдар абый Юзеев үзе! Бөтен ышкул гөр килә; «шигырең басарлык түгел» дигән сүзләргә беркем игътибар итми, укытучы апабыз да хәтта. Глауный, «каләмең өметле!» Ай-яй кәттә җавап...

Сүз җаеннан, заманында Илдар Юзеевның, әзме-күпме каләм тибрәткән башлап язучыларны барлар өчен, Татарстанны төбәкләргә бүлеп семинарлар оештырып йөрүенә кайберәүләрнең эчләре поша иде: «чын язучы әдәбиятка үз хуты белән килә», янәсе... Килә, пычагым! Ясалма һәм табигый киртәләрне җиңеп үтә алган үҗәтләр килә, ә килә алмый тормыш баткаклыгында ятып калган талантларның исемлеген кем төзегән?! Ә бит кайчак өлкән язучының, минем үземә килгән шикелле, тискәре җавабы да иҗат юлында бәяләп бетермәслек зур ымсындыргыч һәм канат бирүче этәргеч була икән... Хәлбуки миңа уңай тәэсир итте Илдар Юзеевның кире җавабы!

Шулай итеп, теге хаттан соң бер-ике ел эчендә Башкортстанның Ярмәкәй районы масштабында яңа шагыйрь пәйда булды: шигырьләрем-такмакларым район гәҗитендә әледән-әле берәмләп тә, көлтәләп тә басыла башлады. Әмма хәзер инде мин, бер авызым пешкәч, Илдар Юзеев белән туп-туры элемтәгә керергә ашыкмыйм: «кечкенә Апуштан зуп-зур Тукай булгач» кына аның алдына өлгергән җимешләремне илтеп салырга исәбем...

Ә киң әдәбият трактына мине район гәҗите сукмагыннан Аяз Гыйләҗев җитәкләп алып чыкты дисәм, һич тә арттыру булмас: дүртенче курста укыганда ук ул мине «Чаян» журналына эшкә тәкъдим итте, үз шаяртуы белән әйткәндә, «драматурглар бакчасына» да ул алып керде. Иң беренче пьесамны, үзе укыганнан соң, Мәскәү драматургы Ю.Эдлиска күрсәтте, аның киңәше белән Марсель Сәлимҗановка бирде (Аяз Гыйләҗев шулай һәр яңа драматургны, үз опекасына алып, режиссерлар белән таныштыра иде!). Ни гаҗәп, нәкъ шул чорларда ике олы әдип, Аяз Гыйләҗев һәм Илдар Юзеев, бер үк дәрәҗәдә диярлек, мине үзләре белән якын аралаштыра башладылар һәм киләчәктә минем өчен, каты бураннарда адашмаска юл читләренә утыртылган таяклар шикелле, катлаулы әдәбият юлында ике маякка әверелделәр. Шуңадырмы мин аларның икесе белән дә, үзара сөйләшкәндә, бик күп еллар «сез»дән «син»гә күчә алмый, шушы ике сүз арасында адашкаладым. Һәм, турысын әйтергә кирәк, Аяз Гыйләҗев белән аның гомеренең соңгы бер-ике елында гына, анда да сирәк-мирәк кенә, «син»гә күчәргә җөрьәт иттем бугай. Ә Илдар Юзеев үзе миңа: барыбер «сез» белән «син» арасында буталасың — татарлар гомер-гомергә «син»не якынрак иткән, тыйнаксызлык санама, дип, мине уңайсызлыктан - коткарды. Илдар Юзеев, гомумән, гадилекне өстенрәк күрә иде: гел сабыр холыклы, йомшак мөгаләмәле кеше булып калды. Ә инде җанында җыелган рухи байлыгы белән уртаклаша башласа, ул үзен магнат кебек тота: аның эш бүлмәсенең ишеге һәрвакыт һәркемгә шар ачык булды. (Илдар Гафурович гомере буе, якты дөнья белән мәңгегә хушлашканчы, кайда да булса штатта эшләде, «бераз ял итеп алуы» гел берәр хастаханәгә кереп ятып, елдан-ел какшый барган сәламәтлеген әз генә сипләтүенә тәңгәл туры килә иде.) Ул көн дә шул бүлмәсендә әллә кемнәр белән шигырьләрен төзәтеп мәш килә, чөнки үзе язучы булырга теләүчеләрнең кытыгын китереп йөри. Бер дә булмаса, бүлмәсендәге уен-көлкеле сөйләшүләр, Газиз Мөхәммәтшинның «Ике әби бәрәңге ала» дигән гүзәл хикәясендәге ике карчыкның гыйбрәтле әңгәмәсенә охшаган төс ала башлап, җеп очын чуалтса, Илдар Юзеев, сүз арасында хикмәтле берәр фикер-реплика ташлап, ләчтит боткасына төзегрәк юнәлеш бирә — яшьләр ул биргән тема тирәсендә «бии» башлыйлар. Әйтик, беркөнне яшьрәкләрдән берәү, төрле юк-бар пүчтәк сүзләрдән туепмы:

— Кызык, теге дөнья дигән нәмәрсә чынлап та бар микән, егетләр? — дип куйды.

Илдар Юзеев алдында өелеп яткан кәгазьләрдән күзен аера:

— Их, беләсе иде: башка планеталарда кортлар яши микән, дип сораган, имеш, бер тирес корты. Шуны белсәм, миңа бүтән берни дә кирәкми!

Дәррәү көлешүдән бүлмә түшәм күтәреп шартлый.

— Тизрәк язып куегыз моны, Илдар абый: юкса Марсель Гали, мин аны күптән кулландым инде дип, шундук үзенеке итәчәк!

Марсель Гали ул көнне анда булдымы икән, юкмы — истә юк, ә аның, берәр акыллы сүз ишетсә, шулай әйтә торган гадәте барлыгын барысы да әйбәт беләләр.

Илдар Юзеев үз репликасына ачыклык кертә:

— Күптән ташка басылган инде ул, наданнар, Карел Чапекны белмисез, — дип тыныч кына өстәп куя һәм, күзлеген кабат бер генә дә чал төшкән бөртеге күренмәгән маңгай чәче өстенә күтәреп куеп, тагын кулъязмаларга иелә.

Ул арада ярым шаян әңгәмә чех язучысы тирәсендә бөтерелә башлый. Ә Илдар Юзеев үз эшенә чумган: бүлмәсендә кызганнан-кыза барган диспутка колак та салмый сыман. Ниһаять, кемдер, авыр сулап:

— Күпме генә тамак ертсак та монда, Карел Чапекның бөтен дөньяга танылган данлыклы исеменә тырнак очы кадәр генә дә үзгәреш кертә алмыйбыз без, — дип, янәдән җеп очы чуала башлаган бәхәскә нокта куймакчы була. Илдар Юзәйне белми ул, наив җегет!

— Ә мин кайчан язучыларның макталган исемнәре түгел, ә язган әсәрләре мәйданда үзара ярыша башлар икән дип хыялланам...

Шагыйрьнең тавышы шактый зәгыйфь чыкса да, ишетәләр: бәхәс кинәт тына.

— Марсель Гали колагы өчен генә әйтүем: монысы да Карел Чапек сүзләре... Әйдә, Ризван, Бауман урамына төшеп, Тукайча «сыра пирәшләп» алабыз. Сөйләшәсе сүзләр дә күбәйгән чак...

Юк инде, Илдар Юзеев сырага, ара-тирә капкаласа да, артык мөкиббән киткән кеше түгел: колакларына бераз ял бирәсе килгәннән генә «сыра пирәшләү» уйлап тапкан.

Тагын икенче бермәлне Гафурычның максатын сиздерми генә тәртипсез көлешүгә файдалырак юнәлеш биргәне искә кереп калган. Шулай, сүзләр дуены кызып барган чакта, бәхәс өстенә Илдар Юзеевның үзе белән якынрак мөнәсәбәттә булган бер танышы килеп керде һәм, озак кына сүзгә катнашмыйча, йомылыбрак утырды. Гадәтенчә, эштән арный белмәгән бүлмә хуҗасы моның сәеррәк халәтенә игътибар итте:

— Нәрсә, туган, миндә җитди йомышың барыемы?

— Юк ла... Вакытымны кая куярга белми аптырап йөрүем.

— Тапкансың аптырар нәрсә... Вакытны әрәм итү ысуллары татарда мульон! Гайбәт сату, иләк белән су ташу, бозау имезү, комнан бау ишү, ир-атның горурлыгына чабата кайтару, егыласы урынга алдан салам түшәү. Менә шушы җегетләр шикелле бушны бушка тутырсаң да шәп үтә ул вакыт дигән нәрсә... Үзләреннән сорале: күз ачып йомганчы «мең дә бер кичә»лек ыспособ табып бирәчәкләр.

Җыелган халык бер мизгелгә генә тынып торды да ярыша-ярыша Илдар Юзеев әйткән темага синонимнар эзләргә кереште:

— Телевизор карап утыр! Кунак чакыр да килгәнен көт! Кәҗәгә тәкә эзлә! Машина сатып ал! Трай тип! Биләмгә йөр! Сәнәктән көрәк яса! Тавык күкәен очлы башы белән бастырып куй! Эт иярлә!

Китте-китте берсеннән-берсе «отышлырак» тәкъдимнәр... Теге кеше, мескен, биреләм-биреләм, мин үзем дә боларның барысын да эшләп караган кеше, дип көлә-көлә кулларын күтәрә. Ә Илдар Юзеев, әллә укып-төзәтеп утырган кулъязманы ошаткан, әллә «җегетләр»дән канәгать, белмәссең, төсе уңганрак кызгылт иреннәренең читләрен сизелер-сизелмәс кенә кыймылдаткандай итә. Күзлеге гадәтенчә киң маңгаенда, арыграк гәүдәсен кыйшайтып, бер җилкәсен салындырыбрак утыра...

Гафурычның сүз боткасын «вакытны бушка уздыру» темасына ерып җибәрүе бер дә сүз югында сүз өчен түгел: вакытыңны файдасызга сарыф итүне һич өнәми иде ул, җене сөймәде. Мисал өчен, аның белән бергә миңа да районнарга халык белән очрашуларга, бик еш дип шапырына алмыйм, чыккаларга туры килгәләде. Менә кайчан эшләтеп тә күрсәтә иде ул безне! Гафурыч, өлкән буларак, безнең җитәкчебез була, ул ни куша, шуны эшлибез. Бервакыт шулай кайсыдыр авылга килеп төшәбез: Илдар Юзеев, Рөстәм Мингалим һәм мин. Каршы алган хуҗалар безне иң элек, юлдан килгән кешеләр сез, дип чәйгә кыстыйлар.

Илдар абый әйтә:

— Әнә теге юл уңаендагы каралтылар нәрсәләр ул?

— Сыер абзарлары... Мөгезле эре терлек фермасы анда.

— Сыер савучы апалар шундалармы әле?

Төш вакыты килеп җиткән чак иде.

— Шунда булырга тиешләр... Төшкелекне савып бетереп киләләр булыр, — диләр хуҗалар, аптырабрак.

— Соң, шулай булгач? Әйдәгез, юл уңаена бер ун-унбиш минутка шунда сугылып чыгыйк... Бер-ике шигырь дә укырбыз беррәттән, бәлки. Тыңласылары килсә.

Хуҗалар, тагын да ныграк гаҗәпләнебрәк, «трудоголиклар», ахры, болар, дигәндәй, бер-берсенә мәгънәле итеп караштылар да:

— Ярый алайса, Илдар абый, шигырь уку сездән, тыңлау алардан, кем әйтмешли, — дип, безне тездән баткаклы сыер фермасына алып керделәр.

Хуҗаларның икеләнүләре нигезсез булмаган икән: башта эштән алҗыган хатын-кызлар теш арасыннан гына ризасызлык белдерделәр. Колакларыбызга «Ниткән шигырь ди инде ул... Ирләребезгә төшке аш салмаган» кебегрәк сүзләр чалына. Илдар абый белән Рөстәм икешәр-өчәр шигырь сөйләп, мин дә драматурглар-прозаикларча әдәбиятыбызның торышы хакында берничә сүз әйткәннән соң, тып-тын тыңлап торган сыер савучылар белән хушлашабыз:

— Ярый, кадерле апалар-сеңелләр, безне ихлас күңел белән тыңлаганыгыз өчен зур рәхмәт барыгызга да... Хушыгыз әлегә, аяк-кулларыгыз сызлаусыз булсын! — ди Илдар Юзеев өчебез өчен дә. — Вакыт тапсагыз, кич Мәдәният йортына рәхим итегез.

Гафурыч сүзен әйтеп өлгермәде — бер генә мәртәбә дә кул чапмаган дояркаларыбыз безне тыгыз боҗрага уратып алмасыннармы!

— Нинди эш инде бу?! Казан чаклы Казаннан килеп, ике шигырь укып китсеннәр, имеш... Ю-ук! Беркая да җибәрмибез... Тагын укыйсыз!

Ул арада җитезрәк киленнәрнең берсенең кулында яңа сауган бер чиләк сөт пәйда булды. Шуны ап-ак марля аша сөзеп, үзбәк пиалалары белән буы күтәрелеп торган куе сөт белән сыйлый-сыйлый, Рөстәм белән Гафурычтан тагын унбиш-егерме минутлап шигырь сөйләттеләр! Миңа җиңелрәк, шигырь укыйсым юк. Өстәвенә: «Без сине дә әйбәт беләбез, театрыңны телевизордан күрсәттеләр, бик ошады», — дип, күңелемне күтәрделәр. Шагыйрьләрнең шигырь уку белән мәшгуль булуларыннан файдаланып, тәмле сөт эчәм рәхәтләнеп...

— Шигырь яраталардыр болар дип һич башыбызга килмәгән иде, — дип тел шартлаталар хуҗалар, ашханәләренә кайтканда. Ул көнне безгә, җитәкчебез Гафурычның катгый «указларын үтәп», тагын дүрт җирдә әнә шундый очрашулар үткәрергә туры килде!

Менә шушындыйрак «гастрольләребез» кабатлана башлагач, Гафурычка, ярым шаяртып:

— Бүтән синең белән беркая да чыкмыйбыз! — дибез, уены-чыны белән бергә. Әмма Гафурыч эш стилен барыбер үзгәртмәде...

Илдар Юзеев үзенә таныш булмаган һәркемне иң башта җиз иләге аша уздыра торган иде: дусларча мөнәсәбәткә кертеп буламы бу адәмне, юкмы, янәсе? Ләкин аңа шул күзлектән карап «капшавын» сиздерми, иләге аша уза алмаганнарны махсус читләштерми дә: андыйлар үзләре, йөрәкләрен дуңгыз кылы капламаган булса, әкренләп ераклашалар. Сынавын узганнар тиздән аның туган шикелле якын кешесенә әвереләләр: ул алар белән тиңдәшләрчә гап-гади сөйләшә, хәлләрен сораша, иҗатлары белән ихластан кызыксына. Шуңа аның һәр сүзен йотлыгып тыңлыйлар, тапкыр сүзләрен файдаланып, анекдотлар чыгаралар. Без шуңа сәерсенә идек: җор телле әдипләр һәр уңышлы репликаларын үз иҗатларында файдаланырга тырышалар, чөнки андый тапкыр сүзләр авторлар үзләре дә көтмәгәндә, үзара гәпләшкәндә, кинәт туарга мөмкин. Шунлыктан аларны чит күзгә күрсәтми генә берәр каралама кырына теркәп куялар. Әйтик, Шәүкәт Галиев, интеллигент-самородок, бер сүзен дә әрәм итми: шундый афоризмнарын бергә туплап, кирпеч калынлыгы «Илһамым — мәхәббәтем» дигән китапта чыгарды. Аяз Гыйләҗевнең телендә дә, әсәрләрендә дә җорлык баштан ашкан. Ә Илдар Юзеевның нишләптер тапкыр сүзләре үз әсәрләренә күчми: иҗатында ул бик җитди, телдән әйткән тирән мәгънәле җор сүзләрен шаяру гына дип саный, авызыннан ишеткән афоризмнарны беркайчан да аның әсәрләрендә очратмассың. Йә инде, бервакыт Фоат Садриевка очраклы гына әйткән сүзе файдаланырлык түгелмени? Көннәрдән бер көнне Фоат Мөслимнән Казанга килеп төште дә күптәнге гадәтенчә иң элек Илдар Юзеевка визит ясады. Сүз ара сүз чыгып, Фоат:

— Җиңел кәсеп таптым әле, Илдар абый, — диде. — Дуңгыз фермасына библиотекарь булып урнаштым! Редактор эшеннән муеннан гарык булдым.

— Дөрес иткәнсең, Фоат, китапханәдә чучка булганчы, дуңгыз абзарында библиотекарь булу мең артык.

Бер тапкыр мин дә шулай Илдар Юзеев янына килеп керәм:

— Ник болай сөмсерең коелды? — дип сорый ул миннән, кәефсез икәнемә игътибар итеп.

— Бишбылтыр инде фатирыма телефон кертә алмый интегәм, кайчан мөрәҗәгать итсәң дә, управлениеләреннән «сезнең йортка кабель тоташтырылмаган» дигән отписка җибәрәләр, — мин әйтәм. — Ә бит алдыйлар, тоташтырылган!

— Алар шундый... Үлгәч тә кабелең якын булмасын алар белән! — дип көлә Гафурыч. Бүлмәдәгеләрнең шаркылдап көлүләренә әз генә дә исе китмичә, кабат кульязмалар өстенә иелә, тик бу юлы күзлеген маңгае өстенә этәреп өлгерми, башын яңадан күтәрә: — Үлгәч, дигәннән... Үлем бер дә куркыныч нәрсә түгел ул, җегетләр... Син берүзең үләсең, бүтәннәр исән кала — менә шунысы куркыныч!

Менә Илдар Юзеев турында язганнарымны янә бер кат укып чыктым да шиккә төштем: Гафурычыбызның сурәте минем тасвирламада артык төче, гел игелекле, үтә дә яхшы, киң күңелле кеше иде дигән тәэсир калдыра түгелме соң бу?! Корней Чуковскийча әйтсәк, «не портрет, а икона».

Юк, максатым һич ул түгел: кешегә хас булган бар нәрсәләр аңа да хас иде. Без эчкәнне эчә, без сокланганча гүзәл, сылуларга соклана. Урынында ачулана, урынында үпкәли, урынында кәефе кырыла... Тик бер нәрсәдә бүтәннәрдән аерылып тора: Илдар Юзеев беркайчан да үзенең чын хәлен читләр алдында ачып салмый. «Кәефләр ничек, Илдар абый», — дип сорасаң, үзенә килешеп торган калын күзлеге аша хәйләкәр төстә тыйнак кына елмая да соравыңа сорау белән җавап бирә: «Рөстәмнән, хәлләр ничек, дип сораганың бармы?» «Бар, — дим, — тик ул кайчан кызыксынсаң да: «Шәп! Бу кадәр шәп булганы юк иде әле моңарчы!» — дип котыла бит гел». «Вәт-вәт, минем хәлләр дә шундыйрак», — дип көлемсери Гафурыч. Үз сәламәтлегенә кагылган теманы яратмый иде ул куертырга. Табу. Әмма аның иҗатына кагылсаңмы?! Без, аның иң якын дуслары, иҗатына нинди дәрәҗәдә сизгер колаклы икәнен бик яхшы белә идек. Әсәрләренә карата саксызрак әйтелгән сүзләрне Илдар Юзеев искиткеч авыр кабул итә иде: гаделсезлекне, хөсетлекне һәм хәтта үзенә сиздереп аяк чалырга маташуларны күп кичерде ул. Яңа әсәрләрен «күрми калуларның» саны булмады. Без үзебез дә мактауга саранрак идек бугай. Ә иҗат кешесе сабый бала белән бер: эт өрер, бүре йөрер дип карый белми. Гафурычыбыз да шундый. Чөнки ул үзе безнең кечкенә уңышыбызга да ихлас йөрәктән сөенә, шәхси фикерем генә түгел бу, фәлән-фәлән кешеләр дә шундый ук әйбәт фикерләр әйттеләр, дип, үз сүзләрен куәтли. Мисалга, бер елны «Идел» журналында минем «Яртыясаклар иле» дигән язмам басылып чыкты. Беркөнне иртән-иртүк шылтырата бу миңа: «Ризван! — ди, тавышында минем өчен шатлануын яшермичә. — Айрат Арсланов таң тишегеннән шылтыратты: Ризван Хәмиднең эссесын «Идел»дән укыдыңмы әле? Тиз генә табып алып укы — үкенмәссең, бик шәп язган, маладис егет икән, дип, сине күкләргә күтәреп мактый! Укып чыктым — дөрес күтәрә, чукынчык... Тукта, беркая да кузгалма өеңнән, хәзер килеп җитәм, кибеткә дә йөгермә!»

Ярты сәгать тә вакыт үтми, ишектә кыңгырау чылтырый: Гафурыч елмаеп басып тора. Бер кулында «Идел» журналы, икенчесендә ирләр «чәе»...

Йә ул телефоннан кичләрен соң гына шылтырата:

— Тыңла! Иртәнгә калдырып торыйммы әллә дип уйлаган идем — синең иртәнге кояш артыңны кыздыра башлаганчы йокы симертергә ятканыңны беләм... Беркемгә дә, хәтта Шәүкәткә дә күрсәтмәгән өр-яңа шигырь...

Укый.

— Йә, ничек?

— Искиткеч шәп, Илдар абый, тик...

— Ниткән тик-микләр тагын?!

— Дүртенче строфасын тагын бер кат укы әле, Гафурыч... Фәлән сүздән башлап?

Иренмичә кабат укый. Мин, үз зәвыгым күтәрмәсенә басып, фикеремне әйтәм. Фәлән төшен, фәлән төрлерәк мәгънә өстәп, менә болайрак үзгәрткәндә ничегрәк килеп чыгар иде икән?

— Артыңны өйрәт!.. Ә, тукта, нидер бар синең сүздә дә... Уйлап карарга кирәк... Булды бу, типтәр, синнән бер ярты!

Заманында Рәсәйдә исеме киң танылган С.Шукшин исемле бер рухани галим яшәгән. Шул шәхес Чехов турында менә нинди сүзләр язып калдырган: «Новый человек, не знавший раньше писателя, едва ли выделял его из ряда других собеседников».

Бөек талантлар кайбер яклары белән генә булса да бер-берсенә охшаш булалар.

*12 апрель, 2007*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**

# Юзизмнар

Кәефе шәп чакта Илдар ага Юзеевтан юмор ургылып чыга иде. Әйтелгән бер сүзне очып барышлый эләктереп алып, шунда ук рифма таба һәм мәзәккә әйләндерә дә куя. Янәшәдәге каләмдәшләре шаркылдап көлә башлагач, мин дә кушылыйм инде дигән кебек, үзе дә юаш кына елмая.

Юлда йөргәндә бигрәк тә ачылып китә иде. Бер мәзәген йотып җибәрергә өлгермисең, икенчесе, өченчесе... Моның чиге булмас шикелле. Ул бит аны алдан әзерләмәгән, әңгәмә барышында килеп чыккан сүз аша тере мәзәк ясый да куя.

Шунысы хикмәтле, язган әсәрләрендә юмор бик күренми иде. Бәлки, ул кәгазь каршында артык җитди бер тәхеттә итеп хис иткәндер үзен. Бәлки, аңа юмор сибеп тору өчен тере күз карашлары, көлү алкышлары илһам биргәндер.

Мәзәкләр бүтән, көлешүләр бүтән иде шул Илдар ага барында. Хәзер менә күпме сүз Илдар аганың шаян, үткен, йөгерек рифмасына юлыга алмыйча ятим кала. Халык мәкальләрен дә кайчакта кире ягы белән әйләндереп куя иде ул. Менә истә калган бер-икесе: «Көзгең кыек булса, авызыңа үпкәләмә», «Язгы кыз ястык калынлыгы булса да ышанма, көзге кыз көзге калынлыгы булса да ышан».

Укучыларга мин Илдар ага үзе исән чакта укытып, фатиха алган кечкенә хикәяләремне тәкъдим итәм.

# Каз

Моннан күп еллар элек Илдар Юзеевның «Ялкын» журналында эшләгән чагы. Язучы Габделхәй Сабитов белән алар бер бүлмәдә утыралар. Яңа ел алдыннан Габделхәйгә туган ягы Минзәләдән каз китерергә тиешләр иде. Көнгә чыкса, гел каз турында сөйләп, тәмам алҗытып бетерә.

Аптырагач, Илдар Юзеев күрше кабинетка керә дә, хәйләсен сөйләп, машинистка кызны котырта. Тегесе Сабитовка шылтырата. Самими авыл кызы булып сөйләшә.

— Әлү, Габделхәй абыймы? Исәнмесез!.. Минзәләдән сезгә каз җибәргәннәр иде. И-и, анда кереп тормыйм инде, язучы абыйлардан оялам. Үзегез генә чыгып алыгыз, нәшрият янына мин хәзер килеп җитәм...

Габделхәй Сабитов тизрәк атыла-бәрелә чыгып йөгерә. Ишектән аның «каз» дигән сүзе генә яңгырап кала.

Кырык градуслы салкында, нәшрият каршында арлы-бирле йөреп, Габделхәй Сабитов каз көтә, бичара. Каз да юк, авылдаш кыз да юк...

Ә Илдар Юзеев коридордан килгән бер язучыны тәрәзә буена алып килә, хәлне аңлата, каз көтеп туңудан бөрешкән Габделхәй Сабитовны, күзәтеп, егылып-егылып көлешәләр.

Кырык градуслы салкында юка борынын өшетеп, ниһаять, Габделхәй Сабитов казсыз гына редакциягә кереп килә.

Шушы хәлдән соң, атна-ун көн үтә микән, Илдар Юзеевны телефонга чакыралар.

— Әлү, Илдар абый, исәнмесез! Анда язучы абыйлар янына кереп тормыйм инде, оялам. Яңавылдан мин, бик симез каз алып килгән идем...

— Кызыгыз да, казыгыз да кадалып китегез! Берни дә кирәкми! — дип, Илдар Юзеев телефон трубкасын атып бәрә.

Шул елны Илдар Юзеев туган ягы Яңавылга сабан туена кайта. Мәйданда аның янына бик чибәр бер кыз килә:

— И-и, Илдар абый, бик рәнҗедем әле сезгә. Кыш көне сезгә күчтәнәч булсын дип, шундый симез каз алып барган идем Казанга, ә сез телефоннан да сөйләшергә теләмәдегез.

Илдар Юзеев, кызга карап, казны күз алдына китереп, өнсез кала. Шуннан бирле ул кыз, әй... каз мәсьәләсендә җитди уйлана һәм күпмедер ел үткәч, «Кыр казлары артыннан» дигән пьеса яза.

# Ни бит...

Бер тарафтарак яшәгәнлектән, Илдар Юзеев белән композитор Зиннур Гыйбадуллин күпер төбендәге азык-төлек кибетендә очрашкалыйлар икән. Бу кибеттә йөк ташучы булып телсезләр эшли. Берсеннән-берсе таза, чибәр егетләр. Алар Зиннур Гыйбадуллинны күрүгә, елмая-елмая килеп җитеп, аны уратып алалар. Ә тегесе, егетләрнең җилкәсеннән кага-кага, нидер сөйли башлый. Авызын очлайта, башын селкеп куя, кашын сикертә, бот чаба, аягын күтәреп ала, йодрыгы белән маңгаена суга,

күзен кыса, көзән җыергандагы кебек бармакларын селкетә — егетләр исә бөгелеп-бөгелеп көләләр, рәхәтләнәләр генә.

Беркөнне Илдар Юзеев ярты сәгать буе кәнфиткә чират тора. Зиннур Гыйбадуллин исә ярты сәгать буе теге егетләр белән бер читтә тавышсыз гына сөйләшә. Әлеге дә баягы бөтен әгъзаларын хәрәкәттә тота.

Соңыннан Илдар Юзеев аңардан:

— Шулкадәр озак ни сөйләдең, син аларның телен беләсеңмени? — дип сорый.

— Ни бит, — ди Зиннур Гыйбадулла. — Ниткән бит инде... Нитәм дә... Нитәләр... Нигә нитмәсеннәр, мин бит ни!..

Берни аңламаган Илдар Юзеев:

— Зиннур, миңа да шул кул-аякларың белән телсезләр телендә генә сөйлә әле, — ди.

# Кызыклы «очрашу»

Илдар Юзеев Язучылар берлегеннән «Казан утлары» журналына телефоннан шылтырата. Телефонны Тәүфикъ Әйди ала.

— Тәүфикъ, коллективыгызга әйт, иртәгә чит ил язучылары белән очрашу була. Сәгать уникегә килсеннәр җыелышып.

— Нинди язучылар, кайсы илдән? — ди Тәүфикъ, сулышына кабып.

Ул елларда чит илдән язучылар килеп төшү кибеттә кара уылдык сату кебек гайре табигый хәл иде.

— Язып ал, — ди Юзеев. — Бирма дигән илдән. Шагыйрь Шатаг Фидәр, икенчесе — прозаик Ташар Имазин.

Бөтен дөнья язучыларын белеп бетерергә кызыккан Әйди:

— Минем китапханәмдә Шатаг Фидәрнең дә, Ташар Имазинның да китаплары юк шикелле, кызганыч, — ди.

— Менә хәзер булыр.

Бераздан «Казан утлары»ннан берәм-берәм шылтырата башлыйлар.

— Очрашуны соңгаракка күчереп булмыймы, төшке аш вакыты бит, — ди Рәдиф Гаташ.

— Кыяфәтлерәк адәмнәрме? Үзебезнең йолкышлардан да туйган, — ди Кояш Тимбикова.

— Ничек киенеп килергә икән? — дип сорый Рашат Низами.

— Бирма дигән ил Австралия утравындамы әле ул, Илдар абый? — ди Шамил Маннапов.

Икенче көнне берсеннән-берсе матуррак киенгән «Казан утлары» язучылары Илдар Юзеев кабинетына җыелалар. Юзеев аларга берәр бит кәгазь өләшеп чыга.

— Чит ил язучылары килгәнче исем-фамилияләрегезне кирегә язып чыгыгыз, тегеннән шулай куштылар...

Дулкынланган язучылар дәррәү эшкә керешәләр. Бераздан шаркылдашып көлү башлана. «Шатаг Фидәр» дигәне Рәдиф Гаташ, «Ташар Имазин» дигәне Рашат Низами икән бит, каһәр...

# Ашханәдә

Урак өстендә Илдар Юзеев бер яшь шагыйрь белән районга чыгып китә. Бик ачыккач, алар, юлда туктап, ашханәгә керәләр. Өстәлләрнең шапшаклыгына, эсселектән пыжыган һавасына күнегелгән инде. Кирәк бит, яшь шагыйрьнең ашыннан социализм шартларында өлгергән таракан килеп чыкмасынмы! Ачуыннан буылып, яшь шагыйрь дәррәү тора да ашханә мөдирен эзләп китә. Тавыш, хәрәкәт куба. Илдар Юзеев кына берни дәшмичә, тып-тын утыра икән.

Соңыннан, бар да үткәч, яшь шагыйрь, аптырап, Илдар Юзеевтан болай дип сорый:

— Ничек Сез шундый чакта тыныч кала аласыз?

— Авызың тулы таракан булса да, кеше алдында төкермә! — ди Илдар Юзеев.

**ЛӘБИБ ЛЕРОН**

# Олуг Шагыйрь белән әңгәмә

Берара «Таһир-Зөһрә» дигән бер бик күркәм гәзит дөнья күреп, укучылар арасында шактый популярлык казанып алган иде. Бу гәзитнең җиденче битендә мин «Җиделе лампа» сәхифәсе белән даими катнашып килдем. Чираттагысы — 2002 елның сентябрь санында басылырга тиешлесе — шәхсән үзем бик ихтирам иткән Илдар Юзеевка тәгаенләнде.

Алдан ук, ягъни шул елның 27 июнендә, сораулар әзерләдем («Үз-үзеңә нинди сөаль бирер идең?» дигән өстәмә сорау белән барлыгы сигез) һәм аларны Илдар абыйга тапшырдым. Сораулардан соң түбәндәге җөмләләр дә бар иде:

*«Илдар абый!*

*Булса әйбәт булыр иде:*

*а) Үзеңә шарж-рәсем, портрет-сурәтләр;*

*б) Үзеңнең фотосурәт (миндә дә бар бугай), яшьлек елларыннан истәлек-сурәт, остазлар белән төшкән бер-ике фоторәсем; Нил абый, Тәфтилә ханым, гаилә һ.б.*

*в) Юзизмнар!*

*г) Сиңа багышланган эпиграмма».*

Бу ахыргы ашык-пошык җөмләләрне искә төшерүем юкка түгел. Ни өченме? Аз гына сабыр...

Илдар абый — бик төгәл, пунктуаль кеше: сорауларга җавапларны икенче көнне үк алып килде, үзе машинкада бастырып. Әлбәттә, әңгәмәне мин Илдар абый белән кара-каршы утырып та ала алган булыр идем — эш минем иренүемдә генә түгел... Хикмәт шунда: әңгәмәдәш (бу очракта Илдар абый) үзе теләгән вакытта кәгазьгә «сөйли» ала, бер сорау белән икенчесе арасында тукталып уйлана ала... Фикерен туплаганда ялгышса-нитсә яисә хата-мазар җибәрсә, җәһәт кенә төзәтеп куя ала...

Илдар абый машинкада үзе бастырган сорау-җаваплар белән бергә минем кулдан гына язып биргән сорауларымны да, үзенең кульязмасын да миңа биргән икән. Мин нишләптер аларга артык әһәмият биреп тормаганмын — махсус папкага салып куйганмын... Әле менә беркөнне генә ул кәгазьләргә тап булдым һәм... шаккатып калдым!

Минем сораулар һәм аларны дәвам иткән җөмләләр Илдар абыйга иҗади дәрт, шаян шаржлар (юзизмнар!) язарга илһамлы этәргеч биргән икән ләбаса. Сораулар язылган шул ук кәгазь битендә әле болай, әле тегеләй урын алган каралама юллар — шигъри автопортрет шул хакта сөйли:

Чәче — өч-дүрт бөртек.
Сакалы — бер карыш.
Җитмеш яшьлек адәм —
Юзи — үзе шарж.

* * *

Такташ минем яшькә җитсә, бәлки, болай шаярыр иде:

Картлык,
Гомерең кыска синең,
Шундый кыска булып тоела.
Кичен чәчәк ата,
Ә таңында комың коела...

* * *

Кайчагында мин бик уңай булам,
Ачу килгән чакта бик кире.
Бармакларым минем — үземә таба,
Гәүдәм җиргә таба кәкере....

Илдар абыйның «Соңгы сорау» дигән сигезьюллыгын да өстәмә соравыма (Үз-үзеңә нинди сорау бирер идең?) җавап рәвешендә язылгандыр дип уйлыйм хәзер:

Туры юлда йөреп бөкерәйдем,
Турайта алмады Бәкере.
Сез аңларсыз, инде тынды диеп,
Яткан җирем булса кәкере.

Сорау билгесенә охшап киләм,
Соңгы сорау белән багамын:
Бөкерәйтми-кәкерәйтми генә
Табарсызмы бирәр җавабын?

Укып-карап, компьютерга бастырырга биргәндә, бу шигырьләрне Илдар абый кичә генә язгандыр дип башыма да китермәдем... Кая ул аларның Шагыйрь күңелендә бөреләнеп, шундук минем кәгазь битенә төшүе турында уйлау!..

Олуг Шагыйрьнең эчкерсез җаваплары тәэсирендә күңелемдә «Шагыйрь — шигырь язган әнисенең шәп әсәре» дигән сүзләр туып, алар сәхифәнең эпиграфы булды.

Илдар абый әнисе Шәкүрә апа белән, шулай ук янә әнисе, дәү әнисе һәм Нил абыйсы белән, шуларга өстәп үзе генә, аннары Аван Такташлар белән төшкән фотосурәтләрен дә китерде. Аван Такташ һәм тагын бер студент белән төшкән рәсем астындагы сүзләрне Илдар абый алдан ук үзе язган иде: *«Педагогия институты студентлары бәйрәм демонстрациясендә. Такташның улы Аван (рәсемдә уртада) шаярта:*

*— Сез әтине классик әсәрләр генә иҗат иткән дип уйлыйсыз. Ялгышасыз. Аның бер бездарный әсәре бар...*

*— Нинди әсәр ул?*

*— Ул... мин!»*

Шулай... Елмаеп алыйк та... Инде әңгәмәгә күз салыйк — янә Хәтергә кузгалыйк...

*10 гыйнвар, 2007*

# «Ул мине абыйларча гына кыйнады...»

Шагыйрь — шигырь язган әнисенең шәп әсәре.

*Л.Лерон*

*— Илдар абый, үсмер Илдарның шигърияттә тәүге адымнар ясаган чагын хәтергә төшереп үтик әле. Беренче шигырь кайчан, ничек, ни рәвешле, нинди форсат белән язылды, олуг Әдәбиятка килүдә кемнәрнең дә булса ярдәме тидеме дигәндәй...*

— Шигърияткә мәхәббәт уятучыларның беренчесе — әнкәй. Ритмның, аһәңнең ни икәнен ул Нил абый белән икебезгә мандолинада уйнап өйрәтте, үзе дә шигырьләр чыгарырга әвәс иде. Туган көн, туй, бала туу уңае белән авылдашлар аның янына киләләр иде.

Сугыш елларында лампа яндырырга керосин булмау сәбәпле, караңгы төшкәч, китапларны мич яктысында укыганым хәтердә... Кулыма Һади Такташның «Җир уллары трагедиясе» эләкте. Шагыйрьнең сихри-серле илаһи шигыре мине тетрәндерә, күкләргә алып менә... Такташ шигърияте мине шагыйрьләр дөньясына тартты. Аннан соң балачакта хыяллана да алмаган Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Шәйхи Маннурларның җылы да, таләпчән дә карашлары...

*— Әдәбиятыбызда күренекле урын алган, үзенә алмашка талантлы шәкертләр әзерләп, милли хәзинәбезгә бай мирас калдырып киткән Нил абыйны шигырьләреңдә, истәлек-язмаларыңда, үзара сөйләшкәндә юксынып, сагынып еш искә аласың... Нил Юзиев энесе Илдар Юзеев өчен, бертуган абый булудан битәр, янә шәхсән кем иде, күңелеңдә кем булып калды?*

— Беренче шигырьләремне Нил абыйга ияреп яздым. Ул мәктәптә уку елларында шигырьләр дә, пьесалар да, хикәяләр дә язды. «Мунча вакыйгасы» исемле пьесасын авыл сәхнәсендә куеп, үзләре уйнадылар.

1943 елда Яңавыл районы газетасында «Бертуган Нил һәм Илдар Юзеевлар иҗаты» дигән әдәби бит чыгардылар. Анда «Дошман җиңелә» дигән минем шигырем дә басылган иде.

Бервакыт, үзеннән сорамыйча, тау шуарга Нил абыйның чаңгыларын алып киттем дә, шуганда егылып, сындырып кайттым. Ул мине абыйларча гына кыйнады, ә мин иркә энеләрчә акырып еладым. Нил абый, тәнкыйтьче булып киткәч тә, киткәнче дә, йомшак әйбер язсам, кыйный, ә мин үпкәләп китә идем. Ә үзем, хаклы икәнен белеп, ул әйткәнчә төзәтә идем.

Үзем тәнкыйтьне бик үк яратмасам да (бигрәк тә хаксыз булса), тәнкыйтьче Нил абыйны сагынып, юксынып искә алам.

*— Милләтебезгә, әдәбиятыбызга ике олуг шәхес биргән Ата белән Ананы зурлап, кадер-хөрмәт белән искә алмау мөмкин түгел. Ягез бер дога!*

— Әти-әниебезнең мәңгелек йокыга талган урыннары туган ягыбызда — Яңавыл районының Ямады авылында. Туфраклары өстенә мәрмәр таш куйдык. Әнкәйнең үз шигыреннән ике юл яздырдык: «Сау булыгыз, туган-үскән кырлар, Тыныч тормыш сезгә бездән соң...»

*— Илдар абый, коеп куйган шагыйрь булу өстенә син менә дигән драматург та бит әле. Соңгы вакытларда кызыклы, мавыктыргыч истәлек-язмаларың белән дә Галиҗәнап Әдәбият сөючеләрне сөендереп торасың. Алга таба безне нинди әсәрләр белән куандырырга уйлыйсың?*

— Икенче сыйныфта укыганда ук «Алсу гөлләр» исемле «пьеса» яздым. Аны үзебезнең урам малайларына уйнап күрсәттек тә. Ул чагында кем уйласын уеннан уймак чыгар дип? Соңрак төрле формадагы поэмалар иҗат итү мине драматургиягә китерде. Дөресен әйтим, драма жанры миңа бик авыр бирелә. Мөгаен, шигырь комачаулыйдыр. Киресенчә, драматик моментлар шигъри әсәрләрне баета. Кайбер драматик әсәрләрне мин уку өчен язам. «Гашыйклар тавы»н мин сәхнәдә күрермен дип

уйламаган идем. Ә Чаллы яшьләр театрында режиссер Фаил Ибраһимов, әсәрнең бер хәрефен дә үзгәртмичә, спектакль иҗат иткән.

«Рәсемнәрдә калган еллар»ны мин үзе бер китапка әверелер дип уема да китермәдем. «Идел» журналы «Тагын! Тагын!» дип сорап котыртып торды. Хәзер инде үзем дә туктый алмыйм.

*— Илдар абый, синең шигырь-поэмаларыңда, пьесаларыңда мәхәббәт төп урын алып тора, бу тормыш-яшәештә дә шулаймы?*

— Мәхәббәт турындагы уйлануларымны мин «Мәхәббәт китабы»нда — поэмалар циклында әйткән идем инде. Дөрес, минем әсәрләремдә мәхәббәт төп урынны алып тора. Кашки тормышта да шулай булсачы!

*— Илдар абый, син гармунны менә дигән итеп уйныйсың. Без белмәгән тагын нинди һөнәр-мавыгуларың бар?*

— Шигырь язу, пьесалар иҗат итү, гармунда уйнау... Бер кешегә шулар да җитеп тормас микән? Минем, кызганычка каршы, башка һөнәрләрем юк. Булса, алар шигырьләремдә күренмичә калмас иде. Үзем булдыра алмаган һөнәрләрне башкаларда күреп сокланам. Институтта миңа укытучы дипломы биреп чыгарсалар да, мин педагог булмадым. Аның өчен аерым талантка ия булу кирәк дип уйлыйм. Мавыгулармы? Бар инде алар. Бу сүзләрне язар алдыннан, бакчамда карлыган җыя идем. Бик яраткан шөгылем. Мин аны шигырь язган кебек җыям: бөртекләп, чистартып. Ләбиб Айтуганов белән язылган иң беренче җырым юкка гына «Карлыганым, бөрлегәнем» булмагандыр?!

*— Шигърияткә, гомумән, әдәбиятның киләчәген ничек күзаллыйсың?*

— Менә алтмыш ел инде мин туган телемдә язам. Укучыларымны 50 нче елларда, бигрәк тә «Таныш моңнар» поэмасын язгач таптым дип саныйм. Кайбер укучыларымның шигырь-җырларымны, мине югалтмыйча калулары өчен сөенәм. Чиксез зур авырлыклар кичеп, бүгенге көнгә исән-сау килеп җиткән телебез киләчәктә сакланырмы-юкмы дигән уй шигырь язучы балаларга якынайта. Туган телнең нигезе татар мәктәбендә. Бөтен гомерем буе мин мәктәпләрдә яшь талантлар эзләдем. Әле дә эзлим, табам. Сөенечкә, Шигырьгә килергә омтылучы балаларыбыз күп. Иншалла, әдәбиятыбызның тамыры корымас!

*27 июнь, 2002*

**РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛА**

# Шигырь ялкыны

Таңнар сызылып калыр,
Җаннар өзелеп калыр,
Без китәрбез әкрен, тын гына.

*И.Юзеев*

Һава зыңлап торган кышкы салкыннарны хәзер искә төшереп сөйләргә генә калды, ахры. Илдар Юзи турындагы истәлекләремне мин менә авылда гыйнвар аенда язып утырам. Тәрәзә алма бакчасына карый, арырак әтәй утырткан тирәкләр каймалаган инеш... Өй кыегыннан тамчылар тама, тирәк бөреләре бүртенгән.

Ә 1979 елга кергәндә, салкынлык илле градуска җиткән иде. Гыйнвар башында җелеккә төшәрлек суык булды, ә мин — җүләр баш! — Казанга чыгып киттем. Илдар Юзинең хаты җылы өйдән кузгатты мине. Язучылар берлегендә шигырьләремне тикшерер өчен семинар үткәрелә икән.

Хәйран кеше җыелган иде Бауман урамындагы унтугызынчы йортка. Ниндидер бер малайның шигырьләрен тыңларга хәзер шулай күбәүләп килерләр микән? Хәер, ул заманнарда язучылар бүтән сорттан иделәр шикелле.

Бүген шулай тоела.

Бәлки, без дә яшьләргә башкачарак күренәбездер.

— Чуаштан ук чакырмасаң бу суыкта, — диде Илдар Юзигә Гариф Ахунов (ул Берлек рәисе), — туңдырып үтерәсең бит егетне.

— Шигырь ялкыны туңдырмый, — дип, ирен чите белән генә елмайды шагыйрь.

Ул монда яшьләр белән эшләү бүлегенең башлыгы икән. Читләргә тәэсир итсен өченме, аңа Язучылар берлеге рәисенең урынбасары дигән статус та биргәннәр. Илдар абый эштән киткәч, бу пост! ничектер үзеннән-үзе юкка чыкты.

Минемчә, Илдар Юзи мондый терәүләргә, кашагаларга мохтаҗ түгел иде, әлбәттә.

Ул — шагыйрь.

Күпләр өчен могҗизаи көчкә ия иде әлеге исем.

Киштәмдәге «Соңгы сынау» дигән тышы төшкән юка гына китапчыкны хәтерлим. Поэма. Авыл китапханәсеннән үзләштергәнмендер инде. Мусаның батырлыгы биредә яңа ягы белән ачылып китә. Ул легендага күчкән таш сын гына түгел, ә нервылар йомарламыннан торган тере җан — икеләнә, тәшвишләнә, нәфрәтләнә, ярата. Мефистофель исемен беренче тапкыр шул поэмадан укып белдем.

Аның төрле кыяфәтләре белән очрашу көннәрем алда иде.

Илдар абый кебек әдәби алмаш турында борчылучы, һәрдаим ярдәмгә әзер торучы шагыйрьләр күп түгел. Туфаннар, Хәкимнәр, Арсланнар шундый иде. Ә бит борын заманда һәрбер зур шагыйрь үзенә бер мәктәп булдырырга теләгән, аның шәкертләре булган. Үзеңнән соң килгән яшьләрнең сиңа олылап Остаз! дип эндәшүе иҗат әһеле өчен шул зур бәхет түгелме соң?

Әлбәттә, һәр шагыйрь әдәбият чытырманлыкларында үз сукмагын салырга тырыша. Колагын йон басканнар гына һәр сандугач та бертөсле сайрый дип уйлый. Шәкертлек эпигонлык дигән сүз түгел. Үзеңнән алда килгән шагыйрьнең үзенчәлекле алымнарыннан файдалану турында сүз бармый. Хәлбуки юл башында бу котылгысыз нәрсә.

Илдар Юзинең унтугыз яшьтә язган бер шигыреннән:

Карлар ява,
Юк ла,
Җир өстенә
Шомырт чәчәкләре түгелә.
Әллә нигә бүген бар нәрсә дә
Миңа матур булып күренә.

Кемне хәтерләтә?

«Бу тавышта Такташ авазы да тоемлана» — Хәсән Туфан яшь каләмдәшенә шулай бәя биргән.

Әлеге бәяне әдәбият белгечләре мәкаләдән мәкаләгә күчерделәр. Югыйсә яшьлегендә Такташка табынмаган татар шагыйре булды микән элек?

Ләкин бүтән шагыйрьнең авазы белән җырлау зурлык түгел.

Күпмедер вакыттан соң Илдар Юзи дә Такташ йогынтысыннан котыла.

Остазлыкны мин киңрәк мәгънәдә аңлыйм. Өлкән фикердәш, аркадаш...

Яшәеше, гамәлләре белән сиңа үрнәк булырлык кеше... дип яздым да, Илдар абыйның тавышы колагымда яңгырагандай булды: «Үрнәк түгел, миннән була бары гыйбрәт алып...»

Билгеле, гомеренең күп өлешен Илдар Юзи чын совет шагыйре булып уздырды. Ул гынамы...

Коммунистик идеология тегерменэнә су койган шигырьләрне Октябрь инкыйлабыннан соң мәйдан тоткан һәр татар шагыйрендә диярлек табып була.

Рәсми шигарьләр бит дөрес иде!

Тигезлек! Туганлык! Гаделлек!

Бүген авыр, ләкин зарланма, килер көннәр матур булыр! Ил гаме белән яшәргә кирәк!

Шагыйранә күңелләр дә шуны теләмимени: «Үзең турында уйлама, илең турында уйла!»

Бер уйласаң, без — совет халкы! — һәр басма сүзгә, партия мөнбәрләреннән яңгыраган телмәрләргә ышанучы зомби хәлендә идек.

Ә шагыйрьләр — Хыял дөньясының илчеләре... ярлыклары — Өмет.

Бүген безнең кулдан шул ярлыкны тартып алдылар.

Шуңа да ул чакта совет шагыйре булу табигый иде.

Сарык тиресе ябынган бүрене танып алырга шагыйрьлек сәләте генә җитмидер...

Әллә, таныйсалар да, исән-имин калыр өчен тел яшерүне кулай күрделәрме?

Без аларны хөкем итә алмыйбыз. Һәр сандугач үз ботагында сайрый. Намуслы шагыйрьләр, соң булса да, ялган сүз өчен үз-үзләрен хөкем итә.

Илдар Юзи 1953 елда Сталин үлеменә карата язган шигырен искә төшерә: «Аның рәсемен хәзер, үкси-үкси, Кара тасма белән үрәмен».

Һәм бүгенге аяусыз нәтиҗә:

Башкалардан аерылмадым,
Башкалардан калмадым,
Коточкыч тиран икәнен
Соң булса да аңладым.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Акланма, шагыйрь, патшага
Баш ию — оят, гарьлек.
Шигырь язу гына җитми, —
Шагыйрьлек — пәйгамбәрлек.

Бу юлларны язу шагыйрьгә җиңел булмагандыр. Кайчагында гап-гади хакыйкатьне аңлар өчен дә озын гомер үтәргә кирәк.

Аңламыйча китеп барганнар күпме!

Илдар Юзи — шигъриятне чын-чынлап хәятының асылы иткән шагыйрьләрдән. Шигырь аның өчен корал түгел, ул үзе шигырь коралы. Илленче-алтмышынчы еллар шигъриятнең дәрәҗәле чагы. Шагыйрь сүзе үтемле. Шигырь тәмен белүчеләр әле күп. «Таныш моңнар» поэмасы бөтен татар дөньясына яңгырый. Чын шагыйрьнең кендеге халык белән тоташкан була: шушы наив, самими, саф хиссият белән тулы әсәр коры тезмәләрдән, штыклы шигырьләрдән алҗыган татар кешесенең иң нечкә күңел кылларына кагыла.

Шагыйрьнең ул еллардагы халык тормышына тәэсирен шуннан аныклап була: күпләр яңа туган кыз балаларына Резидә, Миләүшә исемнәрен кушалар.

Бу җәһәттән Илдар Юзине ул еллардагы иң халыкчан шагыйрь дип атап буладыр. Аның белән янәшә Гамил Афзал, Әнгам Атнабай гына тора, мөгаен.

Аңа хөкүмәтнең халык шагыйре дигән исем бирүе шушы халыкчанлыкны раслау гына иде, әлбәттә. Андый исем указ белән бирелми.

Указлы шагыйрь булганчы,
Указлы мулла булсам,
Бәлки, деннән язмас идем,
Гел изге юлда булсам.

Шагыйрьләрне рәсми иерархия кануннарына буйсындыру белән ул килешә алмый иде, билгеле. Шагыйрьнең бәясен намусы һәм шул намуска тәңгәл шигърияте генә билгели.

Хәер, бу сүз кулланылыштан төшеп бара бугай. Без аны авыз тутырып әйтергә кыенсынабыз да шикелле.

Илдар Юзи — чын татар баласы. Аның өлкән каләмдәшләренә мөнәсәбәте дә элекке татарныкы иде. Туфанга, Хәкимгә мөкиббәнлек. Мондый самимилеккә мыек астыннан елмаючылар да табылды. Янәсе, Хәсән Туфан үлем түшәгендә Илдар Юзигә һәм тагын кемнәргәдер: «Егетләр, мин сездән разыймын», — дигән дә, болар моңа зур мәгънә салганнар:

Юк, җиңел түгел ул изге зат —
Шагыйрьдән фатиха алулар.
Тагын да авыррак Туфанның
Өметен акларга калулар.

Чыннан да бераз балаларча яңгырый бит...

Шагыйрьлек — балачак дөньясыннан аерыла алмаудадыр.

Сибгат Хәкимгә багышланган шигырендә исә:

Киттек, Сибгат абый,
Син — командир,
Мин дә бүген синең взводта.

Әлеге өлкән шагыйрьләрне ул Ата дәрәҗәсендә күрә. Әллә бу сугыш елларына тап булган балачак шаукымымы?

Өлкәннәр культы аңа гомеренең соңгы елларына кадәр хас булды кебек. Абыйсы — әдәбият галиме Нил Юзиевнең йогынтысында үсүе, шуның эзеннән әдәбиятка килүе дә роль уйнагандыр. Энекәшлек холкы үтми. Абыйсының үлеме аңа якын туганын югалту гына түгел, тормышының бер мәгънәсен җую да иде. Ләис Зөлкарнәйгә багышланган шигырендә әнә нинди сабыйлык гаҗизлеге сизелә:

Үзебез дә сизми калдык, энем,
Тормыш руле безнең кулларда.
Барулары бик үк җиңел булмас
Абыйларсыз калган юлларда.

Бу юлларны язганда шагыйрьгә 64 яшь...

Мөгаен, шәкерт була белгән кеше генә остазга әверелә аладыр.

Илдар Юзинең Язучылар берлегендәге шактый ук кысан кабинетын күпләр хәтерлидер әле. Хәер, әлеге «киң күңелле» бүлмәне анықы гына дию дөрес булмас, анда берничә хезмәткәрнең өстәле урнашкан иде. Ул һәрвакыт кеше белән тулган булыр — арада йомышлысы да бар, үткән-сүткәндә кагылучылар да байтак. Көр тавышлар яңгырап тора, ара-тирә шаркылдап көләләр. Бу кадәр халык арасында Илдар Юзине тиз генә искәреп тә булмый төсле, әмма беренче карашка гына шулай, бераздан сизәсең: ул һәрвакыт үзәктә. Үзе күп сөйләшми, көтмәгәндә әңгәмәгә хикмәтле тәгъбирен кыстырып куя да күзлеген күтәреп өстәлдәге кулъязмага иелә... бөтенләй өстәл белән кушылып бетә сыман. Башлап язучылардан олау-олау кулъязмалар килсә дә, өстәле гадәттә буш була иде аның. Калын-калын папкалар янәшәдәге шкаф тартмаларына тутырылган. Шушы пәри туенда ничек укып өлгерә алды икән ул аларны?

Бераздан әһле каләм бильярд уйнарга чыгып китә. Кайсысы шар тәгәрәтә башлый, кайсысы стенаны тоташтан каплап алган «Тынгысыз каләм» гәҗитен укып рәхәт чигә. Бердәнбер нөсхәдәге иң популяр гәҗит шул булгандыр әле Татарстанда! Аны укырга дип бөтенләй күзгә-башка күренмәгән кемсәләр дә Язучылар берлегенә сугылып чыга иде.

«Мин күп өстәлле кысан бер бүлмәгә килеп эләктем. Бер почмакта мине әдәбиятка җитәкләп алып кергән кеше — Илдар Юзеев утыра», — дип искә ала Миргазиян Юныс.

Ул үзе остазыннан шактый өлкән. Әдәбиятта биологик яшьнең әһәмияте юк.

Илдар Юзи үзеннән өлкәннәрне дә, үзеннән күпкә яшьрәкләрне дә җитәкләде. Без барыбыз да «башлап язучылар», «өметле каләм ияләре» идек.

Аның диварына Татарстан картасы эленгән. Әлеге карта янында ул үзен, бәлки, яу башы — полководец! итеп сизгәндер. Кайсыдыр тикшеренүчеләр ачыклаганча, тамырларда морзалар каны! Юзи, Юзикәй — бик борынгы исем. Чыңгыз ханның атасы Ясүкәйне искә төшерегез.

Башка чорда булсамы? Башка тарихи шартларда...

Карта зоналарга бүленгән. Төгәл бер аралык саен һәр зонада (берәр район үзәгендә) иҗат семинарлары уздырыла. Бу эшкә зурлап тотыналар — партиянең өлкә комитеты исеменнән. Зонага кергән районнарда яшәүче каләм тибрәтүчеләр чакырыла, аларның язганнарын тәҗрибәле шагыйрьләр тикшерә. Язучылар берлегенә әгъзалыкка тәкъдим итәргә дип Казаннан берничә «өметле каләм»не дә ияртеп киләләр.

Һәркем белә: «зоналар»дан әдәбиятка шагыйрь чыга алмый. Чыкканы инде аның үз хуты белән Казанга килгән була.

Илдар Юзинең дәфтәрендәге исемлектә җиде йөзгә якын «яшь язучы» теркәлгән, дип сөйлиләр иде. Ул бу санны язучыларның ниндидер бер корылтаенда үзе дә атады бугай. Көлүчеләр булды — шулкадәр санда язучы буламыни, янәсе.

Нигә булмасын?! Халкыбыз, Аллага шөкер, яза белә. Укый белүчеләр генә аз...

Илдар Юзинең әлеге семинарларны үткәргәндә төп максаты шул укучылар даирәсен киңәйтү иде булса кирәк. Үзе язган кеше аз гына бүтәннәрне дә укырга тиеш ләбаса!

Чыннан да, ул елларда татар газета-журналларының тиражлары бик нык артты. Әлбәттә, моны Илдар Юзинең эшчәнлегенә генә бәйләүдән мин ерак торам. Әмма әдәби сүзне халыкка тарату эшендә шагыйрь йөрәк утын кызганмады. Әдәбият хадиме дигәндә мин гел аны — сөрән салмыйча гына, күкрәк төймичә генә эшләп йөргән гади хезмәткәрне! — күз алдына китерәм. Әлбәттә, ул бу тын көрәштә ялгызы гына түгел, ләкин яубашы итеп барысы да нәкъ менә аны санныйлар иде шикелле.

Илдар Юзине җирләп кайтканда, бер дусты:

— Аның бу яшькә җитүенә гаҗәпләнерлек, — диде. — Ул бит мин беләбелгәннән бирле гел авырып, сырхаулап яшәде. Ә мин аны студент чактан ук беләм.

Үзе әйтмешли, «өндәүдән сорау билгесенә әверелгәндә дә», күкрәгендә дөрләгән шигырь ялкыны тәкъдире сызган юлдан алга әйдәгәндер шагыйрьне. Ул тормышта бик тыныч, басынкы, артык тыйнак күренсә дә, иҗатында әлеге ялкынның көчен без яхшы тоябыз.

Өтеп ала торган кайнарлык.

Кайбер мәсьәләләрдә эндәшми калса да, — бик сак кеше иде (хикмәт ияләренә хас сыйфат, диләр), — шигърияткә кыек сүз тидерүчеләргә ул аяусыз булды.

Шигърияткә хыянәт итүчеләрне кичермәде.

Әмма тормышта шагыйрьләр һәрвакыт җиңелә.

Шигырь язуны көнлекче хезмәтенә тиңләштергән кешеләрнең алгы сафларга чыгуына, әдәбият лидерлары булып йөрүенә йөрәге әрнегәннән бу юллар:

Моңнан, җырдан бары табыш кына
Көтүчеләр күчте һөҗүмгә.
Тукай исеме белән дәшәм сиңа:
Шигырь җаным, зинһар, чигенмә!

Шигърияткә мондый гаҗиз мәхәббәтне бик сирәк шагыйрьләрдә генә күрергә мөмкин.

**ҖӘҮДӘТ СӨЛӘЙМАН**

# Яшьлек җырчысы

Сандугач киткән күңелгә
Кунаклап сайрыйсы бар.
Дошман йөрәген тишәрлек
Хәнҗәр-сүз сайлыйсы бар.

Юлда адашып калганга
Маяклар тезәсе бар.
Үзеңне адаштырсалар,
Бирешми түзәсе бар.

Халык кайгырганда — елый,
Көлгәндә — көләсе бар.
Ил булып утка керәсе,
Ир булып үләсе бар.

Татарстан Республикасының халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге, М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының, Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе Илдар Юзеев иҗатыннан алынган бу шигъри юллар авторның гражданин буларак та, шагыйрь буларак та фани дөньяда toткан кыйбласын, тормышының максатын, яшәешенең мәгънәсен бик ачык күрсәтә. Моны мәшһүр шагыйрьнең шигырендәге изге анты итеп тә кабул итәргә була. Шунысы хак: автор аңа гомере буена тугры калды.

И.Юзеевның иҗаты татар халкының рухи тормышында үзе бер чорны колачлый. Ул шагыйрь дигән олуг исемне аклап яшәр өчен нинди җаваплылык йөкләнгәнен, Шигърият дигән зур йөкне күтәреп бару өчен күпме көч-кодрәт кирәклеген бөтен күңеле белән аңлап яшәде:

Юк, җиңел түгел ул изге зат —
Шагыйрьдән фатиха алулар.
Тагын да авыррак Туфанның
Өметен аклауга калулар.

Илдар Юзеевның меңнәрчә шигырь сөючеләрне сөендереп торган иҗатына бөек Туфанның да рухы шат булгандыр. Аның әсәрләрендә югары идеялелек, саллы фикер, җитди фәлсәфә ярылып ята. Ул аларны тирән образларга, шигъри аһәң, музыкаль ритмга төреп бирә. Нәтиҗәдә искиткеч камиллеккә, гаҗәеп гармониягә ирешә. Заманында Хәсән Туфан үзе дә, Илдар Юзеев иҗатына бәя биреп, болай дип әйткән иде: «Минемчә, Илдар Юзеев — без яшәгән заманның көен, аһәңен тапкан шагыйрь. Бу җәһәттән ул халыкчанлыгы, ихласлыгы, моңы белән әсир иткән Илһам Шакировка бик якын».

Аның әдәби таланты, шигъри сүзенең көч-куәте аеруча поэмаларында чагыла. И.Юзеев — ике дистәләп поэма авторы. Аның әсәрләренең сүлен югары гражданлык пафосы, ил язмышын, халык язмышын кайгыртып яну, патриотик хис тәшкил итә.

Алтмышынчы еллардан башлап И.Юзеев драматургиядә актив эшли башлый. Ул — танылган драматургларның берсе, комедия, драма, трагедия жанрларында ике дистәгә якын әсәр тудырган, сәхнәгә шигъри рух, шигъри моң алып менгән. Ул үзенең пьесаларында замандашларыбызның якты омтылышларын, кеше рухының матурлыгын күрсәтә, тамашачыга үзенең романтик хисләрен ирештерә.

Туксанынчы елларда иҗаты заманның, вазгыятьнең үзгәрүенә бәйле рәвештә үзенең уйланулары, кичерешләре, фәлсәфи фикерләре ягыннан тагы да тирәнәеп, яңа яссылыкка күчсә дә, Илдар Юзеев күпләрнең күңелендә беренче чиратта Яшьлек шагыйре булып калды. Аның иҗаты яшьлекнең үзе кебек мәхәббәт, матурлык, өмет белән сугарылган. Аның шигырьләре яшьлекнең үзе кебек кайнар ярсулы, дәртле һәм самими.

**ШАМИЛ МАННАПОВ**

# Җиргә кайткан пәйгамбәрдәй

*Илдар Юзеевка*

...Үз илендә рәсүлгә дә
Булмаган, дип, хөрмәт,
Ул офыкка карап китте
Бәхет кошын эзләп.

Алсу рәшәгә алданып
Барды да ул барды.
Барган саен рәшә күчте,
Офык ерагайды.

Күп алданды, бәхет кошын
Инде тоттым, диеп.
Көлде язмыш:
Күгәрчен дип,
Аңа козгын биреп.

Аргач-талгач, бу мосафир
Хәтерләде тагын
Алданмас вә алыштырмас
Туган җире барын...

Мигъраҗ кылып*,
Җиргә кайткан
Пәйгамбәрдәй, ул да
Туган төбәгенә карап,
Чыкты кайтыр юлга.

Каршылады туган авылы,
Газиз анасыдай, —
Күзләрендә офык нуры
Балкып яна сыман.

Кәрниздәге күгәрченнәр:
Гөлдер-гөлдер-гөлдер.
Бәхет кошлары, ахрысы,
Шулар үзләредер.

Газизләреннән айрылып,
Ничек китәр инде... —
Көтә аны рәсүл иткән,
Гомер кичкән җире...

**МӨХӘММӘТ МИРЗА**

# Аның двойнигы юк

Илдар Юзеев татар кешесенең җанына турыдан-туры юл таба алган олуг шагыйребез иде. Ул ярты гасыр буе бөтен бер халыкны үзенә каратып, моңландырып, җырлатып яшәде... Үз эшенең остасы, дистәләрчә каләм ияләренең остазы булды. Әдип бигрәк тә яшьләргә, балаларга игътибарлы иде. Илдар абый, күрәсең, балалар өчен нәшер ителгән барлык китапларны, газета-журналларны даими күзәтеп баргандыр. Шулай булмаганда, бөтен республикада, республикада гына түгел, ә читтәге өлкәләрдә яшәп иҗат итүчеләрне дә барлап тора алмас иде. «Ялкын», «Салават күпере», «Сабантуй»да беренче чыныгуларын алган иҗатчылар Илдар абый йогынтысына юлыксалар, киләчәктә чын-чынлап язучы, журналист йә булмаса татар теле белгече булып китәләр. Ни гаҗәп, Илдар абый үзенең яшь иҗатчы дусларын алар Казанга килгәч кенә түгел, ә авыл-районнарда вакытта ук таба, аларга үзенең җылы кулын суза иде.

Минем үземә дә балачактан ук шигырь җене кагылгандыр. Әмма минем үсмер чакта язганнарым тупланган ике калын дәфтәремне әлегәчә беркемгә дә күрсәткәнем юк... Моннан нәкъ 20 ел элек, 1987 елны, инде ир уртасы булгач язганнарымны бер җыентык итеп туплап, шагыйрь Рөстәм Мингалимгә бирдем... Ул үз чиратында Илдар Юзеевка, Мөдәррис Әгъләмовка күрсәткән... Шул чагында Илдар абыйның: «Мирза, син үзеңне шагыйрь буларак кыска шигырьләрдә тапкансың, үз каләмең, үз шигъриятең бар», — дип, алдагы иҗатыма фатихасын биргән иде... Озак та үтмәде, ул җыентыгым басылып та чыкты. Язучылар берлегенә кабул ителү өчен дә миңа юлламаны алар — Илдар Юзеев, Рөстәм Мингалим, Мөдәррис Әгъләмов, Ризван Хәмид бирделәр. Идарә утырышында М.Әгъләмов белән И.Юзеев чыгыш та ясадылар...

Ни кызганыч, халкыбызның иң сөекле шагыйрьләре Илдар Юзеев, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт бу якты дөньядан бер-бер артлы китеп тә бардылар. Аларның олуг иҗатлары, игелекле гамәлләре һәм алар турында төрледән төрле истәлекле вакыйгалар калды. Әйткәнемчә, алар остазлар иде! Язучылар берлеге каршында «Яшь язучылар клубы» оештырылгач, яшьләр беравыздан «Яшь язучылар клубы» Илдар Юзеев исемен йөртсен иде» дигән теләк белдерделәр. Бик тә гадел һәм лаек!.. Рәхмәт яшьләребезгә! Ул нәкъ шулай булыр да...

Илдар абый гаҗәп дәрәҗәдә юморга бай шәхес иде... Инде аның экспромт рәвешендә эпиграммалар язуын, берсеннән-берсе кызыклы рифма үрнәкләре табуын язучы-шагыйрьләр генә түгел, ә аның иҗатына мөкиббән булган артистлар да бер соклану белән искә алып сөйлиләр.

Юзи юморы! Кешенең шәхесен кимсетми торган, әмма үз вакытында иң кирәкле сүзе табылган рифма, чагыштыру, афоризм ул.

...Шулай берчак, ялгышмасам, 1990 елның июль азакларында булса кирәк, Уфадан кайтып барышлый кичкырын, юл уңае дип тә, мине күреп чыгыйк дип тә, алар — Илдар Юзеев, Ризван Хәмид һәм Рөстәм Мингалим — Актанышка килеп төштеләр...

Төнозын хәлдән килгәнчә кунак булып, сөйләшеп утырдык... Аңлашыла ки, сүз милли әдәбият, милли сәнгать турында гына түгел, ә республикабызның киләчәге, мөстәкыйльлеге һ.б. турында барды. Сәяси мәсьәләләрдә, әлбәттә, шул чорда тарих белән чын-чынлап кызыксынган, тарихи пьесалар, очерклар язган Ризван Хәмид бер генә минутка да тынып тормады... Ул сөйләгәннәр миңа гына түгел, хәтта Илдар Юзеев белән Рөстәм Мингалимгә дә яңалык иде булса кирәк. Әмма тегеләре аңа бөтенләй үк мөкиббән дә китмәделәр, ул сөйләгәннәргә битарафлык та күрсәтмәделәр. Төн уртасы җиткәндә, иртәгесен кояш белән торып, Агыйдел буена ял итәргә барырга тәгаенләп йокларга яттык...

Иртәгесе көн бик матур туды. Кояш чыгуга безнең өйнең капка турысына район милиция бүлегенең «буханка» «уазигы» килеп туктады. Алдан сөйләшеп куйганча, Татар Суксуы авылыннан минем дустым шагыйрь Фәнәвис Дәүләтбаев та килеп җитте... Бар кирәк-яракны алып, Агыйделнең Доха күле белән тоташкан ярымутрау булып торган төшенә килеп урнаштык.

Җәйнең нәкъ уртасы. Әрәмәнең мулдан мул чагы. Кара карлыган тулып пешкән, бөрлегән җитеп килә... Кунаклар өс киемнәрен салып алдылар да, Агыйделгә, Доха күленә, әрәмәнең мең төрле сурәтенә, кошлар сайравына хәйран калдылар...

— Шә-әп! — диде Илдар Юзи, Агыйдел ярына басып, тын Агыйделгә сыйган бөтен күкне күзәтеп...

— Гаҗәп бит бу, гаҗәп! — ди Рөстәм Мингалим, Агыйделгә кереп. Ул кул-битләрен чылатты да күптәннән көткән морадына ирешкән хислелек белән тагы да: — Гаҗәп! — диде.

Фәнәвис белән мин учак тергезеп җибәрәбез. Мин әле генә ау-җәймәдән алган сыла, опты, чөгә балыкларыннан уха әзерли башлыйм. Фәнәвис яшь бәрән ите белән яшь бәрәңгене томалап пешерү хәстәренә керешә.

— Гаҗәп бит бу! — ди Рөстәм Мингалим, учак төтененә уралып.

— Шә-әп! — ди Илдар абый, монда бер сүз дә кирәкми, монданиләр генә әйтсәң дә аз диган мәгънә белән.

Ризван Хәмид кенә кичәге сөйләгәннәрдән һич кенә аерыла алмый. Ул Актаныштан Агыйдел ярына кадәр арада да Октябрь революциясенең бөтенләй котылгысыз булмаганлыгын өр-яңа мисаллар белән дәлилләп сөйләп килгән иде. Инде Агыйдел ярында чишенеп аткач, патшаларны, юлбашчыларны сүтеп җыя башлады:

— Аларның һәрберсенең двойниклары булган. Ленинның двойнигы иң гыйбрәтлесе, — дип кызып-кызып сөйләп китте ул, аның белән кемдер бәхәскә керәчәген тоемлап. — Ул, — ди Ризван Ленинның двойнигы турында, — үлеп барган Ленинны терелтә, татарча сөйләштереп тәүбә иттерә... Ленин, үләр алдыннан савыгып, үзе яткан йортның ишегалдына чыгып: «Алла, Алла», — дип, татарчалап Аллаһыдан ярлыкау сораган. Шуннан соң гына Ходай аңа үләргә рөхсәт биргән, газаплардан коткарган, диюем. Бүген ник Рәсәй хәерче, вәхши һәм эчкече? Чөнки җирләнмәгән мәет бар... Аны җирләмичә торып илгә ип килмәс, — диде.

Ризван Хәмидне туктатып булмый иде. Ул «дәлилләр китерә-китерә» Ленинны, партияне сүкте.

Җаны-тәне белән Ленин идеяләренә бирелгән Фәнәвис Дәүләтбаев аның бу гаепләү сүзләренә ризасызлыгын әйтмичә түзеп кала алды әле... Әмма Ризван Хәмид Сталин һәм аның двойниклары турында сүз башлагач, ул аңа ачыктан-ачык каршы сүзләр әйтте... Аның да дәлилләре берсеннән-берсе көчле һәм инкарь итмәслек иде.

— Шәп бит! — дип, инде ничәнче кат кабатлый Илдар Юзи.

— Гаҗәп бит бу! — ди Рөстәм Мингалим. Табигатьнең бөтен матурлыгын, Агыйделне, әрәмәле учакның төтененең төсен, уханың кабатланмас исе-тәмен, яшь бәрән ите белән яшь бәрәңгене дә, карлыганлы болын чәен дә мактаулары иде шагыйрьләрнең.

— Фани дөнья гел ялганнан гына торса да, барыбер матур, гаҗәп бит! — дип куя Рөстәм Мингалим. — Монда каласы түгел... Ә барыбер яшәү гаҗәп! Килү-китү гаҗәп!..

— Шәп! — диде тагы да Илдар абый.

Сүз яңадан параллель дөнья һәм яшәү рәвеше турында куерды. Монда да Ризван Хәмиднең гыйбрәтле өр-яңа дәлилләре бик күп иде... һәм без барыбыз да аны тыңлаучыларга әйләндек...

Инде шактый утырылды. Шигырьләр укылды... Җырлап-көйләп алдык. Учак янын бик пөхтәләп җыештырдылар кунаклар.

«Уазик»ка төялеп, болын юлыннан Актанышка таба кузгалдык... Шунда көтмәгәндә әрәмәлектән берничә эт килеп чыкмасынмы! Шуларның берсе безнең автобусны өнәп бетермәдеме, ярсып өрә-өрә, машинага терәлеп үк ияреп чаба башлады.

— Гаҗәп бит, безнең аңа нинди зыян тиде?.. Нигә өрә инде бу балакай, машинага тапталмаса ярый инде сабый?! — диде Рөстәм Мингалим.

Шунда көтелмәгән хәл булды. Көнозын «Шәп бит!» сүзеннән гайре бер кәлимә сүз әйтмәгән Илдар Юзи бер җөмлә әйтте:

— Нинди бала булсын ул сиңа? Ул Ыгыйзванның двойнигы, Ыгыйзванны тәүбә иттегегә килгән! — диде.

Һәм без барыбыз да эчләребезне тотып кычкырып көләргә тотындык. Безнең шулай кинәттән дәррәү кычкырып көлүебездән эт курыкты, ахры. Ул кинәт кенә читкә ыргылды һәм, борылып, койрыгын гәүдәсенә кысып кирегә йөгерде.

Илдар Юзи юморы! Үзе әйткәнчә, «Шәп бит!» Мингалим әйткәнчә, «Гаҗәп бит!»

Һәм аның тормышта да, иҗатта да, юморда да двойнигы юк!

**ШАҺИНУР МОСТАФИН**

# Изге әманәткә тугрылык

Фани дөньядан бакый дөньяга тиздән күчәсен сизепме, вафатына ике ел чамасы вакыт калгач, халкыбызның олуг шагыйре Илдар ага Юзеев безгә үзенең үтенечен язып калдырган иде. Биредә мин шул язманы бернинди үзгәртүләрсез, тулысынча китерәм:

*«Татарстан Язучылар*
*берлеге идарәсенә,*
*рәис Ф.Г.Галимуллинга*
*Илдар Юзеевтан*

*гариза.*

*Шәйхи Маннурның безгә язган васыятен үтәп, мине шагыйрьнең мирасы комиссиясе рәисе итеп билгеләгәннәр иде. Сәркатибе булып Шаһинур Мостафин эшләде. Бу вазифаны мин 22 ел алып бардым. Өлкәнәю һәм сәламәтлегем какшау сәбәпле, мин хәзергесе көндә — Ат елында җигелеп эшләүдән мәхрүм. Бу камытны миннән алып, яшь, бөтен көчен туплап Шәйхи ага мирасын алып баручы сәркатип Шаһинур Мостафинга кидерүегезне үтенәм. Ул моңа бик лаек. Үзем комиссия әгъзасы буларак эшне дәвам итәрмен.*

*(Имза)*
*10.01.2002».*

Мөхтәрәм әдибебез Илдар ага Юзеевның аңа гына хас эчкерсезлек һәм җылы юмор белән өртелгән әлеге гаризасын укыгач, күңелне сүз белән генә әйтеп бетереп булмастай тирәнтен дулкынлану хисләре биләп ала. Ничәмә-ничә дистә еллар бергә аралашкан-аңлашкан, эч серләрне уртаклашкан гаять кадерле-газиз ошбу шәхеснең үз гомерендә кылган игелекле гамәлләрен санап бетерерлек кенә түгел. Яшь әдәби көчләрне барлау-үстерү буенча үзенең гомерлек якын дусты — Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай премиясе лауреаты, Г.-Х.Андерсен исемендәге Почетлы диплом иясе, бик күпләребезнең яраткан остазы — инде сиксәненче яшен түгәрәкләп килүче Шәүкәт ага Галиев белән берлектә биниһая игелекле матур гамәлләр кылдылар алар. Олпат каләмдәшебез Шәйхи ага Маннурның үзләренә атап язган васыятьнамәсен җиренә җиткереп үтәү буенча да әлеге аерылмас дуслар-сердәшләр бик күпләргә якты үрнәк күрсәттеләр. Хәзер инде безгә, яшьрәк буын вәкилләренә, халкыбызның ихлас мәхәббәтен яулаган, шөһрәт казанган әлеге асыл затларыбызның изге әманәтләрен үтәп, алар кебек җиң сызганып, дәртләнеп-илһамланып эшлисе генә кала...

...Илдар ага белән бергәләп, үзе исән чагында, һәр ел саен диярлек без Шәйхи аганың туган төбәгенә кайтып йөрдек; үзеннән бай әдәби мирас калдырган халыкчан әдипнең якты рухына багышлап, Мамадыш төбәгендә «Кышкы Шигъри Сабантуй»лар үткәрүне матур бер гадәткә керттек; яшь әдәби көчләрне барлап, аларга юл күрсәтүне, осталыкларын үстерүне дәвам иттердек.

Илдар ага Юзеев Ат елында рәислек «камытын» безгә «кидергәч», аның 70 яшьлек юбилеен нәкъ менә Шәйхи ага Маннурның туган җирендә иң беренче булып билгеләп үтүне кирәк дип таптык. Әлбәттә, бу мөһим чара Татарстан Язучылар берлеге идарәсе белән Мамадыш районы хакимиятенең уртак килешүе нигезендә эшләнде.

Халык белән шыгрым тулы Тулбай авылы Мәдәният йортында Шәйхи ага Маннурның лаеклы варисы — юбиляр Илдар ага Юзеев турында бик күп җылы сүзләр әйтелде, бүләкләр тапшырылды. Бүләкләр дигәннән, аңа: «Аякларыгыз туңмасын, гел җылыда йөрсен!» — дип, авыл осталары баскан киез итекләр дә бүләк иттеләр. Монысына бик шатланды Илдар ага. Ә инде аңа 2003 ел өчен Ш.Маннур исемендәге премия бирелү турында карар игълан ителеп, залдагылар аягүрә басып алкышлагач, ул, гаять дулкынланып, болай диде:

— Үз гомеремдә миңа байтак бүләкләр, премияләр алырга туры килде. Ә монысы — мөхтәрәм Шәйхи агабызның якташлары тарафыннан бирелгән зур бүләк — аеруча кадерле, җанга якын! Рәхмәтем чиксез Сезгә!

Үзенә тиешле премияне алгач та, Илдар ага, авылдагы Ш.Маннур китапханәсе мөдире Гөлфия ханым Хисмәтованы сәхнә түренә чакырып, аңа акчалы конвертны тапшырды.

— Әлеге премия акчасына китапханә өчен яңа китаплар алырсыз, яме! — диде ул. — Тулбайлыларның яше-карты киләчәктә дә рухи байлыктан һич кенә дә аерылмасын!

Зал тагын көчле алкышларга күмелде...

Әдәбиятыбызның классигы Шәйхи ага Маннурның 100 еллык олуг юбилеен да Мамадыш—Тулбай—Олыяз төбәгендә бергә-бергә зурлап билгеләп үтү турында хыялланган иде Илдар ага. Ни

кызганыч, аңа әлеге тантанада катнашу мөмкинлеге насыйп булмады. Аяусыз үлем Илдар агабызны — һәркайсыбыз газиз туганыдай, үтә якын дустыдай ихластан яраткан якты күңелле кешебезне — арабыздан бик вакытсыз алып китте. 2004 елның 21 декабрендә.

Әмма без, Илдар аганың варислары, аның васыятенә ныклы тугрылык саклап, остазыбызның исән чакта телдән әйтеп калдырган мөһим сүзләрен, фикерләрен, киңәшләрен һәрчак исебездә тотабыз.

Әлеге язмамны, кадерле остазым Илдар ага Юзеевка атап, аның 70 яшьлек юбилее уңаеннан язган шигырем белән төгәллисем килә. Чөнки әлеге гаҗәеп тыйнак, кешелекле, үтә ярдәмчел шәхескә карата булган ихлас хисләрем нәкъ элеккечә — үзе исән чагындагыча.

## Сез — мәңгелек!

*Татарстанның халык шагыйре*
*Илдар Гафур улы Юзеевка*

Үзегез — гади, үзегез — гали,
Сүзегездә бар хикмәт:
Җиткерәсез һәр күңелгә
Шигырьгә салып, ипләп.
Драматург буларак та,
Сезгә кул чаба күпләр.
Илаһилык бар анда! — дип
Пышылдый хәтта күкләр.
Халкыбыз былбыллары да
Сезне ихлас ярата.
Сүзләрегез җырга күчә —
Яңгырый һәр тарафта.
Юморга — йомры сүзгә дә
Мөкиббән Сез, маһир Сез!
Кайвакытта Мәҗнүн дә Сез,
Кайвакытта Таһир Сез!
«Мәхәббәт Җырчысы!» дигән
Сүз йөри Сезнең хакта.
Бик тә дөрес! — гомер буе
Тугры Сез асыл Затка.
Ул асыл Зат — Тәфтиләдер! —
Тәтешле Зариф кызы!
Яныгызда Илһамчы ул,
Күңелегез шуңа җырлы.
Бер-берен аңлаган җаннар
Җылыта бу тормышны
Һәм нурлый да. Шуңа күрә
Һәр эшегез уңышлы.
«Таныш моңнар» озата бара
безне гомер буена...
«Сандугачлар килгән безгә»
Юбилярның туена.
«Карурман»ны кичеп чыгып,
«Гашыйклар тавы»на менеп,
«Мәхәббәт китабы»н укыдык...
Сөюебез — гомерлек.
«Өзелмәс кыллар» чыңында
Сезнең гомер дәвамы:
«Мәңгелек белән очрашу»
Булыр аның азагы.
Сез — Мәңгелек! Иҗатыгыз,
Үзегез дә үлемсез.
Туар яңа гасырларга
Гел яшь көе килерсез.

**ЛЮЦИЯ ФАРШАТОВА**

# «Таныш моңнар» өзә үзәкне...

2004 елның кояшлы, һавага алма исе, муллык-хөрлек исе таралган сентябрендә, аның хозур бер көнендә без — бер төркем иҗат кешеләре: язучылар, артистлар, журналистлар — Мамадыш якларына карап юлга чыктык. Ул көнне районда дустым, классташым, туган җиребезнең моңлы кызы Гөлнәзирә Талипованың иҗат кичәсе буласы иде. Безнең белән озын юлга, авырыбрак торса да, Илдар абый Юзеев та кузгалды. «Мондый ямьле көнне эчендә җаны булган кеше өендә ятамыни?! Аннары, юл йөрүдән ләззәт, әйбәт кешеләр белән очрашулардан яшәү көче алам бит мин, — дип аңлатты үзенең сәфәргә җыенуы сәбәбен. — Гөлнәзирәнең җырлавын да сагындым. «Мәтрүшкәләр»не, «Яшь наратлар»ны аның һәм эчкерсез дустым Миңгол Галиев башкаруында аеруча яратам мин».

Шагыйрь юл буе әле бер, әле икенче юлдашы белән сөйләшеп барды: әле мәзәк, әле язучылар, артистлар белән булган кызыклы хәлләрне сөйләп көлдерде. Ниһаять, мин дә янына утырырга җөрьәт иттем. Сөйләшер сүзләребез, истәлекләребез күп иде безнең... Шуларны искә алдык. Сүз арасында: «Илдар абый, шулар хакында бер язасы килә, Сез ни диярсез?» — дип әйтеп тә куйдым. «Мин үлгәч язарсың әле... — диде ул, ничектер үпкәләбрәк. — Истәлекләр, исәннәргә иң кирәкле, кадерле сүзләр никтер кеше бакыйга күчкәч языла, әйтелә бит ул...»

Мең кат гаеплемен, чынлап та, аның белән бәйле истәлекләрне үзе исән чакта яза алмадым. Инде ошбу язмам аның якты рухына изге догам булып ирешсен иде...

* * *

...Әдәбиятны үлеп яратучы кеше буларак мин дә, меңнәр кебек, Илдар абый Юзеев шигырьләрен, поэмаларын йотлыгып укый, ятлый һәм сәхнәләрдән сөйли идем. Шигырь яратмаучы классташларым әле дә, сәгатьләр буе шигырь сөйләп туйдырып бетерә идең, дип көлеп искә алалар. Илдар абыйның аеруча 1954–1960 елларда язылган, бер ишетүгә истә кала, җырлап тора торган «Таныш моңнар», «Фәрит-Фәридә», «Әнкәй», «Миләүшә» поэмаларын ул елларда кемнәр генә отып алып, үзалдына гына булса да сөйләп йөрмәде икән? Аның «Таныш моңнар» поэмасыннан «Резидәкәе», «Янар чәчәк» пьесасыннан «Лира җыры», «Фәүзия җыры», «Яшь наратлары», «Мәтрүшкәләр»е 1965–1975 еллар яшьләренең иң яратып җырлана торган җырлары иде.

Үзе дә каләм тибрәтә башлаган иләс-миләс күңелле кызга алар ничек тәэсир итмәсен инде? Кыюлык булгандырмы ул, җүләрлекме, сигезенче класста укыганда мин үземнең берничә шигыремне (яшь чакта кем генә шигырь язып җенләнми инде?!) Илдар абыйга җибәрдем, киңәш сорадым. Адресын белмәү сәбәпле, шигырьләремне ул вакытта үзем яратып укый торган «Татарстан яшьләре»нә юлладым, зинһарлап, хатымны Илдар Юзеевка тапшыруларын үтендем. Дулкынланып өзелеп көткәндә җавап килмәде, инде өметләнми башлагач, беркөнне хат ташучы кулыма «бәхет кошы» тоттырды. Нигәдер ул аны мәктәпкә китергән иде, хатны кулыма тәнәфестә тапшырды. Минем өчен дә, мәктәп өчен дә гаҗәеп вакыйга булды ул. Илдар Юзеевның ҮЗЕННӘН әллә кайдагы авыл мәктәбе укучысына хат килеп төшсен әле! Җитмәсә, ОСТАЗ миннән озак җавап яза алмый торуы өчен гафу үтенгән, шигырьләремне укып, киңәшләрен биргән. Җавап белән озаклавына аның Мәскәүдә әдәби курсларда укып йөрүе сәбәпче икән. Минем хатымны аңа Казанга каникулга кайтып, редакциягә кергәч тапшырганнар.

Ни кызганыч, утыз еллап сакланган ул кадерле хатлар әллә кая гына юк булды. Ташламадык шикелле, әмма таба алмыйм. Хатлар... дим, чөнки без аның белән биш ел буена, мин урау юллар аша Казанга килеп урнашканчы хат алыштык. Ә аңынчы...

Сигезенчедә, тугызынчы, унынчыда укыганда да хат язышып тордык Илдар абый белән. Яшермим, сирәгрәк. Чөнки өйрәнчек шигырьләремне аңа җибәрергә уңайсызлана идем. Ә үзем аның барлык шигырьләрен, поэмаларын диярлек ятлап бетердем.

Унынчыны тәмамлагач, безнең тирә-як авылларда ни икәнен дә белмәгән журналист булу хыялымны тормышка ашыру өчен Казанга — университетка юл тоттым. Берүзем. Әти-әни бармак башы чаклы гына кызыкайларын ничек курыкмый Казан кадәр Казанга чыгарып җибәргәннәрдер, әле дә аптырыйм. Килеп төштем «Божра»га. Кулымда кунып чыгу өчен класс җитәкчебез — әдәбият укытучыбыз Дилә апа Тимергалиевнаның туганнарының адресы һәм Илдар Юзеевның: «Документларыңны тапшырырга килгәч, мине күрми китмә», — дип язган хаты. Гагарин урамындагы йортны эзләп тапкач (хуҗалар өйдә юк иде), университетны һәм Бауман урамындагы Матбугат йортын эзләп киттем. Уку йортын тиз таптым табуын, ләкин документларымны Илдар абый белән киңәшмичә тапшырырга җөрьәт итмәдем. Курка-икеләнә Татарстан Язучылар союзына килсәм, ул кичке якта гына була,

диделәр. Вакытны уздыру өчен Кремль тирәләрен әйләнеп килдем дә Матбугат йорты янында Илдар абыйны көтә башладым.

Әнә УЛ — бөтен яшьләр табынган ШАГЫЙРЬ килә! Мин аны китапларында һәм газета-журналларда чыккан фотоларыннан танып алдым. Үзен күргәч, янына барырга курыктым, билгеле, атылып чыгарга җитешкән йөрәгемне учлап, китап кибете ишеге артына качып калдым. Бераз тынычлангач, кыюсыз гына Матбугат йортының авыр имән ишеген ачтым.

Мең рәхмәт Илдар абыйга, ул куркак куян баласыдай авыл баласын үз сеңлесе кебек каршы алды. Бүлмәдәшләренең: «Шигырь белән җүләрләнгән тагын бер Ләйлә Мәҗнүнен эзләп килде», — дип шаяртуына карамастан, минем белән бик гади, чын абыйларча сөйләште. Укырга кая керергә теләвемне белеште, университетта быел конкурсның зур булуын искәртте, әзерлегең ничек, үз-үзеңә ышанасыңмы, дип сорашты. Үзе әллә ничә мәртәбә каядыр шылтыратып карады да, их, бүген соңлаганбыз икән инде, дип сукранып алды. Без аның белән иртәгә очрашырга сүз куешып аерылыштык.

Юлыбыз иртәгесен дә уңмады. Ул очрашырга теләгән кеше ашыгып кына каядыр киткән булып чыкты. (Берничә елдан күрешкәннән соң гына белдем, очрашасы кешебез аның университетта укытучы абыйсы Нил Юзиев булган икән.) Без янә берничә сәгатьтән күрешергә килешеп аерылыштык. Ләкин мин (гаеплемен!) университет янына бүтән бармадым. Беренчедән, шундый зур кешене кат-кат борчыйсым килмәде. (И-и, беркатлылык: Илдар абыйның, юк вакытын бар итеп, мине көтеп торуы хакында уйлап та каралмаган!) Икенчедән, конкурстан барыбер узалмам дип шүрләдем һәм документларымны, бер классташым үрнәгенә ияреп һәм Дилә апа киңәше белән, Казан дәүләт педагогия институтына тапшырып кайттым.

Ул елны имтиханнарга бөтенләй бармадым мин. Минутлык көчсезлегем — документларымны теләгән җиргә тапшырмавым өчен үз-үземне җәзаларга булдым да, отпускка кайткан авылдашларга ияреп, Свердловск өлкәсенә, романтика эзләп, тимер юлда эшләргә китеп бардым. Хәер, бу адымым өчен беркайчан да үкенмәдем. Кайчан дөнья күргән булыр идем әле?!

Уралда Илдар абый мине үзе «эзләп тапты». Теге көннән соң «тиле кызый»ны «югалткан» да авылга хат юллаган. Аны әниләр миңа җибәрделәр. Янә ике арада хатлар йөри башлады. Олуг шагыйрь миңа үзенең яңа «табадан төшкән» «Карурман» дигән китабын да бүләк итеп Уралга җибәрде. Титул битенә: *«Шигырьләремне анда яшәүче татарларга да укы, ана телен онытмасыннар. Милләтне милләт итеп матур әдәбият, җыр-моң гына һәм сез — Шигырь, Ана телен яратучы яшьләр саклаячаксыз»,* — дип язган иде. Шагыйрьнең шул сүзләре этәргеч бирдеме, яшьлекнең кыю беркатлылыгымы, көннәрдән бер көнне мин урман аланындагы төшке аш вакытында хезмәттәшләремә (тимер юл эшчеләре еш кына походтагы кебек яши иде) аның «Карурман» поэмасын кычкырып укыдым. Безнең бригаданың 80 проценты татарлардан гына тора иде, шуңа да бик әсәрләнеп тыңладылар, тагын-тагын укуымны сорадылар. Бер чирканчык алгач, икенче-өченче көннәрдә дә төшке ял вакытларында яттан Илдар абый Юзеевның, башка шагыйрьләрнең шигырь-поэмаларын укый башладым. Миңа авылдан бергә килгән дус кызым, классташым Гөлсинә дә кушылды. Шулай итеп, безнең мәктәптәге активлык Илдар абый ярдәме белән Уралда янә баш калкытты. Без андагы татарлар белән бергә үзебез бик тә яраткан Рудничный бистәсендә (ул халык телендә элеккеге исеме белән Арбах (Ауэрбах) дип йөртелә иде, күчмә колоннабыз кыш көннәрендә шунда вагоннарда яшәде) татарча концертлар куя, кичәләр оештыра башладык. Мәктәптән калган гадәт буенча, бәйрәмнәргә бизәкләп-чачаклап стена газеталары да чыгардык. Аның күпмедер өлешен русча да яза идек әле. (Их, яшь чаклар... диярсең, билләһи!)

Анда ике ел эшләгәч-яшәгәч, мин Казанга әйләнеп кайттым, эшкә урнаштым, университетка укырга кердем. Шигырьләрен элеккечә үк йотлыгып укысам да, Илдар абый белән берничә елдан соң гына очраштык. Янәсе, баштa кеше булам, ягъни белем алам, аз гына танылам. И-и, самими беркатлылык...

Ул көнне Төзүчеләр мәдәният сараенда Илдар абый Юзеев белән очрашу кичәсе үткәрелде. Башкаларга ияреп сәхнәгә мендем дә кулымдагы чәчкәләрне шагыйрьгә суздым. Мең рәхмәт аңа, онытмаган, шунда ук танып алды да: «И качкын кыз, качкын кыз...» — дип, дүрт юллык шигырь әйтеп тә алды. (Ни кызганыч, башка сүзләре истә калмаган.) «Башка качмыйсыңдыр бит инде», — дип көлде.

«Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасында эшли башлагач, без ешрак аралаша башладык. Ләкин нигәдер мин аннан һәрчак оялдым, уңайсызландым, көндәлек әңгәмәдәш булырлык итеп якыная алмадым. Чөнки ул минем өчен һәрчак буй җитмәс Шәхес, олуг Шагыйрь, фидакарь Милләтпәрвәр булды. Шулай булып кала да...

*Ноябрь, 2007*

**ВАКЫЙФ НУРИЕВ**

# «Илдар абыйга шылтыратырга!»

Шулай гадәтләнгән: иртәгә редакциядә эшлисе эшләремне бер кәгазь кисәгенә язып куям. Ул һәрвакыт өстәлдә, каршымда. Планны һәрдаим искә төшереп тора. Кәгазь кисәге һәр көн кич яңартыла. Кул җитмәгән эшләр икенче кәгазьгә күчерелә, ә монысы чүплеккә оча. Беркөнне ул кәгазьләрнең берсендә «Илдар Юзеевка шылтыратырга!» дигән сүзләр дә бар иде. Тик шылтыратырга өлгерә алмый калдым. Иртән кайгылы хәбәр ирештерделәр: «Илдар Юзеев вафат».

Көтмәгәндә, уйламаганда...

Гомеренең соңгы көннәрендә бездә — «Салават күпере» һәм «Сәхнә» журналлары редакциясендә эшләде Илдар абый. Ипле, җайлы кеше иде. Эшкә килүгә, бүлмәмә кереп хәл-әхвәл сорашыр иде. Кулында — кәгазь. Анда йә шигырь, йә мәкалә, йә төнлә шагыйрь күңелендә туган берәр тансык идея. Журналга бирәсе әйберсен өендә язып килә иде ул. Редакциягә килгәч эш болай да җитәрлек. Корректура укыйсы, теге яки бу йомыш белән килгән автор-хәбәрчеләрнең күңеле булганчы сөйләшеп утырасы, өметле сүз көтеп күзгә баккан яшь яки пенсиягә чыккач шигырь яза башлаган шагыйрьләрнең «иҗат җимешләре»ннән табыш эзләп интегәсе, кемнеңдер туган көненә шигъри котлау язасы. Туган көннәр дигәннән, Илдар Юзеев бәйрәмнәрдә табын күрке иде. Канатлы сүз, йомры юмор остасы иде ул. Кайвакыт балтаң суга төшә, эшең бармый, күңелең төшенкелектә. Шул вакыт Илдар Юзеевның нәкъ урынында, нәкъ вакытында әйтелгән рифма-ритмга салып очырган бер хикмәтле сүзе җитә.

Шәхсән миңа калса, Илдар абыйны олысы да, кечесе дә ярата, үз итә иде. Әмма И.Юзеев үзенең күңел бакчасының капкаларын теләсә кемгә ачып куймады. Ул бакчадагы гөл-чәчәкләрнең матурлыгын, гүзәллеген күрү бәхете бик сирәкләргә генә тәтеде, гәрчә шагыйрь үзе беренче карашка гади, ихлас күренсә дә. Компанияләрдә Илдар абый һәрвакыт игътибар үзәгендә. Ул сөйли, көлдерә, күңелне күтәрә. Әмма ул әңгәмәдәшләре җаны теләгән кешеләр булганда гына ачылып китә. Шунда күңеле кабул итеп бетермәгән берәр кеше утырсамы, Юзеевтан «эһем-эһем»нән башка сүз-аваз ишетә алмыйсың.

Безгә эшкә килгәнче дә Илдар абый редакциябездә еш була иде. Безне ярата иде. «Салават күпере» журналының баш рәссамы Фәрит Муллахмәт кешеләрне дәвалау сәләтенә ия бит инде. Берәр җирең авыртса, Фәриткә куш. Авырткан җиреңә үзенең уч төбеннән кайнар дулкыннар җибәрә ул. Син аның энергетикасын сизеп-тоеп утырасың. Авырту шунда ук басыла. Илдар ага да байтак сеанслар алды аннан. Тора-бара бу сеанслар иҗади хезмәттәшлеккә әверелде. Илдар Юзеев язган, рәсемнәрен Фәрит Муллахмәт ясаган «Бәби Ай» 2003 елның балалар өчен чыгарылган иң яхшы китабы булды.

Бер якта торгач, эштән Илдар абый белән бергә кайтабыз. Җәяү кайтабыз. Җәйге эссе көннәрдә Чехов базары янындагы «Марсель» кафесына кереп утырабыз. Монда җиләс, салкынча. Сөйләшә-сөйләшә берәр чынаяк чәй эчәбез, бик эссе көннәрдә берәр кружка сыра алабыз. Күңелләрне бушатып, һушланып утырганнан соң, кафе каршысындагы бакчага чыгабыз. Соңгы вакытта бу бакчага чәчәкләр-гөлләр утырттылар, кешеләр йөри торган юлларга вак таш түшәделәр. Шәһәребезнең җанга хозур бу почмагында Казанның соңгы елларда матурлануына куанабыз. Тагын бер елдан башкалабызга 1000 яшь. «Күреп булырмы инде ул бәйрәмне? Исән-сау торып булырмы-юкмы?» — дип борчылып куя Илдар абый. «Борчылма, Илдар абый. Син дә күрмәгәч», — дим, аның сүзләренә әллә ни игътибар бирмәскә тырышып.

Бу бакчада безгә еш кына заманында Татарстанның Верховный Советы Президиумы рәисе булып эшләгән Шамил Мостаев очрый. Шулай ук кафеда утырып чыккан пенсионер экс-министрлар, ниндидер экс-түрәләр Илдар абыйга сәлам биреп уза. Аларның да һава сулап йөрүләре, күрәсең. Юзеев алар белән дә бик ачылып китмичә, тыйнак кына күрешә.

Беркөн шулай шушы бакчада утырганда, Илдар абый авыр сулап әйтеп куйды:

— Бүген төнлә хатынга «скорый» чакырттык бит әле, Вакыйф. Авырый. Исән генә була күрсен. Аннан калсам, мин нишләрмен? Хатыныңнан калырга язмасын!

Ходай Тәгалә аның бу теләген үтәде. Тик менә Казанның 1000 еллыгын күрергә насыйп булмады аңа. Шагыйрь күңеле монысын алдан ук сизенгән, күрәсең.

...Редакциядә өстәлемдә иртәгә эшлисе эшләр язылган бер кәгазь кисәге ята. Анда «Илдар Юзеевка шылтыратырга!» дигән сүзләр бар. Әйе, әйе, ул записка һаман ята әле. Аны ташларга кулым бармый. Илдар абыйның арабызда юклыгына ышанасы килми. Үзе үлгәч аның редакциядәге өстәле өстендә калган ручкасын да миңа кертеп бирделәр. Шактый тузган, кыршылган ручка. Күпме хезмәт итте икән ул шагыйрьгә. Бәлки әле, бу фани дөньяда соңгы тылсымлы сүзләрен ул нәкъ менә шушы каләм белән язгандыр. Мин еш кына ул каләмне учыма салып кысып торам. Шагыйрьнең кул җылысын тойгандай булам. Ручканың башын тешли-тешли язган Илдар абый. Шигырь җиңел генә тумыйдыр шул.

Тагын теге кәгазьгә күзем төште: «Илдар Юзеевка шылтыратырга!»

**ЛЕНАР ШӘЕХ**

# «Йөрәктәге тирән ярам»

Мин ул көнне университеттан соң гына кайттым. Эчем пошканга туры юлдан түгел, ә караңгы урамнар аша узган сукмактан атладым. Йөрәк кыса, күңелдә борчулы аваз:

Ярым бушлык, ярым караңгылык,
Йөрәктәге тирән ярам кебек.
Шул ярамны учлап барам кебек,
Болай бару соңгы чарам кебек...
Ярым бушлык, ярым караңгылык.

Күңел нидер сизенә. Нәрсәдер булачак...

Иртә белән «Идел-Пресс»ка килдем. «Чаян»да Мәгъсүм абый Гәрәев белән сөйләшеп утырдык.

— Фото мәсьәләсен Яңа елдан соңга калдырырга туры килер. Илдар абыең сырхауханәгә кереп яткан, — диде ул. (Ә без Мәгъсүм абыйның яңа китабына өчәүләп фоторәсемгә төшмәкче идек.)

Бүген үк барып кайтырга кирәк. Нәрсә булды икән?

...Җиденче каттан сигезенчегә менәм. Роберт Әхмәтҗан кем беләндер сөйләшеп тора. Йөзе борчулы, күзләрендә тирән сагыш:

— Илдар үлгән бит, Илдар...

— Кайсы Илдар? Юзеевмы әллә?..

— Әйе...

— Ни сөйлисез сез?..

— Әйе шул, үлгән...

Бер мизгелдә күңелемнең әллә ничә кылы өзелде, бар җаным актарылып чыкты... Аякларым әллә атладылар, әллә юк...

Башка төшкән кайгы-сагышларны
Әллә бүлешәбез, әллә юк…
Әллә күрешәбез, әллә юк…
*(И.Юзеев)*

Күңелемдә кадерләп сакланган якты хатирәләр уяна. Мин, Илдар Юзеевны әдәбият дәреслегеннән генә укып белгән, Минзәлә педагогия көллиятенең I курсында укып йөргән егет, аннан хат алгач, ничек сөенгән идем!

Авылга кайткач, ул хатны әнием бирде. Куллар калтырый, ә йөрәк күкрәк читлеген җимерердәй булып ярсып-ярсып тибә. Татарстанның икенче бер почмагында туып үскән ниндидер Ленарга Илдар Юзеев тикле халык шагыйре игътибар итсен әле!..

*«Ленар!*

*Шигырьләрең басылырлык. Әмма үзеңнең кем икәнеңне язмагансың. Синең балалар өчен язу сәләтең бар. Дәвам ит. Юморың да мөлаем. Әмма кайбер урыннарда рифмаларың ятышсыз. Бер строфада төзәттем.*

*Өч шигыреңне газетага тәкъдим итәм. Тиз генә чыкмас та, бәлки. Чират зур. Уңыш телим.*

*Илдар Юзеев*

*22 март, 2000 ел».*

Арада тагын алты сәлам хаты — төпле киңәшләр, җылы теләкләр, зур таләпләр... Ярый әле ул мине күреп алды, юкса бөтенләй башка сукмактан киткән булыр идем.

Ахыргы хатында Илдар абый Казанга килергә үгетләгән иде. Ә мин, аның уйларын алдан сизенгәндәй, университет диварлары эчендә башкала шаукымына һаман да күнегә алмыйча, ул кодалаган татар филологиясе һәм тарихы факультетына укырга керергә әзерләнеп йөри идем.

Илдар абый янында узган һәр мизгел, һәр очрашу истә. Ул «Сабантуй»да эшли, мин аның янына гына киләм. Ниндидер магниты, ягымлы карашы белән үзенә тарта. Сөенә-сөенә чыгасың, канатланып кайтып китәсең. Мактавы да, тәнкыйте дә эләгә...

Мөгаен, Казан тикле Казанга да Илдар абый тартып китергәндер. Укуымны, дөньяга чыгуымны, ачылуымны, үсүемне теләде ул. 2002 елның сентябрендә беренче мәртәбә күрешкәч: «Фотоңнан озын буйлы икәнлегеңне чамалаган идем. Кара, чынлап та шулай икән», — дип тагын да үстереп җибәрде. Аралар якынаеп киткәч, семестр ахырларында имтихан билгеләрен сорый да, гел бишлеләр булуын белгәч: «Ленар, син нигә минем оныгым түгел икән?» — дип куйгалый.

Үзе дә миңа дәү әтием кебек якын, кадерле. Бәлки, дәү әни белән генә үскәнгә шулайдыр... Оныкка бабай назы, аның акыл өйрәтүе, тормыш тәҗрибәсен биреп калдыруы да кирәктер.

Илдар абый «Сабантуй»да ун еллап эшләде. Теләмичә китте. Аңа да, миңа да авыр иде. «Идел-Пресс»ка барам, ә анда — бушлык. Беркем көтми, берәүгә дә мин кирәк түгел кебек. Күзләр таныш йөзне, шагыйрьнең ихлас елмаюын эзли, җан җылысы, салкыннан ышык көтә...

Илдар абыйны «Сәхнә» журналына чакырдылар. Минем «кыйблам» да шунда күчте, йөз сиксән градуска борылды.

Беренче карашка өлкән булып күренсә дә, ул күңеле белән бик яшь иде. Яшьләр кайда, Илдар абый шунда. Төрле әдәби конкурсларда, кичәләрдә... Хәтта университетның «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсенә дә кунак булып килде, без оештырган «Шигъри Сабантуй»да: «Әдәбиятның киләчәге бар икән!» — дип сөенеп, бар залны яңгыратты.

Тагын бер кызык вакыйга истә калган. «Чаян»га язарга тотынгач, «Татлы хыял» дигән шигыремне күтәреп, остазым янына кердем. Илдар абый «Сабантуй»ның хатлар бүлегендә Фәридә Вәгыйзова белән бер бүлмәдә утыра, язганнарымны карый.

— «КДУ татфагының 1135 нче төркемендә сигез генә кыз укый...» — Кинәт ул: — Сигез кыз асраганчы, симез кыз асра, — дип елмая.

Юмор йоккан Фәридә апа да:

— Симез каз яхшырак, — дип куя...

* * *

Остазлык назын бик аз тоеп калдым. Чыныгу өчен, чын шагыйрьлеккә юл алу өчен, бәлки, шулай кирәктер дә. Аның хәер-фатихасы, еллар битендә язылып, күңелемә сеңеп калды. Кызганыч, үзе кереш сүз язган беренче китабымны күреп сөенә генә алмады.

Үзегез дә яхшы аңлыйсыз ла...
Калдык инде Илдар абыйсыз да...

Әйе, ул зур шагыйрь, көчле лирик, шигърияттә үз мәктәбен булдырган, пинжәге астыннан йөзләгән шәкерт чыгарган олы, изге җан иде. Илдар абый балалар шагыйре дә иде. Гомеренең соңгы елларында ул бу жанрда җиң сызганып эшләде. Аның »Сабантуй» битләрендә дөнья күргән шигырьләре, китаплары — «Бәби Ай», «Аю сатам, кем ала?», «Кар өстендә дөяләр» — моңа дәлил.

Илдар абый драматург та иде әле. Әлмәт, Минзәлә театрларында, Күчмә театрда күп куелды ул. Безнең Г.Камал театры гына тиешенчә игътибар итмәде кебек.

* * *

...Вакыт ага. Бүген тагын ябалак-ябалак кар ява. Күңелне аркылыга-буйга моңсулык айкый, күз алдыннан хатирәләр чабыша. Юксыну катыш сыкрану аша йөрәктән суырылып-суырылып моң ташый, моң агыла...

Күңелләрне телеп төшә,
Йөрәкләрне мең яралый
Синең юклык, салкын бушлык,
Илдар абый, Илдар абый...

Ап-ак кышның моңлы көне.
Бөтен җаным гамьгә тарый.
Ак кар явар...
Синсез авыр,
Илдар абый, Илдар абый...

Әнә дымлы тәрәзәдән
Моңсу итеп кояш карый.
Ул да сине сагынадыр,
Илдар абый, Илдар абый...

...Язлар җитәр, карлар китәр,
Тамчы тамар бертуктамый.
Күзем яшьле.
Кемдер дәште:
«Илдар абый, Илдар абый...»

Яфрак булып шыбырдашкан
Гомерләрне еллар саный...
Кол Галидәй басып тора
Илдар абый, Илдар абый...

*21 декабрь, 2004*
*Казан*

**ЛӘЙСӘН МӨГЪТӘСИМОВА**

# Җырларымны сезгә бүләк итәм...

*(Илдар Юзеев монологы)*

Кайталмадым, дустым, ни кызганыч,
Әмма күңлең ялгыш уйламый,
Шаярса да, усал шаяра шул!
Без дигәнчә язмыш уйнамый!
Бүген төштә миңа әнкәй керде:
«Сине, — диде, — көтә Ямады!»
Раска килде төшем, булмаса да
Көткәнемнең иң дә яманы.
Каләмемнән шигырь аккан чакта,
Үкенечле шунсы, сүнде шәм,
Үкенмәс тә идем, бәлки, шәмне,
Вакыт җитеп, үзем сүндерсәм!
Салкын Мәңгелектә югалганчы,
Яшәрлегем бар да иде күк.
Күпме языласы җырлар калды,
Ярсып-ташып аккан Идел күк!
Җырым минем һич бетәрлек түгел,
Куларбамда гына — бер капчык!
Җае чыкса, шул арбаны тартып,
Килер иде Юзи бер кайтып,
тик
Кояш күк гом(е)рем баеды да
Төшеп сүнде офык читенә.
Шигырь дәфтәрләрем тулмаса да,
Соңгы нокта куям битенә.
«Нигә киттең, — дияр кемдер, —
Сиңа яшәргә дә әле яшәргә!»
Тудырса да авыл, көне җиткәч,
Шагыйрь үлә барыбер шәһәрдә.
Гәүдәм минем калсын Казанымда!
Аңлар диеп беләм Ямады,
Халкым диеп янды шигъри йөрәк,
Мин ышанам, юкка янмады!
Китмәскә дип калам, бөтенләйгә,
Ләкин калсам да мин Казанда,
Җан күбәләк булып Ямадыга
Очар соңгы юлны язганда.
Каберемә мәрмәр димим, бары
Туган якның ташын куйсыннар,
«Юзи — Җирнең моңлы баласы!» — дип,
Сүзләремне анда уйсыннар!
Хушлашмыймын. Мин бит калам,
Калам, дуслар, шигырь-җырымда!
«Кеше китә — җыры кала», — диләр,
Ә калганы бар да ерунда!
Еламагыз, дуслар, беркайчан да,
Тырышыгыз җырлап яшәргә!
Васыятем итеп куларбамны
Калдырырга булдым яшьләргә.
Җырларымны сезгә бүләк итәм,
Үзем калам җырда яшәргә!

*21 декабрь, 2004*

**РАФАЭЛЬ МОСТАФИН**

# Кыр казлары артыннан...

Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев турында язарга омтылу мәрхәмәтле бурыч кына түгел, ә бәлки зур җаваплылык та. Шигъриятенә кайсы яктан килеп карасаң да, соклану хисе туа: ул гадилеге белән үзенә җәлеп итә, фәлсәфи тирәнлеге белән мавыктыра; аңлаешлы булуы белән халыкчан, ә фикер сөрешенең катлаулылыгы белән фәнни...

Күпме генә сагынып сөйләсәк тә, шагыйрь арабызда юк инде. Ә иҗади мирасы тулаем исән. Нәкъ менә хәзер ул мирасны өйрәнү, сайланма әсәрләрен тагын бер кат күздән кичерү кирәк тә...

# Үз язмышыңның ачысы да татлы

Кеше тик торганда гына шагыйрь булып китми, шигырь язарга нәрсә этәрде соң сине, дип сөйләшеп киттек без бервакыт Илдар белән. Казан педагогия институтының I курсында укыган чагында ул бик каты авырый башлый, врачлар анда ачык формадагы туберкулез дигән үпкә авыруы табалар. Бу — балачаклары сугыш елларына туры килгән, ач-ялангач килеш көн күргән бик күпләргә хас авыру.

Больницага эләккәч, ул ике врачның үзе турында сөйләшеп торганын ишетә... Хәлләр шәптән түгел икән... Кичекмәстән операция ясарга кирәк, юкса исән калуы икеле. Җитмәсә, ул елларда әле үпкәгә операция ясаучы белгечләр дә аз, ахыры ни белән бетәчәген беркем белми. Ә бит әле егеткә нибарысы унсигез яшь!..

Менә шул көннән башлап Илдарның гомере өчен аның күңелендә пыскып яткан поэзия көрәшкә күтәрелә. Ул тән сызлауларын, яшәү белән үлем арасындагы гаделсез газапларны онытыр өчен шигырьләр яза башлый. Поэзия аның шәфкатенә әверелә. Рухи көче физик көч бирә. Яшәүнең төп матурлыгы табигать хозурлыгын күрә белүдә, һәр яңа көнне сөенеп каршы алуда, һәр мөмкинлекне файдалану өчен вакытның кадерен белеп эшләүдә икән, дип әйтә торган иде Илдар. Табигатьнең һәр мизгеле тормыш яңарудан тора. Көз көне коелып, кыш көне изелеп яткан иске яфраклар арасыннан яшь үләннәрнең шытып чыгуы, һәр таңда болыт каурыйларының яралуы, иртәнге чык белән юылган җир өстенә ялантәпи баса алу — болар барысы да яшәү поэзиясе бит! Кеше аны күрә белергә генә тиеш! Һәм, врачларны шаккатырып, нечкә күңелле, йомшак холыклы Илдарда туган поэзия аңа аякка басарга ярдәм итә. Шигырьләрең укучы күңелен өтеп алсын өчен, күрәсең, фаҗига белән хисләрнең янәшә булуы үзенчә бер киеренке рухи шарт тудыра аладыр.

Катлаулы операциядән соң исән калуын тасвирлап, Илдар Юзеев 1951 елда, больницада чакта ук, үзенең беренче поэмасын иҗат итә башлый. «Тормыш җиңә» дип атый ул аны.

Илдар Юзеевның шигърияткә килеп керүен әлеге авыруы белән бәйләп сөйләү бик үк дөрес тә булмас. Ник дисәң, ул бит инде өченче сыйныфта укыган чагында ук шигырьләр яза һәм алар Башкортстанның район газеталарында, әдәби журналларда күренә башлый. Ә инде «Тормыш җиңә» дигән поэмасы басылып чыккач, республиканың әдәби мохите аны шагыйрь итеп таный. Кем әйтмешли, бәхетсезлектән бәхет эзләү шушы була инде ул!..

# «Таныш моңнар»

Алтмышынчы еллар башында татар әдәбиятына килеп кергән җылы җилләрне Илдар Юзеев исеме белән бәйләсәк, һич ялгыш булмас. Моңарчы пафослы кысаларга буйсынган, рәсми күрсәтмәләргә ярарга тырышып яшәп килгән татар поэзиясенә идеологик таләпләргә бик үк туры килмәгән хисле-мәхәббәтле, халыкчан лирика алып килә ул.

1955 елда басылып чыккан «Таныш моңнар» поэмасы шуның бер мисалы. Әсәрдәге романтик рухтагы кичерешләр, саф мәхәббәт маҗаралары, хезмәт темасына манылмыйча, яшьләр өчен һәм яшьләрнең үз телендә язылган.

Поэма киң катлам укучылар өчен куен дәфтәренә әверелә. Мәктәп сәхнәләрендә, әдәби кичәләрдә, клубларда яңгырый ул. Гашыйклар аны яттан сөйли, саф мәхәббәтне идеал итеп куйган яшьләр кулдан-кулга йөртеп укый. Татарстан радиосы «Таныш моңнар» дигән радиоинсценировка әзерләгәч, поэма иң популяр әсәр булып китә.

Мин юлда бик күп йөрдем. Кая гына барсам да, татарлар яшәгән төбәктә И.Юзеев иҗатына табынган кешеләрне күпләп очраттым. «Таныш моңнар» һәм «Фәрит-Фәридә» поэмалары бүгенге өлкәннәр өчен яшьлекнең үзе булып хәтердә калган.

И.Юзеевны күбрәк укыган саен, иҗади офык киңлекләренең чиксезлегенә ныграк ышанасың. Поэзия шәһәр йә авыл шагыйрьләренә бүленми икән. Татар мәдәниятенең йолдызлы күге уртак, милли йолдызлыкларга бүленми. Һәм Илдар Юзеев исеме поэтик кыйблада Такташ, Туфан, Сибгат Хәким исемнәре белән янәшә. Тарих шагыйрь гомере белән үлчәнә.

Беренче китабы чыккан көннән башлап И.Юзеев туктаусыз иҗат итә. Үзе исән чакта ук сайланма әсәрләренең биштомлыгы дөнья күрә. Шагыйрьнең активлыгына тиңнәр юк! Халык арасына таралып, бүгенге көнгәчә туктаусыз яңгырап торган җырларын исәпләп карасаң, йөздән артып китә.

Илдар Юзеев тышкы ялтыравыкларга корылган эксперименталь шигырьләр тудыру белән мавыкмый. Беренчел шигырьләре Һади Такташның романтик лирикасына ияреп язылса да, тора-бара ул, үз бизәкләрен табып, традицион ысулга әверелердәй юнәлешне хуплый, үз йөзен саклый ала. Олпат яшькә җиткәч тә И.Юзеев яшьлек каләменең романтикасын югалтмый.

Шагыйрьнең поэмалары хакында бик зурдан кубып сөйләшеп булыр иде. Үз гомерендә ике-өч поэма яза алган автор үзен зур иҗади уңышка ирештем дип исәпли, ә Илдар Юзеевның утыз поэмасы бар! Мәскәүдә яшәүче каләмдәш дусларыма бу турыда әйткәч, тегеләр аптырап калдылар, сизәм, ышанасылары килми, чөнки бу гайре табигый хәл, феноменаль күренеш хәтта! Ул поэмалар берсен берсе кабатламый, һәркайсысы татар поэзиясенең йөзек кашына әверелгән.

# Батырлык авазы

Илдар Юзеевның илле еллык иҗатына күз салсаң, әйткәнемчә, Такташ, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким шигырьләренең йогынтысын тоеп була. Әлбәттә, бу күренеш Илдарның кайбер чордашларына, әйтик, Шәүкәт Галиев, Гамил Афзал кебек талантларыбызга да хас. Ә менә Муса Җәлилнең иҗаты һәм батырлыгы Илдар Юзеев иҗаты өчен турыдан-туры әһәмияткә ия. Бөек Ватан сугышы темасына мөрәҗәгать итүе очраклы күренеш түгел, батырлык рухы, ягъни патриотик пафос шагыйрьнең үз җанында, һәм ул аның гомер буе көрәшеп яшәвенең асылы. «Язылмаган поэма» — әнә шул нисбәттән туган әсәр. Поэманың нигезендә Дахау концлагерена эләгеп, крематорийда яндырылган татар шагыйре, подполковник Хәйретдин Мөҗәйнең фаҗигале язмышы. Поэма һәлак булган шагыйрь монологы рәвешендә бара. Автор геройның эчке кичерешләре белән шултиклем мавыга ки, гүя тасвирланган вакыйгалар авторның үз башыннан кичкәндер, Илдар Юзеев дөрләп торган крематорий миче янында басып торып тоткыннарны җәзалауның шаһиты булгандыр кебек. Шагыйрь образларны бизәп күрсәтү белән мавыкмый, алар гади, горур, кадерле һәм изге. Минем әлеге поэманы авторның үз авызыннан тыңлаганым бар. Ул укыганда, тамакка нәфрәт төере тыгыла, шагыйрьләрне фашизм тырнагыннан азат итәр өчен бөтен Җир шарында чаң кагасы килә. Поэманы тыңлаганда, күздән яшь тама.

Ватан сугышына кагылышлы «Соңгы сынау» драматик поэмасын үз эченә алган «Миләүшә» китабы (1968) Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясенә лаек була. Шагыйрь батырлык темасын эзлекле рәвештә дәвам итә...

Җәзалап үтерелер алдыннан Муса Җәлил «Фауст» трагедиясен Гётеның үз телендә укый. Нәкъ менә шушы вакыйга яңа поэма өчен җирлек була да инде. Шагыйрь үзе аны драматик легенда дип атый.

Илдар Юзеев танылган драматург буларак та билгеле. Аның пьесалары, республика театрларында уңыш казанып, әкренләп күрше Башкортстан, Мари, Тува, Каракалпак сәхнәләренә дә барып җитә. Ә инде үзешчән театр коллективларының репертуарын И.Юзеев әсәрләреннән башка күз алдына да китерергә мөмкин түгел. «Янар чәчәк», «Бөркетләр кыяга оялый», «Кыр казлары артыннан» кебек пьесалар — татар драматургиясенең үрнәге, гел режиссерларның кул астында ятачак актуаль әсәрләр. Драматург Илдар Юзеевның тамашачылар саны миллионнар белән исәпләнә.

# Гармунсыз авыл

Илле елга якын дәвам иткән иҗат әледән-әле яңарып тора, күптөрле үзгәрешләр кичерә, туктаусыз яшәрә. Башлангыч чорларда И.Юзеевның шигырьләрендә шәхси кичерешләр, идиллия эзләү, һәркайда романтика күрергә омтылу өстенлек итсә, соңгы елларда ул фикер төрлелегенә, фәлсәфи тирәнлеккә ирешә. Драматургия законнары аның шигырьләренә дә үтеп керә: сюжетлы шигырьләре күбәя, эмоциональ киеренкелеге арта, диалоглары көчәя.

Сиксәненче еллар ахырында И.Юзеевта опера жанрына кызыксыну арта. Ул, үзенең бер шигъри драмасына таянып, «Ерактагы кәккүк авазы» дигән опера өчен (Рәшит Кәлимуллин музыкасы) либретто язды. Татар операсы барлыкка килү милли музыка сәнгатебездә бик сирәк күренеш.

Илдар Юзеев шигырьләре тулы бер гасырны колачлый, батырларга һәйкәл сала, персонажларны сөйлән итеп тезә.

Тырышса да дошман,
шагыйрьләрне
Аералмый җырдан, халыктан.
Тукай киткән.
Юкка сөенгәннәр —
«Мин исән», — дип, Җәлил калыккан.
Уйласа да балта тоткан җәллад:
«Җәлил китте...»
Җырчы китмәгән!
Шигъри җаны
Ярсу бер көч белән
Тибеп чыга тау-таш, чишмәдән.
Тәнен асрап йөргән җәллад күрә:
Җырлар исән...
Нинди көч анда?!
Шагыйрь җаны типкән җырлы дөнья
Гел тарая бара дошманга...

Илдар Юзеевның шигырьләре елдан-ел үсә, аларда фикер тирәнлеге, метафоралык, образлылык арта. Беренче карашка публицистик әсәр булып күренсә дә, поэмаларында лирика көчәя, фәлсәфи уйлар тыгызлана, шуның өчен дә киң катлам укучыга якыная. Аның һәр шигыре — акыл чыганагы.

Юеш тә дым... Дым да юеш...
Яңгыр да яңгыр...
Ә син яңгыр яуганда да
Яшен булып ян бер!
Нур да кояш... Кояш та нур...
Их, бер тамчы яңгыр!
Ә син бар җир янганда да
Яңгыр булып яу бер!

Мондый шигырьне дидактик өндәмә дип кабул итә алмыйсың. Шагыйрь кеше язмышына карата битараф калмаска, дөньялыкта гамьсез яшәмәскә, көндәлек гүзәллеккә иялнмәскә, ә һәрдаим яңалык итеп карый белергә өйрәтә. «Мин һәрнәрсәгә беренче тапкыр күргән сабый кебек сокланам һәм башын палач балтасына салган шагыйрь кебек бәхилләшеп карыйм», — дип әйтә иде шагыйрь үзе.

Илдар бик матур итеп гармунда уйный иде. Шуңа күрә аның «Гармунсыз авыл» дигән шигыренә аерым тукталасым килә. Сигез юллык миниатюрага нинди зур проблема сыйган! Авылларда хәзер рухи ярлылык көчәя. Борынгыдан килгән йолалар, гореф-гадәтләр онытыла бара. Авыл кешеләре, матуррак киенеп, техника могҗизаларына ышанып, чит ил тәгамнәре белән сыйланып, үткәннәрдән калган милли байлыктан ваз кичә. Бәйрәмнәрдә, тын урамнарда, сагышлы минутларда чыңлап торган гармуннарны магнитофоннар һәм видиклар алыштырды. Яңа буынга кеше булып калыр өчен фән һәм техника казанышлары гына җитәрме?

Авылларда йөрим. Кем генә юк...
Бар моңлысы шунда... бар моңсыз.
Моңсыз авыл җирдә булмаса да,
Мин бер авыл күрдем гармунсыз.
Бар тирә — тын... Яшьлек — чәчәкләрен
Вакыты җитми йомган шикелле.
Нидер җитми җанга...
Авыл йоклый...
Сандугачсыз урман шикелле.

Илдар Юзеев дигән олы шәхес, талантлы шагыйрь һәм кайгыртучан әдип белән бер чорда яшәү үзе бер бәхет. Аның иҗаты хисләр өермәсе булып, әүлия авазы һәм моң чишмәсе булып безгә яшәү дәрте өстәп тора.

Ул калдырган әдәби мирас — татар поэзиясенең алтын баганасы...

Язмамның азагын яраткан шагыйребез Илдар Юзеевның үз сүзләре белән төгәллисем килә:

Болай да кыска гомерне
Мәгънәле итәсе бар.
Юлчы булып дөнья буйлап
Сәфәрләр китәсе бар.

Халык кайгырганда — елый,
Көлгәндә — көләсе бар.
Ил булып утка керәсе,
Ир булып үләсе бар.

**ТӘЛГАТ ГАЛИУЛЛИН**

# Шигъряттә үз биеклеге бар!

Илдар Юзеев белән яшь аермабыз, тарихка кизәнмичә, кеше гомерен генә истә тотканда да, бик кечкенә, бер кул бармаклары саны җитәрлек булса да, яшьлек һәм тормыш ямен, мәхәббәт кадерен белергә, халык җыры моңын, моңның рухи дөньяга тәэсирен аңларга минем буынны ул өйрәтте, дисәм дә, олы хата булмастыр. Сүз бер-береңә карашып сөйләшү, аралашу юлы белән ясалган әхлакый тәэсир турында бармый. Ул елларда безнең шәхси танышлыгыбыз юк иде әле. Биредә аның шигърияте, дөресрәге, «Таныш моңнар» поэмасы күздә тотыла. Без тугызынчы-унынчы сыйныфларда укыганда, ягъни 1955 елда дөньяга аһәң салган бу әсәр һәр яктан ачыш булды. Аның тексты Кычытканлы дигән сәер исемле ерак татар авылына килеп җиткәнче, әсәрнең җырга, көйгә төрелгән вариантын радиодан ишеттек. Бер караганда гади күренеп тә, кеше кичерешләрен шулай тирәнтен иңләп, үтемле сүз — образга күчереп буламы икән дип гаҗәпләндек, сокландык. Эссе көндә бик теләп эчелгән су кебек кабул ителде әсәр. Шул елларда фикер белән хис арасында тәңгәллекне тапкан, җыр белән көйне тормыш чынлыгын ачуга буйсындырган поэма милли рухы белән зиһеннәребезне эшләтеп, йөрәкләребезне җилкендереп җибәрде. Күр әле, бу әсәр нәкъ безнең бүгенгебез һәм киләчәгебез турында икән ич. Зөфәр белән Резидә дә, унынчыны тәмамлап, мөстәкыйль тормышка, олы юлга чыгарга әзерләнәләр түгелме соң? Тик киләчәкне һәркайсы үзенчә күзаллый, бәхетне үзенчә аңлый. Бер-берсен яратсалар да, егет белән кызның дөньяга карашлары үзгә. Резидә «институт, театрлар, асфальт урамнар, шәһәр парклары, яңа дуслар турында» хыялланып, Зөфәрнең, тракторчы булып, «тузан, май эченә» батып йөрүен хупламый.

Кыскасы, «Таныш моңнар» хис киеренкелеген бирүе, лирик-моңсу аһәңе, мавыктыргыч сюжеты белән вакытлы язылган, көтеп алынган поэма иде. Чөнки ул безне, кем генә булсаң да, кеше булып калырга, мәхәббәт килсә, аны саклый белергә өндәде.

Ул елларда һәр өйгә радио кереп җитмәгән, мәгәр авыл уртасындагы баганага элеп куелган, артист Боярский эшләпәсен хәтерләткән ямьсез кара «тарелка» көннәр буена җырлап-сөйләп тора. Бер-беребезгә хәбәр итә-итә, күз яшьләрен, елмаюны үзебездән дә яшереп, багана төбендә «Таныш моңнар»ны кат-кат булса да, онытылып тыңлый идек. Гадәттә, китапны бер тапкыр укысаң, тапшыруны бер трит тыңласаң, кабат укыйсы да, колакны арытасы да килми. И.Юзеев поэмасы, сирәк эләккән тәмле тәгам төсле, туйдырмый торган әсәр булып чыкты. Хәзер дә аны укыганда яшьлегеңә әйләнеп кайткандай буласың. Тукай Казанга «Пар ат» белән килеп керсә, И.Юзеев татар дөньясын «Таныш моңнар»ы белән яулады.

Кыскасы, яшь шагыйрь, чал тарихлы татар поэзиясенә яшьлекнең күркәм сыйфатларын, бүгенгесен һәм киләчәккә хыялларын романтик биеклеккә күтәреп җырлаган әсәрләре белән килеп, үз үрен тапты. «Таныш моңнар» янына «Миләүшә», «Фәрит-Фәридә», «Өчәү чыктык ерак юлга...», «Мәхәббәт китабы» кебек поэмалары, дистәләгән шигырь-җырлары өстәлде. Барысы да яшьлек, мәхәббәт, әхлак һәм һәр кешегә бер тапкыр гына бирелгән гомернең кадерен белү турында... Ә инде бөтенләй башка яссылыкта иҗат ителгән «Тынлык белән сөйләшү», «Соңгы сынау», «Язылмаган поэма», «Таш диварлар авазы», «Очты дөнья читлегеннән...», «Мәңгелек белән очрашу», «Соңгы төн» кебек поэмаларында И.Юзеев гомумгуманистик төшенчәләр, тарихи категорияләр белән эш итә, дөньяның барышы, киләчәге өчен сызлана. Аның өчен үрнәк-өлгe булырдай чын кешеләр — халык бәхете хакына җаннарын фида кылган, милләтләренә турылыклы татар шагыйрьләре — бөек Тукай, Хәйретдин Мөҗәй, Муса Җәлил, Абдулла Алиш...

Киләчәк матурлыгына, тормыш яменә гашыйк романтик шагыйрь булып калды И.Юзеев.

И.Юзеев романтизмының төп үзенчәлеге — чынбарлык белән сәнгать арасындагы мөнәсәбәтнең асылына төшенеп, тормышны үз табигый сыныннан күтәребрәк сурәтләү. Аның лирик герое — галәм, җир язмышы турында уйланып, борчылып яшәүче шул ук галәм һәм җир кешесе. Ул үзен кешеләр язмышы, аларның киләчәге өчен җаваплы саный. Җансыз матдәләргә, тынлыкка, тарихка җан өрүче дә Кеше йөрәге. Ә йөрәкне мәхәббәт уты һәм халык тарихы җылыта. Реалистик әдәбиятта акыл йөрәкне уятса, И.Юзеевның романтик әсәрләрендә акылны йөрәк хәрәкәткә этәрә.

> Сөю хисен йөрәк югалтмаса,
> Җир суынмас мәңге,
> Җир яшәр, —

ди шагыйрь.

И.Юзеев иҗаты турында мин шактый уйландым, әсәрләндем, «Яшьлек һәм батырлык җырчысы» дигән хезмәтемне дә язып бастырдым, җае чыккан саен, язучының гаҗәеп бай иҗади мирасы турында

фикерләремне әйтеп барырга тырыштым. Ул тәнкыйть жанрын, хәтта кайбер «чеметеп» алуларны да дөрес кабул итте. Шагыйрьләрнең бер ишесе аналитик фикерне, тәфсилле анализны өнәп бетерми, гомуми мактауны, фәлсәфи атамалар белән сөйләшүне, баллы «сиптерүне» яратыбрак кабул итә, янәсе, иптәш аның эзләренең асылын дөрес аңлаган. Абыйсы, күренекле тәнкыйтьче Нил Гафур улының тәэсире дә булгандырмы, әмма И.Юзеев шигырьне фәнни анализлауны, бигрәк тә аның поэтик үзенчәлекләре турында сөйләшүне, хәтта тәнкыйди сүзне уңай кабул итү сәләтенә ия иде. Бусы да аның олы шәхес булуына бер дәлил. Язмыш мине Илдар Гафур улы белән таныштырганда, каләмдәшләре яратып эндәшкәнчә Юзәй инде татар поэзиясенең С.Рәмиев, Һ.Такташ шигъри мәктәбенең талантлы дәвамчысы, әдәбиятта (ул бит әле лирик рухлы драматург та) үз сүзен әйтергә өлгергән, җырлары халык иреннәннән төшмәгән танылган шагыйрь иде.

Үткән гасырның җитмешенче елларының икенче яртысы... Казанны, язучыларны сагынып, әдәби процесста аз-маз катнашып, Алабуга педагогия институтында көн күреп яткан чорым. Мәдәни үзәктәнерактарак яшәп белем алучы, милли җанлы талиб-талибәләр «тере» каләм әһелләребезне күреп, тыңлап, аралашып калсыннар дип, татар язучыларын, үзем шигырьгә мөкиббән кеше буларак, күбрәк шагыйрьләрне очрашуларга чакыра, иҗат кичәләре оештыра башладым. Иң әүвәл мин: «Алабуга педагогия институты студентлары белән очрашуга килеп чыга алмассызмы», — дип, яраткан шагыйрем, киң күңелле, милләтенә аң-белем бирү, тамчылап булса да коллык психологиясеннән арындыру өчен җанын, соңгы тамчы канын кызганмас олы талант иясе Сибгат Хәкимгә сүз каттым. Аның язучылар арасындагы абруе да истә тотылгандыр инде. Беренче фәнни мәкаләмне иҗатына багышлавым ярдәм итте булса кирәк, ул бер чакыруымны да кире какмады. Сибгат ага һәр килүендә берничә татар язучысын, хәтта артистларны (З.Нурмөхәммәтов, В.Гыйззәтуллина), композиторларны (Алабуга студентлары Җәүдәт Фәйзине дә күреп калды) алып килде. М.Мәһдиев, Г.Ахунов, Г.Рәхим, Р.Мөхәммәдиев, тәнкыйтьче Ф.Миңнуллин һ.б. Алабугада үзләрен ихластан яратып, әсәрләрен мөкиббән китеп тыңлаган укучыларын таптылар. Шулар арасында ике аерылмас дус — Ш.Галиев белән И.Юзеев та бар иде.

Ул чорда әле Чулман, Вятка елгаларының ике ярын тоташтырган күперләр корылмаган, аэропланнар сирәк оча, юллар Әби патша Себергә сәфәре чорында салдырган килеш диярлек. Язын, көзен Алабугага ар җире — Можга шәһәре аша тимер юл белән генә эләгеп, анда да 100 чакрымнан «уазик» атлы машинада гына үтеп була иде. Ә нинди рухи якынлык, очрашулар-күрешүләр шатлыгы яшәде ул чорда. Язучылар techинститутка әледән-әле килеп-китеп тордылар. Алабуга, урыс купецлары шәһәре булу сәбәпледер инде, аның җитәкчеләре әдәбияттан, гуманитар дөньядан ерак булдылар. Шуңа күрә татар язучыларын, Актаныш тарафларындагы шикелле, ипи-тоз, җыр-биюләр белән каршы алулар булмады, әмма студентларның күзендәге, йөзендәге шатлык хисе, кызыксыну, мәҗүсилеккә якын ихласлык юл газапларын да, фирка оешмаларының игътибарсызлыгын да онyttырды.

Шул төбәкнең Актаныш, Мөслим, Мамадыш, Минзәлә кебек саф татар районнарыннан җыелган студентларның туган телебезне яхшы белүләре, язучы сүзен йотлыгып тыңлаулары, Казан кунакларын пәйгамбәрләрдәй сокланып кабул итүләре, соңыннан ямьле концерт белән сыйлаулары ошамаслык түгел иде. Шул сыйфатлары белән ул еллар иң кадерле, истәлекле хатирәләр булып күңелдә калды.

Хәзер юллар да бар, җиңел арбалар да җитәрлек, тик чакыру, татар әдәбиятына игътибар гына юк. Бик кызганыч, ул чорда татар сүзен галәмнәргә тоташтырган бөекләребезнең күбесе инде Аллаһ хозурында.

Илдар әфәнде белән Алабугада гына түгел, Казанда да, Язучылар берлегендә идарә әгъзасы булып утырганда да аралашып, уртак байлыгыбыз әдәбият турында сөйләшеп, дуслар ук булмасак та, рухи якынлык тоеп яшәдек. Калын пыялалы күзлеге ашаерактан күреп алып, акрын гына яныңа килеп, «Исәнме, Тәлгат!» дию үзенчә, Юзәйчә; тавышы күңелгә талгын рәхәтлек дулкыны йөгертә, яшисе килү дәрте өсти иде. Сабыр холыклы, тыштан тыныч, Ходай үзенә юмор хисен, телне сиземләү куәсен мул «тамызган» кеше бер үк вакытта утлы-давыллы, өермәдәй романтик холыклы (иҗатында) булып чыксын инде! Йөзенә иңгән тышкы ваемсызлык фәлсәфи-тарихи поэмалар язуга да комачауламый. Аңарда ике «мин» яшәде кебек. Берсе, күрәсең, тышкы дөнья өчен, әдәби әсәрләрендә ачылган эчке рухын, тетрәнүен, ярсуын күрсәтмәү өчен тышкы битлек, төскә юри чыгарылган битарафлык булгандыр.

Табигый хасияте белән ул философ, тарихчы, көрәшче һәм татар әдәбиятында барган эзләнүләр рухын алдан сиземләп, кешенең аң төпкелендә яткан катламнарга үтеп, яшәешнең гомумсимволик мәгънәләрен ачу юлларын күрсәтеп, сызымлап калдырган икән ләбаса.

Татар әдәбиятының, дөнья поэзиясенең гүзәл казанышларына таянып, И.Юзеев шигъриятебезне гаҗәеп матур образлар, камил сурәтләр белән баетты. Чал тарихлы татар поэзиясенә үз биеклеге булган сүз остасы булып кереп калды.

*Февраль, 2007*

**РӘДИФ ТИМЕРШИН**

# Боз өстендәге учак

*Якташым Илдар Юзеев вафатыннан соң*

Мәтрүшкәле яшел болыннарны
Кәфендәй ак карлар күмгәннәр.
...Синең эзләр калган болыннарда
Минем дә бар иде йөргәннәр.

Безнең авылларны аера бары
Ходай өйгән ташлар көшеле.
Ике яктан ике елга ага —
Икесе дә Гәрә исемле.

Гәрә буйкайлары — бөдрә таллык,
Карагаты гүя гәрәбә,
Әрәмәле Гәрә килеп кушыла
Гәрәбәле ямьле Гәрәгә.

Шуның сымак, туган якларымда
Таптым төсле рухи дустымны —
Синең моңлы, синең нурлы җырга
Тонык тавышым килеп кушылды...

Салкын боз өстендә учак ягып,
Гәрә суларында аккан егет,
Җырлый-җырлый гармун
тарткан егет —
Ул син идең. Бер дә юкка гына
Җырлар җырлап гармун сузмадың —
Җылытмакчы булдың бу дөньяны,
Эретмәкче күңел бозларын.

Синдәй кайнар хисле булсын диеп,
Исемеңне куштым улыма.
Саф хисләрдән җилләр искән заман
Ниләр өяр аның юлына?

Бәхетлеләр — сине ишеткәннәр,
Бәхетлеләр — сине күргәннәр.
...Янар чәчәк үскән болыннарны
Кәфендәй ак карлар күмгәннәр.

*22 декабрь, 2004*

**РӘҮФ ИДРИСОВ**

# Көчле шәхес, кодрәтле шагыйрь

Мәшһүр шагыйрь һәм соклангыч кеше Илдар абый белән очрашу һәм аралашу бәхете миңа да насыйп булды. Хәтерем ялгышмаса, аны беренче тапкыр 1986 елның февралендә Муса Җәлилнең 80 еллык юбилей тантанасында күрдем. Халык тулы залга Сибгат ага Хәким бер төркем язучы-шагыйрьләр белән килеп керде. Остазны яшьрәкләр чолгап алган иде. С.Хәким үз свитасы белән килгән дигәнрәк уй да күңелгә кереп калды, һәм шулардан бары тик «коеп куйган шагыйрь» Илдар абый гына ныклап хәтердә сакланган, чөнки ул бик хисле итеп шигырьләрен укыды. Кабарып торган болыт кебек кап-кара чәчле, күзлекле мөлаем кеше иде ул. Иҗаты буенча белгән шагыйрьгә охшаган икән дигән фикер дә шунда туды.

Туксанынчы еллар башында Уфаның «Рамазан» җәмгыяте, шагыйрьне олылап, Опера театрында аның иҗат кичәсен үткәрде. Ә инде 1995 елның җәендә «Болгарга сәяхәт» вакытында, якташларын сагынып, шагыйрь теплоходка үзе килде. Җыелган халык аны «Мәтрүшкәләр» җыры белән каршы алды. Иң күзгә ташланганы: шагыйрьнең гадилеге һәм аңа булган халык мәхәббәте булгандыр. Шул очрашудан соң Илдар абый белән якыннанрак аралашу мөмкинлеге туды. Шагыйрь сүзләре белән әйтсәк, «алыплар нәселеннән булган мәһабәт гәүдәле, талантлы һәм тәвәккәл шәхес» Марат Шәрипов җитәкләгән «Рамазан» төрки милли-агарту үзәге оештырган «Болгарга сәяхәт»ләрдә, Казанда «Сабантуй» гәзите редакциясендә, фәнни конференция, һәртөрле мәдәни бәйрәмнәрдә, Уфада аралашулар дәвам итте. Һәм алар беркайчан да тукталмас кебек иде...

1992 елда Уфаның «Шәрык» радиосында хезмәттәшлегем башлангач, журналист буларак та Илдар абыйга бик еш мөрәҗәгать итәргә туры килде. Ул һәрвакытта да бик теләп әңгәмәләрдә катнашты, радио өчен шигырьләрен укыды. Илдар абый якташларына бик хәерхаһ булды, иҗатын туган ягына җиткерергә омтылып яшәде. Уфада кайбер пьесаларын бастырып чыгару һәм «Нур» театрында куйдыру уе да бар иде аның. 1997 елның 26 март һәм 14 июлендәге хатларында ул шул хакта сүз кузгатты. Шагыйрь биргән пьесаларны театрга илтеп тапшырдым, ләкин шактый озак җавап булмады. Соңрак, әдипнең 70 яшьлек юбилее якынлашкан көннәрдә, «Нур» театрындагы бер пресс-конференциядә дә шул ук мәсьәләне рәсмирәк тә күтәрергә туры килде. Һәм, минемчә, дөрес җавап та алынды кебек: «И.Юзеев кебек үзенчәлекле драматургның пьесаларын куярлык режиссер әлегә бездә юк», — диделәр анда.

1998 елның мартында Илдар абый Тәфтилә апа белән Ә.Атнабаевның 70 еллык юбилеена килде. Нефтьчеләр мәдәният сараендагы юбилей кичәсендә ул бик матур чыгыш ясады. Башлап ул юбилярга якташы Әмирхан ага Еникинең «кош теле кадәр генә сүзен» тапшырды: «Шагыйрь кем? Мин белмим. Исемнәрен яхшы беләм. Беренчесе Тукай иде, соңгысы — Атнабай. Алар арасындагы бүтән бөекләрне санап тормыйм. Әмма Әнгам Атнабай да соңгысы булмас дип бик нык ышанам. Котлы булсын Атнабайлы шигърият бәйрәме!» Сүзен дәвам итеп, Илдар абый: «Атнабай, безнең төбәкләрдә «Һади Такташ» исемле әдәби берләшмә төзеп, безне әдәбиятка тартучы булды. Ул ни өчендер шинельдән килде. Бәлки, башка киеме дә булмагандыр, бәлки, ул Такташның шинель киеп төшкән рәсеменә гашыйк булгандыр?.. Мин бүген шуны гына әйтә алам: без икебез дә Такташ шинеленнән чыктык. Әмма мин үзем Әнгамның шинеленнән килеп чыктым әдәбиятка. Рәхмәт сиңа, Әнгам!»

Икенче көнне шагыйрь БДУ студентлары белән дә очрашты, тормыш һәм әдәбият, яшьлек һәм мәхәббәт хакында гамьле сөйләшү булды анда. Якыннан, ихлас аралашу булганга, бу очрашулар гомерлек истәлек булып калды. Уфа буйлап сәяхәт иттек, Салават батыр һәйкәле янында булдык. Аннан Әнгам абыйларга киттек. Анда да төп сүз поэзия, үткән тормыш сәхифәләре, шәхесләр хакында барды. Юбилярны арытмаска да ниятләп, Илдар абый белән Тәфтилә апаны үзебезгә дә алдык. Табын артында җылы сөйләшү, гәп тукталмады.

Тәфтилә апаны якыннан беренче күрүебез. Шуңа да ул игътибар үзәгендә булды. Илдар абыйдагы ифрат зур рухи көчкә ул да ия иде. Бер-берсен тын алышыннан, күз карашыннан аңлый торган, үзара ихтирамлы һәм игътибарлы соклангыч шагыйрь һәм аның хәләле иде алар. Шагыйрьлекнең олы вазифасын үтәүдә Тәфтилә апаның Илдар абыйга ышанычлы таяныч булуын да тойдык без. Ихлас, нәзакәтле һәм үзара гади мөнәсәбәтләр үрнәген күрсәтте алар. «Шагыйрь хәләле нинди булырга тиеш?» дигән бик четерекле сорауга да шунда җавап таптык кебек. Кунакханәгә илтеп куйгач та бергәләп гәпләшү озын-озак дәвам итте әле. Ерак юл алдыннан мөхтәрәм кунакларны арытмау кирәклеге генә бу утырышыбызга чик куйды. Бер хакыйкатькә дә төшендек: Илдар абыйны күбрәк белгән саен, аның шәхесенә һәм иҗатына ихтирамың арта бара икән.

Чираттагы Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә Казан Кремле белән янәшә урнашкан «Яңавыл» кафесында якташлар җыелды. Бу күркәм бәйрәмгә Илдар абый мине дә чакырды.

Кунакларны кафеның хуҗасы Каниф Гафур улы Фазылов каршы алды. Яңавылдан килгәннәр Казанда яшәүче педагог Ф.Исламов, җырчы Н.Нигъмәтуллин, профессор Ф.Харисов, халык шагыйре Илдар Юзеев белән очрашты. Шагыйрь сүзләренә язылган җырларны башкарып, Нәфкать якташлык хисләрен тагын бер кат яңартты. Табынның иң түрендә, аның йөзек кашы, әлбәттә, Илдар абый Юзеев булды.

Яңавыллылар өчен ул иң абруйлы зат, чын халык шагыйре һәм кадерле якташ иде. Шагыйрен кадерләгән халык үзе дә кадерле буласын бик дөрес аңлаган яңавыллылар Илдар абыйга булган ихтирам, горурлык һәм рәхмәт хисләрен җиткерергә омтылдылар.

Шагыйрьнең 70 яшьлек юбилеен каршылап, Башкортстандагы «Атна» гәзитендә, соңрак «Тулпар» журналында материаллар чыгардык. Илдар абыйның үзе тәкъдим иткән шигырьләре «Атна» гәзитенең 2003 елның беренче санында дөнья күрде. «Гомеремнең соңгы тамчыларын көйгә салган чагым тын гына...» дигән исем белән басылды алар.

Иң истәлекле, иң кадерле, иң сәгадәтле, ләкин, кызганычка каршы, соңгы очрашу 2002 елның җәендә «Болгарга сәяхәт» вакытында булды. Бу сәфәр шагыйрьнең якынлашып килгән 70 яшьлек юбилеена багышланган иде. Илдар абый белән Тәфтилә апа автовокзалга бик соң гына килеп төште. Кадерле кунакларны «Болгарга сәяхәт» программасы җитәкчесе Марат Шәрипов белән каршы алдык. Сәяхәт вакытында теплоходта Илдар абыйның иҗат кичәсе үткәрелде. Анда язучы һәм дипломат Вахит Юныс, Фәридә Кудашева, Марат Шәрипов, Тәфтилә апа, Әлфия Юлчурина, Радик Динәхмәтов һәм сәяхәтчеләр катнашты.

Шагыйрь хакында кереш сүз әйтү миңа насыйп булды. Чыгышымда мин И.Юзеевның бүгенге поэзиядә әйдәп баручы һәм классик булуын нигезләргә омтылдым. Моның өчен әсәрләрен дә мисал итеп китердем. Тукай, Такташ, Туфан, Хәкимнәрнең традицияләрен дәвам итеп һәм үстереп, үзенең шигъри мәктәбен булдыруы, әдип шәхесенең зурлыгы, гражданлык активлыгы, аның гуманизмы, поэтик осталыгына игътибарны юнәлттем. Дәлилләү өчен «Олы җанлы шагыйрь-әдипләргә...», «Өлкәнәйгән бер хис», «Кара каен», «Татарча туабыз...», «Уйлыйсыздыр» кебек шигырьләренә мөрәҗәгать иттем. Кичәдән соң да иркенләп аралашу мөмкинлеге булды. Һәм шунда Илдар абый: «Мин үзем дә мисал өчен нәкъ шул шигырьләремне алыр идем», — диде. Шундагы әңгәмәләребезнең берсендә ул үз чыгышы хакында әлегә кадәр билгесез сәхифәләргә дә тукталды: «Нәсел дигәннән, Р.Миңнуллин безне туганнар итеп саный. Аның әйтүенчә, Робертлар нәселендә дә Юзәйләр булган. Һәм алар дворян-морза булырга тиешләр. Башкаларның да шул хакта сөйләгәне бар. Дөресен генә әйткәндә, мин моңа ышанмыйм да. Минем әти көтүче, ятим булган. Миндә морзалык та юк. Әмирхан ага Еникинең бөтен кыяфәтендә морзалык иде. Ә мин авызымны ачсам, аннан һаман да бәрәңге күренеп тора». (Татар морзалары тарихы буенча белгеч Илдус Габдуллин әйтүенчә, Минзәлә якларында, чыннан да, Юзәй морзалар булган. — *Автор искәрмәсе*.)

Җан рәхәте булган мондый очрашулар беркайчан да тукталмас кебек иде, ләкин язмыш, тәкъдирне узып булмый. Илдар абый гомере буе романтик рухлы чын әдип, кешеләрне дөрес аңлап, аларга изгелек кенә теләүче әүлия, рухы гаять көчле шәхес, кодрәтле шагыйрь, зыялы, затлы һәм мөлаем кеше булып гомерлеккә күңелдә калды.

**РАЗИМ ВӘЛИУЛЛИН**

# Мәңге сүнмәслек янгын

2004 елның 21 декабрендә Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев вафат булды

Бер хәл төшкә керде:
Дөрләп утта яндым,
Ялкыннарда пешеп уяндым.
Котимәнгеч утлар
Капты болытларга.
Шатлыкларга аны юрадым.
Кайгым яна диеп куандым.
Күтәренке күңел,
Яшәү дәрте белән
Уң аякка бастым, бисмилла...
Шул мәл хәбәр иңде:
Илдар Юзи үлде.
Утка чумдым өндә, һушымда.
Йөрәгемне тоттым кушкуллап.
Мәңге сүнмәс янгын,
Чиксез ачы хәсрәт
Ялмап алды җанны, бәгырьне.
Үлем үкенечле,
Әҗәл үткен тешле,
Ача гына тора каберне.
Исәннәргә сала җәберне.
Көрәште ул һаман
Үҗәт үлем белән.
Күләгәсен аның гел тойды.
Ялталарга бардык
Әҗәл адашсын дип,
Әйтте: менә, качып котылдык!
(Ә Казанга кайтып тотылды...)
Татар ятим хәзер,
Якыннары үксез,
Олуг шигъриятем, син ятим.
Ул гомере буе
Сиңа бер карусыз
Хезмәт итте, газиз милләтем!
Илдар абый, синсез без ятим.
Алтын баганалар
Ава гына тора.
Агач терәүләрдә калабыз.
Бар кыйммәтләр
Ваклап сатылганда,
Туармы соң алтын балабыз?!
Дип, сүнмәс янгыннарда янабыз.

*22 декабрь, 2004*

**ИРШАТ СИРАҖЕТДИНОВ**

# Эх, ул чаклар!..

Шул чакларны хәзер
Әллә нигә бигрәк
сагынам.

*Р.Сафин*

Үткән гасырның сиксән икенче елының 15 феврале Башкорт академия театрында шагыйрь Р.Сафинга 50 яшь тулуга багышланган җырлы-моңлы тамаша булып истә калган. Ул вакытта шагыйрьгә, дөресен әйткәндә, чын шагыйрьгә мөнәсәбәт бөтенләй башкача иде. Халык үз күңеленә якын әдипләрне олылый, зурлый белә иде, укучы күңеленә матур шигырь яисә моңлы җыр булып кергән шагыйрьләр бар иде ул заманда.

Әле дә көн кебек истә, Рафаэль абыйның бәйрәме белән котларга килеп җиткән җан дуслары — Туфан Миңнуллин, Илдар Юзеев һәм юбиляр үзе ярсып-ярсып гармунда халык көйләрен уйнап тамашачыны хәйран иткән иделәр. Нинди шәп замана булган икән, ә? Җыр-моң өләшеп, тел-лөгать алмашып яшәгән икән әдипләр!

Дуслык дигән изге чишмәгә кем иң башта сукмак салган — татармы, башкортмы, аны тикшереп вакланмадылар, шагыйрьләргә ул мөһим түгел иде, аларның белгәне, аларның табынганы югары шигърият иде.

Әле әйтеп киткәнемчә, 1982 елның кышында мин фәкыйрегез, Уфа дәүләт сәнгать институтын тәмамларга йөргәндә, филармониядә Илдар Юзеев поэмасы буенча үзем язган сценарий нигезендә диплом эше куйган идем.

Илдар абыйның шигърияте шәп, үзе җыр кебек, артистлар да әле ул вакытта исемсез, әмма бик өметле җырчылар Фәнүнә Шәйдуллина (соңыннан Сираҗетдинова), Шамил Хәмәдинуров, Ридәл Фәтхиев, баянчы Роберт Тимербаевларның ярсып иҗат иткән вакытлары. Шул сценарийны күтәреп, «Агыйдел» кунак йортына барып кердем Илдар абый номерына. Мостай абый әйтмешли, «нигә сандугачка буй-сын», мине буйга артык мәхәббәт булмаган, күзлекле әдип — Илдар абый үзе каршы алды. Минем сценарийны дикъкать белән карап чыкты, бик разый калды, уңышлы булыр дип ышанам, дип, хәтта култамгасын куйды.

Миңа, әле өлгереп тә бетмәгән яшь кешегә, тигез, тиң карап үзен әллә кемгә куймый якын итүенә мин бик хәйран булдым. Элек тә мин Илдар аганың шигърияте белән якын таныш идем. Ә ары таба безнең танышлык дуслыкка әверелеп озын-озак еллар дәвам итте.

Тагын бер гүзәл сәхифә. 1991 елда филармония залында бөек Хәсән Туфанга 90 яшь тулуга багышланган кичәдә катнашты Илдар абый Роберт Миңнуллин белән икәүләп. Ул кичәне ике шәп шагыйрь Нажар Нәҗми һәм Әнгам Атнабай алып бардылар. Нинди шәп әдипләр һәм артистлар катнашты ул кичәдә! Гыйлемдар Рамазанов, Шәриф Биккол, Фәния Чанышева, Фәридә Кудашева, Бәхти Гайсин, Илфак Смаков һәм тагы да бик күп атаклы шәхесләр. Күңеле булып, Казанда узган кичәгә бик рәнҗеп торды Илдар абый ул кичен. Бик нечкә күңелле, дөньяга сагышлы күз, әрнүле йөрәк аша караган әдип иде Илдар ага. Соңгы елларда дөньялар буталып китте, уттай якын күршеләр арасына ятлар керде, Казан—Уфа арасына күләгә ятты. Илдар абый бик авыр кичерде бу хәлне. Ул бит үзе дә Башкортстанда туып үскән асыл зат. Тик ничек кенә булмасын, дөньялар ничек болганмасын, шагыйрь үзе, аның якты истәлеге, асыл сүзе йөрәкләрдә яши, яшәр, яшәячәк.

**ЭЛЬМИРА ҖӘЛИЛОВА**

# «Бик юаш мин...»

**Өйдә ятсам, саргаям**

*— Илдар Юзеев иҗат дөньясына ничек килеп керде?*

— Мин шигырьдән алда пьесалар язарга тотынганмын. 9 яшемдә «Алсу гөлләр» исемле пьеса язып, шуны мәктәп балалары белән җәй көне урамда куйдык. Бик кызыклы булып хәтергә сеңеп калган. Ә 10 яшьтә Яңавыл районы газетасында «Бертуган Юзеевлар иҗаты» дигән баш астында Нил абыйның шигырьләре һәм минем беренче шигырем басылды. Ә чын-чынлап иҗатка тотыну Казанга килеп укый башлагач булды. С.Хәким, Х.Туфаннар, институтта эшләп килгән әдәбият түгәрәгенә килеп, безне үзләре эзләп тапты. Шулар мине бу серле дөньяга алып кереп китте.

*— Татар язучысының язмышы бәхетлеме?*

— Халык бәхетле булса, язучы да бәхетле, халык еласа, язучы да елый. Дания Заһидуллина дигән укытучы татар әдәбияты методикасында: «Рәдиф Гаташның романтикасы — оптимистик, Илдар Юзеевныкы — пессимистик», — дип язып чыккан һәм шушы ялган фикерне укучыларга тарата. Ничек минем шигърият пессимистик була алсын? Әлбәттә, минем трагедияләрем — аяныч язмышлы кешеләр турында язган әсәрләрем күп. Сырхауханәдә ятканда язган хәсрәтле шигырьләрем бар. Әмма язучы иҗатының бер этабына гына нигезләнеп мондый фикер әйтү, минем уйлавымча, һич дөрес түгел. Мин бары тик булган вакыйгаларны алсу төсләргә манмый гына укучыларга җиткерергә омтылам. Халык бәхетле булганда, аеруча татар бәйрәмнәре вакытында мин бигрәк тә бәхетле. Ул вакытта шигырьләр дә җырлап туа.

*— Сез инде лаеклы ялдагы кеше, үзегез бүгенге көндә дә эшләвегезне дәвам итәсез. Чит илдә яшәп иҗат итсәгез, кадерегез күбрәк булыр иде кебек тоелмыймы?*

— Эшкә йөрүем акча җитмәгәннән түгел, кешеләр кирәк булганнан. Кызык түгел миңа аралашмыйча ялгыз яшәү. Өйдә ятсам, саргаям мин. Болай, ичмаса, йөреп кайтам, кешеләр арасында булам. Хөкүмәтебезгә рәхмәттән башка сүзем юк. Кадерем дә бар, хөрмәтлиләр дә. Ә чит илләре үзләренә булсын. Минем табигатем анда тартмый.

*— Әгәр сайлау мөмкинлеге булса, Казанның кайсы җирендә яшәр идегез? Шәһәр читенә авылча бер кечкенә өй салып, шунда яшисегез килмиме?*

— Мин инде 3–4 тапкыр күчеп караган кеше. Казанның төрле почмакларында яшәргә туры килде. Бар җирдә дә ошый миңа. Ә иң кызыклысы, күчкән саен яңа кешеләр белән танышасың. Ә авылча яшәүгә килгәндә, юктыр, мөгаен. Ни өчен дигәндә, без авыл балалары булсак та, авылдан киткәнбез, холкыбыз, рухыбыз белән ерак без аннан. Дөрес, кайчак ул шигырьгә килеп керә, әмма бу авылны түгел, анда үткән әкияти балачакны, серле яшьлекне сагыну гына...

**Җәен илһам сирәк килә...**

*— Ә ул шигырьләр елап туамы, җырлапмы?*

— Кайчан ничек инде, үзем моңсу булганда, елап туа. Җырлап туганнарын композиторларыбыз эләктереп алып, шундук җыр язып ташлыйлар.

*— Иҗат өчен кайсы ел фасылы уңай?*

— Җәй көне нишләптер миңа илһам сирәк килә. Шигырьләр язам, әмма зур әсәрләргә (поэма, пьесалар) тотына алмыйм. Ә менә яз һәм көз көннәрендә минем иҗат чишмәм ургый башлый. Әмма минем бер гадәтем бар: язган зур әсәрем басылмыйча торып, икенчесен яза башламыйм.

*— Әле бит Сез драматург та. Кайсы жанр Сезгә җиңелрәк бирелә?*

— Шигырь ул — минем стихиям. Шунлыктан аны язу җиңелрәк. Мин көн дә шигырь язам, кемгә генә, кая гына барсам да, кучтәнәчкә шигырь язып барам. Берсен дә җыеп бармыйм, эзсез югалалар. Ике жанрда эшләү, бер яктан, катлаулы булса, икенче яктан, алар бер-берсенә ярдәм итә, бер-берсен тулыландыра.

*— Сезнең күңелне нәрсәләр күтәрә һәм нәрсә хәтерегезне калдыра?*

— Ел ахырында «Иң күп укылган китап» дигән йомгаклар була. Поэзия буенча 4 ел минем китапларым беренче урынга чыкты. Укучыларымның барлыгы, «шигырь укылмый» дип сөрән салган заманнарда аларның кимемәве, киресенчә, арта гына баруы күңелгә сары май булып ята. Җанны бер генә нәрсә тырный. Ул да булса татар халкының бер сәер гадәте: башка халыклар белән ул шулкадәр тату, дус яши, ә үзара тыныша алмый. Бер-берләреннән көнләшү, читләшү, бер-берләренә юл бирмәү

күп кенә җитәкчеләребезгә үрләр яуларга да аяк чала. Нигәдер алар һаман бер-берсен юк итәргә тырыша.

**Хуҗалык хатын җилкәсендә**

*— Еш сырхаулыйсызмы, ничек дәваланасыз?*

— Яшь вакытта миндә авыру тапканнар иде. Гомер буе шуның белән көрәшеп яшим. Хәер, тән сызлавына түзеп була ла ул, җан сызлавы кыен.

*— Сез гаиләдә нинди кеше?*

— Бик юаш мин. Әгәр хатын булмаса, ул мине карап, тәрбияләп тормаса, бу дөньяда яши дә алмас идем. Хуҗалык эшләренең берсен дә белмим, бөтенесе хатын җилкәсендә. Кечкенә чакта үз өебез юк иде, кеше фатирында да тордык. Әткәй сугышта 4 ел йөреп кайткач кына өй салырга тотындык. Бер балта остасы белән Нил абый өй салдылар. Мине кечкенә дип якын җибәрмәделәр. Хәзер бик үкенәм шул чакта балта эшенә өйрәнеп калмаганыма. Ә үзем гаиләмнән, гаилә тормышымнан бик канәгать, алар да миннән канәгатьтер дип уйлыйм.

*— Ә балаларыгызга карата Сез нинди әти?*

— Әйтәм ич, бик юаш мин. Шулай да олы улым минем юлны — язучылыкны сайлады. Салават Юзеев исеме, бәлки, кемнәргәдер таныштыр. Бүгенге көндә ул урысча ике китап авторы.

*— Оныгыгыз Самат йомшак ягыгызны белеп, Сезнең янда сырпаланамы?*

— Ул сабый килеш бик зур югалту кичерде. Әнисе үлде. Хәзер ул әтисе белән бергә бездә яши. Аның белән аралашу, уйнау, шаяру — иң яраткан шөгылем.

*— Аңа карап үзегезнең балачагыгызны искә төшерәсезме?*

— Әйе, әмма хәзерге чор балалары бездән бик нык аерыла. Алар күпкә акыллырак. Без хыялый идек, алар — реалист. Хыялыйлык, юләрлек дигәннән, балачактан бер кызыклы хатирә искә төште: авылда 6–7 нче класста укучы 4 бала үзебез көймә ясадык һәм, шул көймәгә утырып, Гәрә елгасының кайда барып тоташуын ачыкларга чыгып киттек. Әнкәйләргә 1–2 көнгә дип киткән идек, бер атна йөреп, талчыгып кайтып кердек. Эт күрмәгәннәрне күрдек, әмма бу вакыйга поэмага әверелде. Озак еллардан соң «Өчәү чыктык ерак юлга» исеме астында балачак хатирәм кабат яңарды.

*— Илдар абый, Сез тәмлетамакмы? Нәрсәләр ашарга яратасыз?*

— Татар халык ашлары — токмачлы аш, өчпочмак, бәлеш. Ризык талымламыйм. Макаронны да бик тәмләп ашап куям. Хатыным Тәфтилә һәр көнне берсеннән-берсе тәмле ризыклар пешереп сыйлап кына яши.

**Ходайдан тагын берничә генә ел сорыйсым килә**

*— «Сәхнә» журналы белән Сезне нәрсә бәйли?*

— Сәхнә ул минем тормышымда ниндидер бер серле образ. Балачакта үзебезнең авыл укытучылары йә, булмаса, Минзәлә театры спектакльләр куйганда, иң алгы урыннарга кереп, «оялап», йотлыгып карый идем. Үзебезнең урманнан кисеп алынган чыршы шул сәхнәгә менгәч, әкияти булып, могҗиза булып күренә иде. Шул вакытлардан ук сәхнә күңелгә сеңеп калган. Журналның исеме дә шуңа якын тоела.

*— Бәлки әле, Сез артист булырга да хыяллангансыздыр?*

— Бик зур хыялым иде. 7 нче класста вакытта үзем язган «Моңлы җыр тавышы» исемле пьесамда хәтта Сәлим ролен дә уйнаган идем. Бәлки, шул вакытта үземнән бик үк уңышлы артист чыкмасын аңлаганмындыр. Аннары инде шигырь белән җенләнә башладым. Әмма үкенмим. Автор булсам да, мин сүз артисты булганмын. Үзем тудырган һәр образ, һәр герой булып мин үзем яшим, үзем уйныйм. «Кыр казлары артыннан» пьесасында да мин бөтен геройны башта үзем «уйныйм», алар барысы да мин.

*— Сезнең өчен бу дөньяда иң зур бүләк нәрсә булыр иде?*

— Аллаһы Тәгаләнең миңа шушылай озын гомер бирүе ул — үзе зур бүләк. Биргәненә шөкрана, әмма әле минем Ходайдан тагын берничә генә ел сорыйсым килә. Тормыштан туеп булмый бит — яшәү көче бар, иҗат ялкыны бар. Язасы әйберләрем, әйтәсе сүзләрем шактый...

**РАШАТ НИЗАМИ**

# Иҗат — татлы газап

*— Илдар абый, Сезнеңчә, язучылыкның «чишмә башы» кайларга барып тоташа? Ни өчен кайберәүләр трактор-комбайн белән җенләнә, берәүләр балта остасы һөнәрен сайлый, кемдер галим-голәмәлеккә тартыла, кемдер техника-компьютер эшләренә маһир була? Ә менә әдип кешенең иң яраткан ганимәте, омтылышы, бөтен барлыгы — каләм, ак кәгазь, уй-фикерләр дөньясы.*

— Балачакта мин, шигырьләр язсам да, шагыйрь булуыма ышанмыйча, театр сәхнәсенә менү турында хыялландым. Үзем язган пьесаларда уйнап, сәхнәгә дә чыктым әле. Әмма мин барыбер профессиональ театр сәхнәсенә менә алмадым, ул өлкәдә сәләтем чамалы икәненә төшендем. Хыялыма ирешә алмасам да, мин күңелем белән артист, сүзләр артисты булып калдым. Шигъри сүзләрем белән мин Хәйретдин Мөҗәй кебек дөрләп утта да янам, Зөфәр булып җырлыйм да, Резидә булып сөйгән ярымны ташлап та китәм, Җәлил булып Мефистофель белән бәхәсләшәм дә, Ясминә булып кыр казлары артыннан талпынам да, яраланган бөркет булып күктән егылып төшәм, кирәк икән, маймылга, җенгә дә әйләнәм...

Шагыйрьлекнең «чишмә башы» кайда? Әнкәйнең бишек җырында. Мандолинада көйләр уйнап, ул ритмны тоярга өйрәтте. Шигырьнең башы ритмда. Ритм ул — шигырьнең йөрәк тибеше. Йөрәк туктаганда да аның ритмы шигырьләреңдә кала.

Илле еллык иҗат гомеремдә мин беркайчан да башыма, йөрәккә ял бирмәдем, газета-журнал редакцияләрендә җаваплы секретарь, поэзия бүлеге мөдире, әдәби хезмәткәр булып «Ялкын», «Казан утлары», «Чаян», «Сабантуй» редакцияләрендә, Язучылар берлегендә штатта торып эшләдем.

Илле ел штатта эшләү дәверендә мин беркайчан да иҗат итүдән туктамадым. Күпчелек әсәрләрем эштән соң яки бер айлык ял вакытында, яки лаеклы ялга чыккач язылган.

Чыннан да, ничек түзә бу баш һәм йөрәк?!

Бәлки, иҗат — тәнгә вә җанга үзе ялдыр...

*— Шигырь кайчан, ничек туа? Уйлап чыгарырга кирәкме аны, әллә кеше җанының аңлатуга ансат кына бирелми торган илаһи бер рухи халәтеме?..*

— Шигырь, бала кебек, теләсә кайсы вакытта: төнлә дә, көндез дә туа. Ниндидер бер фикер көндез зиһенгә эләгеп кала да төн уртасында йокыдан уята. Ут кабызам, каләм алып язарга тотынам. Күп вакыт яткан килеш тә. Шигырь тусын өчен, әлбәттә, тынычлык, ялгызлык зарур. Әмма минем шау-шулы студентлар торагында да, җыелышларда да язылган шигырьләрем бар. «Җырлар бирәм» дигән шигыремне мин Муса Җәлил китабына язып, бүлмәдәш дустыма бүләк иткән идем. Соңыннан ул экспромт шигырь биштомлыгыма да керде.

Композитор Заһидулла Яруллинга җитмеш яшь тулган көнне, аларның өендә мәҗлестә утырганда, ул үзе иҗат иткән «Тукай маршы»н пианинода уйнады. Көй мине шулкадәр сихерләде, өстәлдәге салфетканы алып, шунда ук шигырь яздым.

Төштә дә шигырь язган бар. Авылыма кайтып барам, имеш. Менә хәзер әти-әни каршыма чыгар... Мин аларны кочакларммын... Уяндым. Каләмгә тотындым. Барысы да төштә генә... Әти-әниләр мәңгегә кайтмаска киткәннәр.

Кайбер шигырь җитлекмичә, өлгермичә дөньяга килә: барыбер тудырасың, ә аның җаны юк. Аны, ак биләүгә-кәгазьгә төрмичә, шундук юк итәм, ертып ташлыйм. Чөнки ул җанда яралмаган, кулына алса да, укучы күңеленә ятмаячак.

Әсәр иҗат ителү мизгелләре минем өчен дә аңлашылмый торган серле бер халәт. Зур күләмдә поэма яки драматик әсәр язу авыр да, газаплы да, рәхәт тә. Материал инде табылган, әмма сюжеты, геройлары ачыкланмаган. Бәхетсез бер бәндә кебек, кайгыда башыңны түбән иеп йөрисең. Менә берзаман әсәргә ачкыч табасың, өстәлгә, каләмгә тартыласың. Җирдәге ваклыклардан, кечкенә-зур мәшәкатьләрдән ычкынасың. Дөньяда синнән дә бәхетле кеше юк! Үзеңне намаз өстендә утырып, Күк белән бәйләнешкә кергән изге зат итеп тоясың... Мондый халәттә урамга чыксаң, машина таптап китмәсен дип куркып, сакланып йөрисең. Алла сакласын, башланган әсәрең тәмамланмый калса...

Әсәргә соңгы ноктаны кую — иң бәхетле мизгелдер. Әмма үзеңне бераздан бушап калган, иң якын дусларыңнан, сөйгән ярыңнан аерылган кебек, ямансу тоясың. Чөнки җаныңның яртысы геройларыңа күчкән.

Үтенәм,
китегез ялгызым калдырып.
Нур тама каләмем очыннан.
Күңелемнән аккошлар очырам,
Шашынам, тилерәм, очынам.

Үтенәм,
китегез ялгызым калдырып.
Мин —
Күкнең җиденче катында.
Бу мәлдә кирәкми берсе дә:
Сөйгән яр, дусларым, алтын да.

Язучы иҗат иткәндә үзенә читтән карап тора алмый. Хатыным Тәфтилә беркөнне миңа болай диде:

— Сиңа карап торам-торам да тагын бер кат карап куям. Әллә нинди сәер затлар сез язучылар... Үз тормышыгызда болай да бит кайгы-борчуларыгыз җитәрлек, ә сез булмаган геройларның кайгыларын уйлап чыгарып, шулар өчен кайгырып газап чигәсез. Ничекләр түзәдер ул йөрәк дигәнегез?..

Чыннан да шулай бит.

*— Автор белән аның геройлары арасына шартлы рәвештә тигезлек билгесе куярга мөмкинме? Әллә болар икесе ике нәрсәме?.. Автор бит берәү генә, ә аның геройларында мең төрле холык, бер-берсен кабатламый торган йә бәхетле, йә фаҗигале язмышлар...*

— Кайвакыт әсәреңнең герое белән бер булып яши башлыйсың. «Очты дөнья читлегеннән» трагедиясенең финалына җиттем. Тукай үлем алдыннан... авыру... Шул чакта үзем дә, үпкә белән авырып, бер атна, язудан туктап, авыр сулап, йөткереп яттым. «Сирень чәчәге»ндә Фәнүдәнең авырган чагын язганда, үзем дә салкын тидереп егылдым. Героең бик авыр хәлдә кала, ул еламый, ә синең күзләреңнән яшь ага. Комедия язганда, иң кызык дип уйлаган урыннарында рәхәтләнеп көләсең. Ә тамашачы спектакль барышында мыегын да селкетми, бөтенләй син кызык дип уйламаган урында көлә. Тоташ драматик, трагик әсәрләр язу йөрәккә авырлык китерүе ихтимал. Андый чакта комик әсәргә, шаян шигырьләргә тотынам.

*— Ялгышмасам, Сез тәрҗемә эшләре белән артык мавыкмадыгыз шикелле. Бу нәрсәдән килә?*

— Илле еллык шигърияттә яшәү гомеремдә тәрҗемә белән шөгыльләнмәдем диярлек. Чын милли шагыйрьне башка телгә күчерүне йөрәгем кабул итмәде. Хәлбуки үзем бала чакта Пушкиннарны татарча укып үссәм дә.

Чын шагыйрьне үз телендә уку — мәхәббәткә, ә тәрҗемәдә уку мәхәббәт белән шөгыльләнүгә тиң.

Сандугачны да башка телгә тәрҗемә итеп булмый. Минем өчен ул татарча сайрый.

*— Татар әдәбиятында Сезнең хезмәтегез тау чаклы диярлек. Моңа сокланмый мөмкин түгел...*

— Шагыйрь иҗатына хезмәт дигән рәсми сүз туры килми. Иҗат итүнең серлелеге югала. Иҗат ул барыннан бигрәк рухи халәт. Шигырь туганда матди дөньядан ычкынып, тәннең барлыгын тоймыйсың, яныңдагы җансыз һәм җанлы нәрсәләрдән аерылып, кайдадыр фәрештәләр янына күтәреләсең. Тукай шигырь язуны юкка гына фәрештәләр белән сөйләшүгә тиңләмәгән.

Әгәр кем дә булса сине шул халәттән бүлеп, гадәти эш турында берәр сүз әйтсә, фәрештәләр яныннан котсыз җиргә бәреп төшерелгән кебек буласың...

**ЙОЛДЫЗ**

# Карларга да бүген кайгы сарган...

Бәгырьләрне телеп хәбәр килде:
Бер моңлы кыл кинәт өзелгән.
Күз яшьләре дәрья булып акты
Татар милләтенең күзеннән.
Өзелер шул,
Нечкә иде ул кыл —
Болай да бит күпме түзелгән.
Дөнья пычрак,
Шагыйрь күңеле ап-ак —
Кагыласы калган саграк.
Олы күңелләрне аңлар өчен,
Вакытында күреп санлар өчен
Безнең җаннар мәллә ваграк.
Үзе гали, үзе гади иде,
Булгандыр, шәт,
Изге пәйгамбәрләр нәселеннән.
Андыйларның олы йөрәгенә
Саекмас моң кереп яшеренгән.
Кинәт үлде, диләр.
Юк-юк, түгел кинәт —
Шагыйрь йөрәгенә күпме кирәк?!
Шагыйрьдә бит иң яралы йөрәк.
Без барасы юлга җырларын да
Гөлләр итеп тезгән.
Без аларны күрми үттек мәллә...
Ничек түзсен шагыйрь шушы хәлгә?
Йөрәге дә ярылгандыр аның
Нәкъ шул мәлдә.
Ул гөлләр бит гади гөлләр түгел,
Шыткан алар йөрәк каныннан.
Милләтенең киләчәген уйлап,
Болай да бит күпме янылган...
Үз шагыйрен күмде бүген халкым,
Җанны җылытучы кимеде шул.
Бүген бигрәк салкын.
Кар өстендә кара яра булып
Кабер калыкты, яңа.
Соңлап әйткән гафу сүзе булып
Өсләрендә канәферләр яна.

Өсләренә күз яшьләре булып
Карлар ява.
Ак карларын түгеп елый Казан —
Карларга да бүген кайгы сарган.

*23 декабрь, 2004*

**ТӘФТИЛӘ ЮЗЕЕВА**

# Сагынып уйлану...

Без Илдар белән 46 ел бергә яшәдек. Шул гомер эчендә аның бер генә тапкыр да кимсетерлек, рәнҗетерлек авыр сүз әйткәне булмады. Илдар бик игелекле, мәрхәмәтле кеше иде.

Бала вакытыннан ук урын өстендә яткан авыру әни белән үсеп, үзе дә гомере буе сәламәтлеккә туймыйча сызланып яшәсә дә, ул тормышның тәмен, кадерен белеп шаян-җор сүзе белән тирә-яктагыларның күңелен күтәреп яшәде.

Мин Илдарга кияүгә чыкканда татарча авыр укый идем, татар әдәбиятын белми идем, бу, әлбәттә, аның бәхетен арттырмагандыр. Тора-бара өйрәндем, укый башладым һәм Илдарның чын шагыйрь, зур шагыйрь икәнен аңладым. Кино, спектакль, әдәби әсәрләр турында фикерләребез туры килә иде. Матурлык ярата иде Илдар, бакчадагы чәчәкләргә гел соклана иде, хәтта аларны өзәргә кызгана иде.

Илдарны олысы-кечесе үз итте. Чөнки ул кешенең уңышына шатланып яхшы, җылы сүз әйтә белә торган олы җанлы кеше иде. Әле яңа гына каләм тибрәтә башлаган балаларга да, яшьләргә дә игътибарлы булды ул. Үзе дә каләмдәшләренең, якташларының, шәкертләренең җылы мөнәсәбәтен тоеп яшәде. Бу китапны әзерләгәндә дә аларның өлеше зур булды. Басманы әзерләүгә, дөньяга чыгарырга ярдәм иткән барлык кешеләргә, Татарстан китап нәшриятына без гаиләбез исеменнән ихлас рәхмәтебезне белдерәбез.

Вакыт ага. Инде Илдарны югалтуга да дүртенче ел китте. Бу югалту белән һич килешәсе килми, ләкин шагыйрь йөрәге моны сизгән, ул изге җан мине юатырга, кайгымны җиңеләйтергә тырышкан. Аның 2004 елда язылган шигыре шул хакта:

# Юату

Җан сөйгәнен югалтканнар,
Ярдәм итмәс юату.
Аңлыйм, дөньяда бу — сезнең
Иң-иң авыр югалту.
Узганны сагынып уйлану,
Үкенечле сызлану...
Картлыктамы, яшьлектәме —
Зур газап — ялгыз калу.
Төшеңдә генә булса да
Бер күрергә тилмереп...
Мәңгелеккә аерылуга
Булмыйдыр ул күнегеп.
Тик бер генә сызлангыч уй
Күңелне юатадыр:
Җан сөйгәнен тапкан гына
Үз парын югалтадыр.
Гомернең гүзәл еллары
Яратышып узган ич.
Югалткан табалмас инде...
Тапмаганнар кызганыч...

**ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ**

# Мәңгелек җыр

*Илдар Юзеевка[*]*

Халкым, син моңнан яралган,
Җырда телең ачылган —
Язмышың булып тезелгән
Шагыйрьләр һәм гасырлар.

Халкым, син моңнан яралган,
Җырда рухың чагылган —
Канатларың күтәрелгән
Кол Гали кочагыннан.

Халкым, син моңнан яралган,
Җырыңда кайнар каның —
Һәр яңа чорда кабынып
Яңа Тукайлар җаны.

Халкым, син моңнан яралган,
Җырыңда йөз аклыгы —
Җәлилләрнең, Туфаннарның
Батырлыгы, сафлыгы.

Халкым, син моңнан яралган,
Җырың гел яңарасы —
Бездән киләчәккә үтеп,
Мәңгелеккә барасы!

*15 гыйнвар, 1983*

## АВТОРЛАР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ

***Минтимер Шәймиев*** (1937) — Татарстан Республикасы Президенты.
***Шәкүрә Юзеева*** ( 1905–1986) — Илдар Юзеевның әнисе.
***Фоат Динов*** (1933) — Илдар Юзеевның авылдашы, сабакташы.
***Назир Зыязов*** (1946) — Башкортстанның Яңавыл районы хакимияте башлыгы.
***Фираз Харисов*** (1952) — педагог, педагогия фәннәре докторы, ТРның һәм РФнең атказанган мәктәп укытучысы.
***Эрот Зарипов*** (1938) — график, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе.
***Салават Юзеев*** (1960) — язучы, кинорежиссер.
***Самат Юзеев*** (1992) — Илдар Юзеевның оныгы.
***Айдар Юзиев*** (1958) — философ, философия фәннәре докторы.
***Шәүкәт Галиев*** (1928) — Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Г.-Х.Андерсен исемендәге халыкара Почетлы диплом иясе.
***Роберт Әхмәтҗанов*** (1935) — шагыйрь, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***Хәсән Туфан*** (1900–1981) — шагыйрь, ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***Ләбибә Ихсанова*** (1923) — язучы, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре.
***Альберт Яхин*** (1931) — әдәбият белгече, язучы, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре.
***Туфан Миңнуллин*** (1935) — драматург һәм дәүләт эшлеклесе, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык язучысы, РСФСРның К.С.Станиславский исемендәге, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты.
***Нәҗип Әсәнбаев*** (1921) — Башкортстанның халык язучысы, Башкортстанның С.Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***Рөстәм Мингалим*** (1937) — язучы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***Суфиян Поварисов*** (1924) — язучы, филология фәннәре докторы, Татарстанның һәм Башкортстанның атказанган фән эшлеклесе.
***Сибгат Хәким*** (1911–1986) — ТАССРның халык шагыйре, ТАССРның Г.Тукай исемендәге, РСФСРның М.Горький исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты.
***Марс Шабаев*** (1933–2008) — шагыйрь, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***Миргазиян Юныс*** (1927) — язучы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***Миркасыйм Госманов*** (1937) — тарихчы, Татарстан ФАнең хакыйкый әгъзасы, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе.
***Мирсәет Яруллин*** (1938) — композитор, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе.
***Равил Тумашев*** (1923) — режиссер, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***Гайнулла Шакиров*** (1925) — хәрби эшлекле, генерал-майор.
***Роберт Миңнуллин*** (1948) — Татарстанның халык шагыйре, дәүләт эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Г.-Х.Андерсен исемендәге халыкара Почетлы диплом иясе.
***Мәсгут Имашев*** (1930) — композитор, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе.
***Шәүкәт Биктимеров*** (1928) — актер, ТАССРның һәм СССРның халык артисты, ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***Айрат Арсланов*** (1928) — актер, ТАССРның һәм РСФСРның халык артисты, ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***Ренат Харис*** (1941) — Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Россиянең Дәүләт премиясе лауреаты.
***Нәҗибә Ихсанова*** (1938) — актриса, ТАССРның һәм РСФСРның халык артисткасы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***Саимә Ибраһимова*** (1928) — язучы-тәрҗемәче, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре.
***Исламия Мәхмүтова*** (1939) — актриса, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисткасы.
***Хәлил Мәхмүтов*** (1939) — актер, ТАССРның халык артисты.
***Әхмәт Гадел*** (1942) — шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.
***Фәнис Яруллин*** (1938) — шагыйрь, Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***Рәдиф Гаташ*** (1941) — шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.
***Рабит Батулла*** (1938) — язучы, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***Мансур Шиһапов*** (1940) — шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.
***Зөлфәт*** (Дөлфәт Маликов) (1947–2007) — шагыйрь, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***Ризван Хәмид*** (1941) — драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.
***Марсель Галиев*** (1946) — язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
***Ләбиб Лерон*** (1961) — язучы Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Муса Җәлил исемендәге яшьләр премиясе лауреаты.

***Ркаил Зәйдулла*** (1962) — шагыйрь, Татарстан Республикасының М.Җәлил исемендәге яшьләр премиясе лауреаты.

***Җәүдәт Сөләйманов*** (1955) — техник фәннәр докторы, профессор, шагыйрь, Татарстан Республикасының М.Җәлил исемендәге яшьләр премиясе лауреаты.

***Шамил Маннапов*** (1938) — язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

***Мөхәммәт Мирза*** (1953) — шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

***Шаһинур Мостафин*** (1948) — язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

***Люция Фаршатова*** (1954) — журналист.

***Вакыйф Нуриев*** (1958) — язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

***Ленар Шәех*** (1982) — шагыйрь, журналист.

***Ләйсән Мөгътәсимова*** (1988) — Казан дәүләт университеты студенты.

***Рафаэль Мостафин*** (1931) — әдәбият галиме, тәнкыйтьче, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

***Тәлгат Галиуллин*** (1938) — язучы, әдәбият галиме, ТР ФАнең мөхбир әгъзасы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе.

***Рәдиф Тимершин*** (1947) — шагыйрь, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

***Рәүф Идрисов*** (1954) — журналист, филология фәннәре кандидаты.

***Разим Вәлиуллин*** (1942) — шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

***Иршат Сираҗетдинов*** (1954) — режиссер, Башкортстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

***Эльмира Җәлилова*** (1979)— журналист, шагыйрә.

***Рашат Низамиев*** (1950) — язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

***Йолдыз Шәрәпова*** (1960) — журналист, шагыйрә.

***Тәфтилә Юзеева*** (1938) — укытучы, И.Юзеевның хатыны.

**ЭЧТӘЛЕК**

Чын мәгънәсендә халык шагыйре

Илдарның балачагы
Сабакташ
Туган җирнең гүзәл җырчысы
Моңнар җырчысы
Хәтердә калган мизгелләр
Слово об отце
Минем дәү әтием
Штрихи к портрету Ильдара абый

«Гадәт-холкым беләнnull...»
Ямады
«Мәхәббәт, нишләттең...»
Шагыйрьләр нигә картаймый?
Болытлар артында Кояш бар!
Кошлар юлы
Ян, күңел!
Хәсрәтле җыр
«Әллә нигә йөрәк яна бу айда...»
«Юк инде гамьсез шаяру...»
Сагышлы мирас
«Искитәрлек булмаса да...»
Озак яшисегез килсә...
Шом
Кояшлы хыяллар

Алгы сафтагы шагыйрь
Янар чәчәкләрнең яктысы
«Үз йөрәгең янар чәчәк»
Элегия
Эчкерсез дуслык
Болытлар артындагы кояш
Илдар мәзәкләре
Гүзәл зат иде...
Илдар Юзеевка
Иҗади дуслык ялкыны
Юксындыра...
Моңсу шагыйрь
Тапкыр сүз хикмәте
Асыл зат иде...
Теләктәшләр булып…
Сагыш
Яңавылга — Илдар Юзеевның туган җиренә бер сүз
Җырлап узган гомер арасы...
Яшәргә стимул биреп китте
Романтик рухлы иҗатчы
Илдар Юзеев
Сагынам
Үзебезнең Юзәй
Җырың китмәс инде күңелдән
Тик оча алмыйм...
Ачы яшь түгеп
Онытабыз
Остазыбыз!

Әзерҗавап Илдар Юзеев
Кирәклеләр китә
Ул минем остазым иде
Яшьлекләрнең яшьтәше
Мәңгелек булмаса да, гомерлек...
Юзизмнар
Олуг Шагыйрь белән әңгәмә
Шигырь ялкыны
Яшьлек җырчысы
Җиргә кайткан пәйгамбәрдәй
Аның двойнигы юк
Изге әманәткә тугрылык
«Таныш моңнар» өзә үзәкне...
«Илдар абыйга шылтыратырга!»
«Йөрәктәге тирән ярам»
Җырларымны сезгә бүләк итәм...
Кыр казлары артыннан...
Шигъриятттә үз биеклеге бар!
Боз өстендәге учак
Көчле шәхес, кодрәтле шагыйрь
Мәңге сүнмәслек янгын
Эх, ул чаклар!..
«Бик юаш мин…»
Иҗат — татлы газап
Карларга да бүген кайгы сарган…
Сагынып уйлану…
Мәңгелек җыр
Авторлар турында белешмә

***Китапта И.Юзеев, Р.Миңнуллин архивындагы фотолар, И.Юзеевның З.Гыймаев эшләгән портреты файдаланылды***

Литературно-художественное издание

Ильдар Юзеев

Составители: **Миннуллин** Роберт Мугаллимович, **Юзеева** Тафтиля Зарифовна

Казань. Татарское книжное издательство. 2008

На татарском и русском языках

Әдәби-нәфис басма

Илдар Юзеев

Төзүчеләре: **Миңнуллин** Роберт Мөгаллим улы, **Юзеева** Тәфтилә Зариф кызы

Мөхәррирләре *Р.Ә.Заһидуллина, А.Җ.Алишева*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Т.В.Гредюшко*
Корректоры *Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 20.03.2008. Форматы 70г100 $^{1}/_{16}$.
Шартлы басма табагы 16,25. Шартлы буяу-оттиск 65,65. Нәшер-хисап табагы 18,01.
Тиражы 3000 д. Заказ Т-171.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.